А 219567 (кол)

В. Н. ДЕНИСЬЕВ

# КӨТЕПХАНӘ ЭШЕ БУЕНЧА КЫСКАЧА КУЛЛАНМА

ТАТГОСИЗДАТ
КАЗАН 1948

ру (кол)

5-КР-РУ-БИ-48

РСФСР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ ЯНЫНДА
КУЛЬТУРА-АГАРТУ ЭШЛӘРЕ КОМИТЕТЫ

В. Н. ДЕНИСЬЕВ

# КӨТЕПХАНӘ ЭШЕ БУЕНЧА КЫСКАЧА КУЛЛАНМА

ЯҢА ЭШЛИ БАШЛАУЧЫ
КӨТЕПХАНӘЧЕЛӘР ӨЧЕН

*А. В. Увов редакциясендә*

А 219567 (кол.)

ТАТГОСИЗДАТ
КАЗАН 1948

ОРЛОВСКАЯ ОБЛАСТНАЯ
ПУБЛИЧНАЯ
БИБЛИОТЕКА
им. И.А. Бунина

## *КЕРЕШ СҮЗ*

### МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ КӨТЕПХАНӘДӘ ЭШЛӘҮЧЕНЕҢ РОЛЕ

Китап — бик зур көч ул.

Матбугат — „безнең партиябезнең бик үткер һәм бик көчле коралы“ (Сталин).

Массовый көтепханәнең бурычлары — китапны, матбугатны барлык хезмәт ияләренә җиткерү, СССР да басылып чыга торган бик күп һәм төрле-төрле басма әсәрләрне халык арасында тарату, халыкның укуга булган ихтыяҗларына хезмәт күрсәтү. Көтепханә башка төрле культура-агарту учреждениеләре арасында күренекле урын тота, ләкин ул үзенең бурычларын үзенә махсус, үзенә хас булган юллар белән хәл итә,— китаплар һәм башка төрле матбугат әсәрләре турында пропаганда алып бара, үзләренә кирәкле китапны сайлап алуда һәм китап өстендә үзлекләреннән эшләүдә укучыларга ярдәм итә.

Матбугат әсәрләре турында пропаганда алып барып һәм ул әсәрләрне кулларга биреп, көтепханә укучыларга марксизм-ленинизмны өйрәнүдә ярдәм күрсәтә, аларны совет патриотизмы рухында тәрбияли, аларда Ватанга мәхәббәт һәм аның дошманнарына карата нәфрәт хисен ныгыта. Көтепханә киң күләмдә масса эшләре алып барырга, хезмәт ияләренә агымдагы политика мәсьәләләрен, партия һәм хөкүмәт карарларын, шул край, өлкә һәм район алдында торган бурычларны аңлатырга тиеш.

Китап — белемнәр чыганагы ул.

Китапларны пропагандалау һәм кулларга бирү белән көтепханә төрле белемнәр — табигать фәне, техника, авыл хуҗалыгы белемнәрен, хәрби һ. б. белемнәр-

не халыкка илтә. Шуның белән китапханә укучыларның үзлекләреннән белем алуларына, культура дәрәҗәсен киңәйтүләренә, аларның производство квалификациясен күтәрүләренә булышлык итә. Бик күп совет кешеләре үзләренең белемен үстергән өчен, фән, техника, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге унышлары һәм казанышлары өчен китапханәләргә бурычлылар. Массовый китапханәләргә йөрүчеләрнең үзләренең бик күп отзывлары (фикерләре) моны яхшы раслыйлар.

В. И. Ленин китапханәләргә зур әһәмият бирде. „Халык мәгарифе өчен нәрсәләр эшләргә мөмкин“ дигән мәкаләдә, 1913 елда Ленин китапханәләрнең халык өчен киң файдалана алырлык булу таләбен куйды. Ул китапханәләрнең „...галимнәр, профессорлар һәм башка шундый белгечләр цехы өчен генә түгел, бәлки масса өчен, халык өчен, урам өчен“ (Әсәрләр, XVI том, 529 бит) киң файдалана алырлык булырга тиешлекләрен күрсәтеп үтте.

Патша Россиясендә китапханәләр китаплардан файдалану турында, аларны халыкка җиткерү турында кайгыртудан бигрәк китап туплау турында, библиография характерындагы, сирәк очрый торган әсәрләр җыю турында күбрәк кайгырталар иде.

Ленин китапханәләр алдына яңа бурычлар куйды: „...һәркем өчен ачык китапханәнең горурлыгын һәм данын анда сирәк очрый торган әсәрләрнең күпме булуында, нинди дә булса XVI гасыр әсәрләренең яки X гасыр кулъязмаларының күпме булуында түгел, бәлки китапларның **халык арасында** ничаклы **киң** әйләнүендә, яңа укучыларның күпме тартылуында, китапка булган теләсә нинди таләпнең ничаклы тиз канәгатьләндерелүендә, китапларның өйләргә күпме бирелүендә, укуга һәм китапханәдән файдалануга күпме баланың тартылуында күрергә кирәк...“ (шунда ук).

Советлар Россиясендә китапханә эшен оештыру мәсьәләсенә В. И. Ленин бик зур игътибар һәм кайгыртучанлык белән карады. Мәктәптән тыш белем бирү буенча I Бөтенроссия съездында сөйләгән речендә Ленин болай диде: „Без үзебездә булган китаплардан файдаланырга тиешбез һәм халыкка үзебездә булган һәр китаптан файдаланырга ярдәм итәрлек оешкан китапханәләр челтәрен төзи башларга тиешбез, параллель оешмалар төземәскә, бәлки бердәм планлы оешма төзергә тиешбез“ (Әсәрләр, XXIV том, 277 бит).

Ленин китапларның, брошюраларның, газета һәм журналларның көтепханәләр арасында дөрес бүленүе һәм аларга вакытында барып җитүе турында кайгыртты. Ленин көтепханә эшендә отчет бирүнең дөрес куелуын таләп итте һәм моның:

„1) нәрсәләр эшләнү турында совет властен да, шулай ук барлык гражданнарны да дөрес һәм тулы **таныштырып** торуны,

2) **халыкның үзен** эшкә тартуны,

3) көтепханә работниклары арасында **ярыш** тудыруны"* тәэмин итәргә тиешлеген күрсәтеп үтте.

Ленин күрсәтмәләре буенча эш итеп, большевиклар партиясе һәм совет хөкүмәте көтепханәләр челтәрен киңәйтү турында, аларның фондларын ныгыту турында, көтепханә эше буенча квалификацияле белгечләр кадры тудыру турында, һәрвакыт зур кайгыртучанлык күрсәтеп килделәр һәм күрсәтеп киләләр.

„Правда" газетасының 1935 ел 12 апрель номерының баш мәкаләсендә болай диелгән: „Көтепханә фонды — совет культурасының алтын фонды ул. Без үзебезнең китап байлыгыбыз белән тизлектә дөньяда беренче урынга күтәрелеп барабыз, ләкин безнең илебез өчен, аның белемгә һәм культурага сусап омтылучы халыклары өчен бу аз әле". Шул ук мәкаләдә культура эшен, аерым алганда көтепханә эшен, партиянең политик эш итеп караганлыгы һәм көтепханәләр алдына җаваплы һәм җитди бурыч — политик аң белем һәм халык культурасы үзәкләре булып әверелү бурычын куйганлыгы әйтеп үтелә.

„...Безнең илебездә, халыкта китапка һәм белемгә ихтыяҗ гаять нык үскән илдә, көтепханә эше дәүләт күләмендә зур әһәмият казанды"*, диде иптәш В. М. Молотов.

Партия һәм хөкүмәтнең кайгыртучанлык күрсәтүләре аркасында СССР да көтепханә эше, революциягә кадәрге Россиядә булганга чагыштырганда, бик нык алга атлады. 1914 елда массовый көтепханәләр 12 600 булган, аларның фонды 8 900 мең китаптан торган, уртача алганда һәр көтепханәгә чама белән 750 китап туры килгән.

---

* „Ленинский сборник"— XXIV, 159 бит.

* В. М. Молотов. Югары мәктәп турында. Югары мәктәп работникларының 1938 елны 15 майда булган Беренче Бөтенсоюз киңәшмәсендә сөйләгән речь. М. Госполитиздат. 1938 ел. 10 бит

СССР да 1939 елның 1 октябрена 86 266 массовый көтепханә булып аларның гомуми фондында 166 728 мең китап булган, уртача алганда һәр көтепханәгә 2000 ләп китап (1933 китап) туры килде. Шулай итеп, 1914 ел белән чагыштырганда 1939 елда массовый көтепханәләр саны 7 тапкыр артты, аларның гомуми китап фонды 19 тапкыр үсте, һәр көтепханәдәге китапларның уртача саны 2,5 тапкырдан күбрәк артты.

Әгәр дә инде массовый көтепханәләрне генә түгел, бәлки барлык типтагы көтепханәләрне дә (һәркем өчен булган дәүләт көтепханәләрен, фәнни көтепханәләрне, вуз, мәктәп көтепханәләрен һ. б.) алсаң, ул чагында 1939 ел башлануга СССР да аларның саны 240 765 булды, ә аларның гомуми фонды 442 миллион китапка җитте.

Сугыш вакыты шартларында көтепханәләрнең роле артты һәм аларның бурычлары тагын да катлаулырак һәм җаваплырак булды. Көтепханәләр үзләренең агитация-масса эшләрен көчәйттеләр, аерым алганда — газета белән эшләүгә аеруча игътибар бирделәр, халыкка, бигрәк тә хәрби хезмәткәрләр семьяларына белешмә бирү хезмәтен яхшырттылар, промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының яңа кадрларына китап белән ярдәм иттеләр, госпитальләрдәге авыруларга һәм яралыларга китап белән хезмәт күрсәттеләр, күчмә көтепханә эшен һәм укучыга китапны илтеп тапшыру эшен киңәйттеләр. Гомумән көтепханә үзенең эшен илебезнең куәтен көчәйтүгә мөмкин кадәр күбрәк һәм яхшырак ярдәм итәрлек итеп корырга тиеш. Кирәкле әдәбиятны оста итеп массага җиткерү белән көтепханә һәр укучыга үзенең Ватан алдындагы патриотлык бурычын үтәүгә ярдәм итә.

Немец-фашист илбасарлар СССР көтепханәләренә гаять зур зыян китерделәр, бик кыйммәтле китапларны таладылар һәм Германиягә алып киттеләр, вакытлыча оккупацияләнгән районнарда барлык көтепханәләрне диярлек тар-мар китерделәр һәм яндырдылар.

Азат ителгән районнарның көтепханә работниклары алдына аерым бурычлар килеп басты, фашист варварлар җимергән көтепханәләрне бик кыска вакыт эчендә аякка бастырырга һәм район халкына аның халык хуҗалыгын һәм культурасын торгызу эшендә китап, газета, журнал белән ярдәм итәргә кирәк булды. Оккупациядә булмаган районнарның көтепханәләре дә бу бурыч-

тан читтә тора алмыйлар. Алар азат ителгән районнарның көтепханәләренә бер үк исемдәге китапларның берничә данәсен бирү белән, бигрәк тә Бөек Ватан сугышы көннәрендә чыккан әдәбият белән, үткән елларда чыккан газета һәм журналларның артык комплектлары белән, библиографик һәм көтепханә эшендә методик ярдәмлекләр белән, ниһаять, торгызыла торган көтепханәнең эшен ничек яхшырак оештыру турында киңәшләр бирү белән ярдәм итәргә тиешләр.

Көтепханә эшчесенең роле һәм вазифалары массовый көтепханәнең политик-агарту бурычлары белән билгеләнә. Кайбер кешеләр: көтепханә эшчесенең эше— техник эш ул, аның эше укучыга китап бирүдән һәм аны укучы карточкасына язып куюдан, укучыдан китапны алып, китапның кайтарылуы турында билге ясап куюдан гына гыйбарәт дип ялгыш уйлыйлар.

„Көтепханә эшчесе — техник работник кына түгел, китапларны механик рәвештә өләшеп утыручы гына түгел. Ул — большевистик культура пропагандисты һәм агитаторы. Аның бөтен эше большевистик идея һәм партиялелек рухы белән сугарылган булырга тиеш" („Правда". 1937 ел. 31 август. „Көтепханә эше" дигән баш мәкалә).

„Совет көтепханә работниклары алдында зур, мактаулы бурыч — кешелек дөньясы тарафыннан тудырылган иң яхшы нәрсәләрнең бөтенесен үзендә туплаган большевистик культураны үзләштерүдә ватаныбызның хезмәт ияләренә ярдәм итү бурычы тора" (шунда ук).

Шушы җаваплы бурычны үтәү өчен, көтепханә эшчесе культуралы, политик белемле кеше булырга тиеш, китапны белергә һәм яратырга, аның белән эшли белергә тиеш.

Көтепханә эшчесенең әһәмиятен һәм ролен Н. К. Крупская болай дип билгели:

„Көтепханә эшчесе — эшнең җаны ул. Бик күп эш аңа бәйләнгән. Ул үз эшенең энтузиасты булырга, укучылар массасы белән эш итә белергә, көтепханә эшенең методларын үзләштерергә, көтепханәнең бөтен эшен шушы методлар ярдәмендә оештыра белергә тиеш" (Н. К. Крупская. Көтепханә эшенең бурычлары. М. Партиздат. 1934 ел. 22 бит).

Көтепханә эшчесе халыкка якын торырга, үзенең укучыларын белергә, аларның интересларын төшенергә, үз районының яки авылының җәмагать тормышын-

да катнашырга тиеш. Көтепханәдә китап бирү белән генә чикләнмичә, көтепханә эшчесе китап, газета, журнал белән производство участокларына, кыр станнарына, колхозчыларның өйләренә бара. Көтепханә эшчесе китап фондыннан төрле практик мәсьәләләрне (мәсәлән, язгы чәчү, игеннәрне урып-җыю эшләрен һ. б. ларны) хәл итүдә халыкка ярдәм күрсәтү өчен файдаланырга тырыша.

Көтепханә эшчесе көтепханә эшенә җәмәгатьчелекнең игътибарын тартырга, көтепханә каршында укучылар активы тупларга һәм алар ярдәмендә халыкка китаплар һәм бүтән төрле матбугат әсәрләре белән хезмәт күрсәтүне һәрьяклап киңәйтергә һәм яхшыртырга тиеш.

---

## *БУЛЕК*

## РАЙОН ҺӘМ АВЫЛ КӨТЕПХАНӘЛӘРЕНЕҢ ЭШЕН ОЕШТЫРУ

### § 1. РАЙОНДА КӨТЕПХАНӘЛӘР ЧЕЛТӘРЕ

Безнең илебездә дәүләт тарафыннан бик күп көтепханәләр челтәре оештырылды. Һәр районда, кагыйдә буларак, район һәм авыл, балалар һәм мәктәп көтепханәләре бар.

Шуның өстенә районда гадәттә җәмәгать оешмаларының: колхозлар, профсоюзлар, кустарь-һөнәр артельләре, партия район комитетының (парткабинет) көтепханәләре бар.

Үзенә аерым авыл көтепханәләре авыл советлары каршында, халык күбрәк булган пунктларда оештырылалар.

Авыл көтепханәсе шушы авыл советы территориясендә яшәүче халыкка китап белән хезмәт күрсәтә, ә кайбер хәлләрдә, үзләренең көтепханәләре булмаса, башка авыл советлары территориясендә яшәүче халыкка да хезмәт күрсәтә. Авыл көтепханәләре уку өйләре белән тыгыз бәйләнештә эшлиләр. Һәрбер уку өендә кечкенә көтепханә булырга тиеш, ә аңа өстәмә итеп авыл (яки район) көтепханәсеннән күчмә көтепханә оештырылырга мөмкин. Авыл көтепханәсе китаплар белән зурларга гына түгел, бәлки балаларга да хезмәт күрсәтергә тиеш.

Район көтепханәсе район күләмендә әһәмиятле булган массовый көтепханә һәм китап саклау урыны булып исәпләнә. Гадәттә ул район үзәгендә була һәм аның халкына өйгә һәм уку залында китаплар биреп хезмәт күрсәтә. Районда балалар өчен аерым көтепханә булмаса, район көтепханәсе балаларга да хезмәт күрсәтергә тиеш.

Район көтепханәсе авыл көтепханәләренә методик ярдәм күрсәтә, авыл көтепханәсе эшчеләре өчен методик киңәшмәләр, курслар, семинарлар, практикумнар үткәрә.

Район көтепханәсе үзенең эшендә район парткабинеты көтепханәсе һәм районадагы башка көтепханәләр белән бәгланыш тотарга тиеш.

Балалар өчен аерым көтепханәләр күбрәк шәһәрләрдә була.

Балалар көтепханәләре мәктәп көтепханәләре белән бәгланыш тотып эшлиләр һәм көтепханәсендә җитәрлек китап фонды булмаган мәктәпләргә күчмә көтепханәләр бирәләр.

Райондагы балалар көтепханәләре авыл көтепханәләренә укучы балалар белән эшләүдә методик ярдәм күрсәтәләр.

*Мәктәп көтепханәләре* башлангыч, җидееллык һәм урта мәктәпләр каршында булалар һәм укучы балаларга хезмәт күрсәтәләр.

*Колхоз көтепханәләре* колхозлар карары буенча ачылалар һәм аларның үзләре средствосына яшиләр. Үзләренең бурычлары буенча колхоз көтепханәләре авыл көтепханәләреннән аерылмыйлар һәм авылның барлык хезмәт ияләренә китап бирәләр. Колхоз көтепханәсенең торышы һәм эше өчен колхоз правлениесе җаваплы була.

Колхоз көтепханәләре методик ярдәмне, авыл советлары көтепханәләре белән бер дәрәҗәдә, район көтепханәләреннән алалар.

*Профсоюз көтепханәләре* предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, профсоюз клубларында оештырылалар. Профсоюз көтепханәсе укучылар активы ярдәмендә профсоюз членнарын һәм аларның семья членнарын китаплардан файдалануга тарта. Профсоюз көтепханәләре, нинди профсоюз оешмасы карамагында булсалар, шул оешма средствосына яшиләр. Совхоз көтепханәләре дә профсоюз көтепханәләре рәтенә керәләр. Алар совхозлардагы профсоюз оешмалары средствосына яшиләр һәм совхозларда торучы эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә, шулай ук аларның семья членнарына хезмәт күрсәтәләр.

Колхоз һәм профсоюз көтепханәләре дәүләт көтепханәләре челтәренә—район, шәһәр, авыл көтепханәләренә һ. б. ш. ларга өстәмә булып хезмәт итәләр һәм

халыкка китап белән тулырак хезмәт күрсәтүгә, укучыларның сорауларын тулырак канәгатьләндерүгә булышлык итәләр.

Күчмә көтепханәләр. Китапны халыкка якынайту өчен, ара ерак булу яки вакыт булмау сәбәпле даими (стационар) көтепханәләрдән файдалана алмаган кешеләрне укучылар рәтенә тарту өчен күчмә көтепханәләр оештырыла һәм китапларны укучыга илтеп бирү үткәрелә. Даими көтепханәләр үз фондларыннан китаплар аерып алып, шул китапларны төрле оешмаларга бирәләр, бу оешмалар шул китаплар белән үз членнарына коллектив хезмәт күрсәтәләр. Шундый юл белән, үзенең китап фонды булмаган, ә китапларны вакытлы файдалану өчен даими көтепханәләрдән яки махсус оештырылган күчмә фондтан алып торучы күчмә көтепханәләр (передвижкалар) оештырыла. Күчмә көтепханәләр белән предприятиеләргә, учреждениеләргә, торак йортларга, тулай торакларга, промкооперация артельләренә, грамота өйрәтү мәктәпләренә, колхозларга, совхозларга, машина-трактор станцияләренә һ. б. хезмәт күрсәтелә. Авыл көтепханәләре һәм уку өйләре колхоз бригадаларына, кыр станнарына, авыл хуҗалыгы эшләренең төрле участокларына күчмә көтепханәләр бирәләр һәм аларда укучыларга китап илтеп бирүне оештыралар. Күчмә эш халыкка көтепханәләр аша хезмәт күрсәтүнең иң массовый һәм иң җайлы формасы булып тора.

## § 2. КӨТЕПХАНӘ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕК

Авыл көтепханәләре культура-агарту эшенең район бүлеге һәм авыл советы җитәкчелегендә эшлиләр. Авыл көтепханәсенең эш планы авыл советы тарафыннан раслана, эш турындагы отчет авыл көтепханәсе тарафыннан авыл советына һәм культура-агарту эшенең район бүлегенә тапшырыла.

Авыл көтепханәләре методик ярдәмне беренче чиратта район көтепханәсеннән алалар. Көтепханә эшенең техникасына һәм методикасына караган барлык кыен хәлләрдә, мәсәлән, китапларга классификация үткәргәндә, массовый чаралар—кычкырып укулар, беседалар һ. б. ларны үткәргәндә, авыл көтепханәсе эшчесе ярдәм сорап район көтепханәсенә мөрәҗәгать итә.

Авыл көтепханәсендә яңа эшкә башлаучы көтепханәчеләр район көтепханәсендә практикум үтәләр, ягъни мөстәкыйль эшкә керешкәнче, чама белән ике атна вакыт дәвамында район көтепханәсе мөдире җитәкчелегендә практикада көтепханә эшен өйрәнәләр. Район көтепханәсе авыл көтепханәсе эшчеләренә ярдәм күрсәтә, аларның эшен тикшерә һәм аларга инструкция бирә. Район көтепханәсе аена бер тапкыр авыл көтепханәсе эшчеләренең методик киңәшмәсен үткәрергә тиеш. Киңәшмәдә авыл көтепханәләренең отчетлары тыңлана, эш тәҗрибәсен уртаклашу үткәрелә, авыл көтепханәләренең агымдагы эшләре турында күрсәтмәләр бирелә.

Район көтепханәсе культура-агарту эшенең район бүлеге тарафыннан расланган һәм райондагы партия һәм совет оешмаларының эш планы белән килештерелгән план буенча эшли. ВКП (б) район комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге тарафыннан һәм район парткабинеты тарафыннан җитәкчелек һәм ярдәм күрсәтелү район көтепханәсе өчен аеруча әһәмиятле.

Өлкәләрдә (крайларда) көтепханә эшенә җитәкчелек культура-агарту эшләренең өлкә (край) бүлекләре тарафыннан, ә автономияле республикаларда АССР ның культура-агарту учреждениеләре идарәләре тарафыннан тормышка ашырыла.

Культура-агарту эшләренең өлкә бүлеге, нинди ведомство кулында булуларына карамастан, өлкәдәге барлык көтепханәләрнең эшенә дәүләт контролен тәэмин итә.

Өлкәдәге көтепханәләрнең тормышында өлкә көтепханәсе зур роль уйный. Ул өлкә күләмендә әһәмияте булган китап саклау урыны булып тора һәм, өлкәдәге бүтән массовый көтепханәләр белән чагыштырганда, аның көтепханә фонды аеруча көчле була. Өлкә көтепханәсе өлкәдәге көтепханәләргә китаплар белән ярдәм итә, моның өчен көтепханәләр арасындагы абонементны оештыра, ягъни көтепханәләрнең сораулары буенча аларга вакытлыча файдалану өчен үз фондыннан китаплар җибәрә.

Өлкә көтепханәсенең белешмә-библиография бүлеге массовый көтепханәләргә ярдәм итү өчен библиографик материаллар хәзерли, бик әһәмиятле темалар буенча, бигрәк тә хуҗалык-политик кампанияләр үткәрү уңае белән, тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләре

белән тәэмин итә. Һәрбер өлкә көтепханәсендә көтепханә эше буенча методик кабинет булырга тиеш. Методик кабинет массовый көтепханәләрнең эш тәҗрибәләрен өйрәнә һәм гомумиләштерә, иң яхшы тәҗрибәне популярлаштыра һәм өлкәдәге барлык көтепханәләргә җиткерә. Методик кабинет инструктив-методик материаллар төзи һәм аларны көтепханәләргә җибәрә, язма яки телдән консультацияләр үткәрә, урында ярдәм күрсәтү өчен район һәм авыл көтепханәләренә методистлар җибәрүне оештыра. Методик кабинет өлкәдәге көтепханә работникларына үзләренең культура-политик дәрәҗәләрен һәм производство квалификацияләрен күтәрүдә булышлык күрсәтә.

РСФСР да барлык көтепханә эшенә РСФСР Министрлар Советы каршындагы культура-агарту учреждениеләре эшләре комитеты җитәкчелек итә. Комитет составында көтепханәләр управлениесе һәм уку йортлары бүлеге бар, көтепханә техникумнары шулар карамагында эшлиләр. Бу уку йортлары район һәм авыл көтепханәләре өчен белгечләр хәзерлиләр.

Кайбер көтепханә техникумнарында, төп бүлекләрдән башка, балалар көтепханәләре өчен работниклар хәзерли торган бүлекләр бар. Көтепханә техникумнарының читтән торып уку бүлекләре дә була.

Көтепханә эше буенча югары белем бирә торган ике институт бар: Москвада өч факультеты—көтепханә эше, библиография һәм балалар көтепханәсе факультеты—булган В. М. Молотов исемендәге дәүләт көтепханә институты, шулай ук Ленинград көтепханә институты.

1943 елда РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты каршында Дәүләт әдәбият фонды оештырылды. Аның бурычы—немец оккупациясеннән азат ителгән районнардагы көтепханәләрне китап белән комплектовать итү. 1945 елда Дәүләт әдәбият фонды РСФСР Министрлар Советы янындагы культура-агарту учреждениеләре эшләре комитеты карамагына күчте.

Көтепханәләргә методик ярдәмне политик-агарту эшләре Үзәк кабинеты күрсәтә. Бу кабинет составында көтепханә бүлеге бар. Бу бүлек массовый көтепханәләрнең эш тәҗрибәсен җыя, өйрәнә һәм гомумиләштерә, аларга ярдәмгә инструктив-методик материаллар төзи, өлкә көтепханәләре каршындагы методик кабинетларның эшенә җитәкчелек итә, көтепханә техникум-

нары, курслар һәм семинарлар өчен программалар һәм пособиеләр хәзерли. Политик-агарту эшләре Үзәк кабинетына консультация бирүне сорап һәрбер массовый көтепханә мөрәҗәгать итә ала.

РСФСР Министрлар Советы янындагы культура-агарту эшләре комитетының издательствосы бар. Бу издательство көтепханә эше буенча әдәбият, массовый көтепханәләр өчен библиографик пособиеләр һәм көтепханә техникасы әйберләре (инвентарь кенәгәләре, укучы формулярлары, каталог карточкалары, китап формулярлары һ. б.) бастырып чыгара.

ВКП (б) Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть һәм библиография турындагы карары буенча шәһәр һәм авыллардагы массовый көтепханәләр өчен тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләрен хәзерләү эше СССР ның В. И. Ленин исемендәге һәм Ленин орденлы Дәүләт көтепханәсенә тапшырылды.

Хәзерге вакытта „Красный библиотекарь" журналы чыгып килә. Бу журнал көтепханә эше теориясе һәм практикасы мәсьәләләрен, шулай ук иң яхшы көтепханәләрнең, бигрәк тә массовый көтепханәләрнең эш тәҗрибәсен яктырта. Һәрбер көтепханә эшчесе бу журналны һәрвакыт укып барырга тиеш.

Гомумән, совет көтепханә эшчесенә үз профессиясе буенча белемен күтәрү һәм үз көтепханәсенең эшен яхшырту өчен киң мөмкинлекләр бирелгән.

## § 3. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ АНЫҢ КИТАПЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ТӘРТИБЕ

Район көтепханәсендә, кагыйдә буларак, өч бүлек: абонемент, уку залы һәм күчмә фонд бүлеге була.

Районда балалар өчен аерым көтепханә булмаса, район көтепханәсендә балалар бүлеге дә булырга тиеш.

Өйгә китаплар бирү бүлеге абонемент дип атала. Бу—массовый көтепханәнең иң әһәмиятле, төп бүлеге. Китаплар биргәндә көтепханә эшчесе укучы белән сөйләшә, кирәкле әдәбиятны сайлап алуда аңа ярдәм итә, аңа яхшы китапларны укырга тәкъдим итә, укучыны өйрәнә һәм аның укуына җитәкчелек итә. Көтепханәнең төп китап саклый торган урыны абонемент каршында була. Урындагы шартларга карап абонемент халык өчен иң уңайлы сәгатьләрдә ачык булырга тиеш.

Һәрбер массовый көтепханәнең бурычы — мөмкин кадәр күбрәк укучы тарту, үзенең китап фондыннан мөмкин кадәр яхшырак файдалану. Ләкин, шуның белән бергә, китапларның саклануы турында да кайгыртырга һәм китаплардан файдалану буенча билгеләнгән кагыйдәләрне нык җиренә җиткереп үтәргә кирәк. Массовый көтепханәләрдән файдалану буенча РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан 1944 елның 25 сентябрендә расланган кагыйдәләр шушы китапка кушымта итеп урнаштырылды, биредә иң әһәмиятлеләрен генә күрсәтеп үтәбез.

Массовый көтепханәдән барлык гражданнар түләүсез файдалана алалар. Шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә өйгә китап алу өчен көтепханәгә язылганда паспорт күрсәтү таләп ителә. Көтепханәгә язылучының шушы урында даими рәвештә яшәве турында паспортында билге булырга тиеш. Бу урында вакытлы рәвештә торучы кешеләр китап алу өчен 30 сум залог кертәләр. Көтепханәдән файдалану тәмам булганнан соң залог укучыга кире кайтарып бирелә. 16 яшькә җитмәгән балалар китап алу өчен ата-аналарының яки үзләрен тәрбияләүче башка кешеләрнең поручительствосын (ышаныч кәгазен) күрсәтәләр.

Көтепханәдән китаплар беркемгә дә бөтенләйгә бирелми.

Укучы өйгә берьюлы өч данә китап алырга хаклы: брошюраларны санамаганда, матур әдәбияттан бер китап һәм фәнни ике китап алырга мөмкин. Китаплардан файдалану срогы—10 көн. Әгәр дә китапны башка укучылардан сораучы булмаса, укучының үтенече буенча бу срокның озайтылуы мөмкин.

Көтепханә эшчесе укучыларда китаплар белән культуралы һәм җыйнак эш итү гадәтләре тәрбияләү буенча эш алып барырга тиеш. Китапларны саклап тоту турында көтепханәдә күп кенә плакатлар эләргә киңәш бирелә: „Китап—социалистик милек“, „Китапны срогыннан артык тотма, аны бүтән укучылар көтә“, „Китапны ертылудан сакла“ һ. б. Кагыйдә буларак, дефектлы китаплар көтепханәдән бирелми.

Укучы китапларны срогында кайтармаса аңа повестка—искәртү кәгазе җибәрелә. Китапны срогыннан артык тотып, кичегеп китергән һәрбер китап өчен укучыдан көненә 50 шәр тиен пеня алына. 10 көн үткәч пеня ике тапкыр арта. Әгәр дә повестка алганнан соң

да укучы китапны кайтармаса, көтепханә аның өенә сборщик җибәрә, аңа китапларны һәм пеняны алып кайту бурычы йөкләтелә. Әгәр дә берәү китапны югалтса, яки бозса, укучы көтепханәгә шундый ук китап яки (көтепханә белән килешеп) шуңа тиң китап кайтарып бирергә тиеш, алай эшләмәсә, китап урынына китап алу өчен шул китапның бәясен түләргә тиеш. Укучы югалткан китапның бәясен түләүдән баш тарткан хәлдә, көтепханә аны нотариаль контораның башкару язуы буенча яки суд аша түләтә. Ләкин башка төрле чара булмаганда гына судка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Көтепханә, беренче чиратта, укучылар арасында аңлату эшләре алып барырга, аларда көтепханә китапларына социалистик милек итеп аңлы рәвештә карауны тәрбияләргә тиеш. Укучы балалар белән мәктәпләрдә китапларны саклап һәм культуралы тоту турында беседалар үткәрергә кирәк.

Җыйнаксыз укучыларга йогынты ясау өчен аларның фамилияләрен стена газеталарына, җирле матбугатка язып чыгарырга, укучыларның җыелышларында игълан итәргә, укучы член булып торган партия һәм профсоюз оешмалары игътибарына җиткерергә киңәш бирелә.

Гомумән, халыкның киң катлауларын көтепханәдән файдалануга тарту, китапларны массага нык якынайту белән бергә, көтепханә эшчесе бер үк вакытта китаплардан файдалану кагыйдәләренең үтәлүен күзәтә һәм шушы кагыйдәләрне бозган барлык хәлләрдә кискен чаралар күрә. Китап фондының саклануы өчен көтепханәнең бөтен работниклары һәм беренче чиратта көтепханә мөдире җаваплы.

Уку залының бурычы—килүчеләргә шунда, көтепханәнең үзендә, китаплар, газета һәм журналлар белән хезмәт күрсәтү.

Көтепханә өчен уку залы иң элек шуның белән бик әһәмиятле, чөнки ул, мәсәлән, газета һәм журналлар, белешмәләр һәм энциклопедияләр, күргәзмә пособие альбомнары кебек өйгә биреп булмый торган матбугат әсәрләреннән файдаланырга мөмкинлек бирә. Укучылар өчен уку залы шуның белән әһәмиятле, чөнки ул аларга уку өчен уңайлы, җайлы шартларда китап белән эш итәргә мөмкинлек бирә. Уку залы каршында гадәттә ярдәмче фонд була. Шуның өстенә, кирәк булган китаплар яки журналлар төп китап саклана торган урыннан алыналар.

Күчмә фонд—көтепханәнең күчмә көтепханәләр оештыру, комплектлау һәм күчмә көтепханәләр бирү белән шөгыльләнә торган бүлеге. Район көтепханәләрендә күчмә эш өчен махсус китап фонды булдырыла, ә авыл көтепханәләрендә күчмә көтепханәләр көтепханәнең гомуми фондыннан оештырыла.

Книгоношлык (китап илтеп бирү) я турыдан-туры даими көтепханәнең үзеннән, я ул төзегән күчмә көтепханәләрдән оештырыла. Китаплардан файдалану буенча даими көтепханәләр өчен кабул ителгән кагыйдәләр күчмә көтепханәләр өчен дә саклана. Китапларның саклануы өчен күчмә көтепханә алган оешма җаваплы була.

Балалар бүлеге китап белән гел диярлек 1—7 классларда укучы балаларга хезмәт күрсәтә. 8—10 классларда укучыларга зурлар абонементыннан файдаланырга рөхсәт ителә. Балалар бүлеге өчен балалар әдәбиятыннан махсус фонд төзелә.

Балалар бүлегенең абонементы һәм уку залы булырга мөмкин. Балалар бүлеге үзенең эшендә урындагы мәктәпләр һәм аларның көтепханәләре белән тыгыз бәйләнештә булырга тиеш. Балалар әдәбияты фонды кечкенә булган авыл көтепханәләрендә һәм кайбер район көтепханәләрендә балалар бүлекләре төзелми, бәлки зурлар һәм балалар өчен гомуми абонемент кына оештырыла. Мондый хәлдә балаларга китаплар аерым сәгатьләрдә бирелә.

Көтепханәләр арасындагы абонемент. Укучыларның әдәбиятка, бигрәк тә махсус характердагы китапларга булган сорауларын көтепханәнең канәгатьләндерә алмаган чаклары да булу мөмкин.

Укучыларның соравын тулырак канәгатьләндерү һәм зуррак көтепханәләрдә җыелган китап байлыгыннан күбрәк файдалану өчен көтепханәләр арасында үзара ярдәм итү буенча үзенә бертөрле тәртип куелган. Бу тәртип көтепханәләр арасындагы абонемент дип атала. Бу абонемент буенча көтепханәләр укучыларга үзләрендә булган китаплар белән генә түгел, бәлки вакытлы файдалану өчен бүтән көтепханәләрдән алынган китаплар белән дә хезмәт күрсәтәләр. Штатлы работнигы булган һәр көтепханә—фәнни һәм массовый көтепханә, көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу хокукыннан файдалана. Китапларның саклануы өчен җаваплылык шул көтеп-



А 219567 (кол)
ОРЛОВСКАЯ ОБЛАСТНАЯ
ПУБЛИЧНАЯ
БИБЛИОТЕКА
им. И.А. Бунина

ханәнең штатлы работнигына йөкләтелә. Массовый көтепханәләрнең көтепханәләр арасындагы абонемент буенча өлкә яки край эчендә китаплар алырга хокукы бар. Район көтепханәләре китап сорап өлкә көтепханәсенә, авыл көтепханәләре—район яки өлкә көтепханәләренә мөрәҗәгать итәләр. Сораган китаплар үзендә булмаган хәлләрдә өлкә көтепханәсе урындагы бүтән көтепханәләргә яки үзәк көтепханәләргә мөрәҗәгать итә ала.

Район һәм авыл көтепханәләре работниклары көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу мөмкинлегеннән киң файдаланырга тиешләр (көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу тәртибе турында II бүлектә, § 8 дә тулырак әйтелгән).

## § 4. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘДӘ УКУЧЫЛАР АКТИВЫ

Бер-ике работнигы булган авыл һәм район көтепханәләре китап бирүдән тыш күчмә көтепханәләр челтәре оештыралар, кычкырып укулар үткәрәләр, бик күп белешмәләр бирәләр. Эшне шундый колач белән алып баруга көтепханә укучылар активы ярдәмендә генә ирешә ала.

„Оешкан укучылар активы укуга яңадан-яңа укучылар кадрын тарту, аларны оештыру, аларның интересларын өйрәнү өчен гаять күп нәрсә эшли ала“ (Н. К. Крупская. Көтепханә эше. Мәкаләләр җыентыгы. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940 ел. 31 бит).

Көтепханә активы кемнәрдән җыйнала, көтепханәгә ярдәмгә нинди укучыларны тартырга кирәк соң?

Һәр көтепханәдә даими укучылар бар. Алар үзләренең китап яратулары белән аерылалар, газеталарны, журналларны, яңа китапларны күзәтеп баралар, көтепханәнең массовый чаралары белән кызыксыналар һәм аңа үзләре теләп ярдәм итәләр. Активистлар итеп беренче чиратта шундый укучыларны тартырга кирәк тә. Алар белән сөйләшеп, көтепханә эшчесе көтепханәдә аларга нинди эш җиңел һәм кызыклы булачагын белеп ала.

Көтепханә укучылар активы итеп урындагы интеллигенцияне аеруча күбрәк тартырга тиеш.

„Көтепханәнең һәрбер совет интеллигенциясе вәкилен көтепханәне яхшырту эшенә тарту турында кайгыртуы бик мөһим. Кеше көтепханәгә читтән генә карап тормасын, аңа коры „теләктәшлек“ күрсәтеп кенә чикләнмәсен—иң әһәмиятлесе шунда, ул аны яхшырту өстендә эшләсен, көтепханәне һәм аның эшен яхшырту аның үз эше булып әверелсен“ (Н. К. Крупская. Көтепханә эше. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940 ел. 28 бит).

Белемлерәк һәм китап белән кызыксына торган комсомолецларны, пионерларны һәм өлкән классларда укучыларны көтепханә эшендә катнашу өчен билгеләү турында комсомол һәм пионер оешмалары белән дә, мәктәп белән дә сөйләшергә кирәк.

Күчмә көтепханәләрдә эшләүчеләр, книгоношлар, кычкырып укучылар һәм беседа үткәрүчеләр барыннан да элек һәм аеруча җентекләп сайлап алыналар. Болар укучылар активының иң әһәмиятле һәм даими өлеше булалар. Урта мәктәп укытучылары үз белгечлекләре буенча докладлар һәм лекцияләр укуга, әдәбият кичәләре үткәрүгә тартылырга мөмкин. Агрономнар һәм зоотехниклар көтепханә тарафыннан авыл хуҗалыгы әдәбиятын пропагандалау өчен, медицина работниклары—медицина, гигиена, санитария буенча массовый әдәбиятны пропагандалау өчен тартылалар. Комсомолецлар, өлкән классларда укучылар, клуб түгәрәкләрендә катнашучылар көтепханәгә массовый чаралар (мәсәлән, кычкырып укулар, әдәби-музыкаль кичәләр) үткәрүдә ярдәм итәләр, китап күргәзмәләрен, көтепханә плакатларын, лозунгларын, стена газеталарын оформить итүдә катнашалар. Пионерлар, кече классларда укучы балалар ансат кына техник эшләрне башкара алалар, мәсәлән: китапларга печать сугалар, китапларның төшкән битләрен ябыштыралар, китапларга ярлыклар, кесәчекләр ябыштыралар һ. б. ш. Укучылар активын, бигрәк тә мәктәп балаларын вакытында китапларны китермәгән укучылардан өйләренә барып китапларны алып кайту өчен, шулай ук халык арасында ирекле рәвештә китап җыю өчен файдаланырга мөмкин.

Көтепханәнең белешмәләр бирү эшендә белгечләрнең, урындагы газета работникларының, район җитәкче работникларының аңа бик файдалы булулары мөмкин.

Көтепханә эшчесе һәрбер укучы активистка тапшырылган эшен үтәүдә ярдәм итә, методик күрсәтмәләр бирә, укучыга хәзерләнү өчен кирәкле материалларны табып бирә һ. б.

Эш тәҗрибәләре белән уртаклашу өчен көтепханә вакыт-вакыт активның киңәшмәләрен үткәрә.

Укучы активистларның җәмагать эше социалистик ярыш нигезендә корыла. Активистлар үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр, яңа укучылар тарту, кичектерелгән китапларны җыйнау, кычкырып укулар үткәрү һ. б. буенча йөкләмәләр алалар.

Көтепханә эшчесе укучы активистларның культура-политик дәрәҗәсен һәм көтепханә эше буенча квалификациясен күтәрү турында кайгыртырга тиеш. Көтепханә эшчесе активистларның китап укуларын оештыра, аларга китап сайлауда ярдәм итә, бу укучыларны системалы рәвештә уку юлына төшерергә омтыла. Район һәм шәһәр көтепханәләре каршында укучы активистлар өчен семинарлар оештырыла, семинарларда көтепханә эше буенча төп мәгълүматлар бирелә, бик тәкъдим ителә торган әдәбият күзәтүләре үткәрелә. Көтепханә вакыты-вакыты белән укучыларның гомуми җыелышларын җыя. Бу җыелышларда көтепханә мөдире отчет ясый. Көтепханә эшчесенең укучылар белән шундый очрашулары эштә булган кимчелекләрне бетерергә, көтепханә турында җәмагать фикерен тупларга ярдәм итә, көтепханәнең игътибарын укучылар ихтыяҗына таба, һәм укучылар игътибарын көтепханә ихтыяҗына таба тарта.

## II БУЛЕК

# КӨТЕПХАНӘ ФОНДЫНЫҢ СОСТАВЫ, АНЫ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ КОМПЛЕКТЛАУ

### § 1. КӨТЕПХАНӘ ФОНДЫНЫҢ ТӨП ӨЛЕШЛӘРЕ

Массовый көтепханәдә булган китапларга карап, аның фондын түбәндәге өлешләргә (яки аерым фондларга) аерырга мөмкин:

а) китап фонды, б) брошюралар фонды, в) журналлар фонды, г) газеталар фонды.

5 басма табакка кадәр (уртача форматта 80 бит) күләмдә булган кечкенә китаплар брошюра дип аталалар.

Массовый көтепханәнең төп фонды булып аның китап фонды санала.

Китап һәм брошюра фондларына керә торган әдәбиятны, аның эчтәлегенә һәм язылу рәвешенә карап, төп ике төргә аерырга мөмкин:

а) барлык белем тармаклары буенча фәнни әдәбият һәм б) матур әдәбият (икенче төрле әйткәндә, беллетристика).

Балалар әдәбияты (фәнни һәм матур әдәбият), СССР халыклары (украин, белорус, грузин һ. б.) телләрендәге әдәбият, һәм чит ил телләрендәге (инглиз, француз, немец һ. б.) әдәбият китап фондының аерым өлешен тәшкил итәләр.

Көтепханә фондының состав өлешләре менә шулар.

### § 2. ФӘННИ КИТАПЛАРНЫҢ ТИПЛАРЫ

Көтепханәдә булган фәнни әдәбият төрле белем тармакларын: философияне, иҗтимагый-политик мәсьәләләрне, табигать белемен, тел гыйлемен, тарихны һ. б. ларны эченә ала.

Фәнни китапларның, нинди максат белән һәм кемгә исәп тотып чыгаруларына карап, фәнни әдәбият китаплары да берничә типка аерылалар. Аларның иң әһәмиятлеләрен күрсәтеп үтик:

а) фәнни хезмәтләр (мәсәлән, В. И. Ленин „Россиядә капитализмның үсеше“, И. В. Сталин „Ленинизм нигезләре турында“);

б) фәнни-популяр әдәбият, ягъни фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен гадирәк телдә, популяр рәвештә бәян иткән китаплар (мәсәлән, Фламмарион К. „Популяр астрономия“, Нечаев И. „Элементлар турында хикәяләр“, Ферсман А. Е. „Кызыклы минералогия“);

в) дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре (мәсәлән, Бархударов С. Г. „Рус теле грамматикасы“, Баранский Н. Н. „СССР ның физик географиясе“);

г) белешмәләр (мәсәлән, „Малая советская энциклопедия“, „Политик сүзлек“, „Русча-татарча сүзлек“);

д) директив материаллар җыентыклары (мәсәлән, „ВКП(б)—съездларның, конференцияләрнең һәм ҮК пленумнарының резолюцияләрендә һәм карарларында“; „Авыл хуҗалыгы буенча 1938—1941 елларда чыккан бик әһәмиятле карарлар“, „Партиянең матбугат турындагы карарлары“);

е) производство-инструктив характердагы әдәбият (мәсәлән, Лукьяненко Я. Ф. „Бөртекле сабан ашлыкларыннан ничек итеп югары уңыш алырга“, Азимов Г. И. „Ничек итеп күп сөт алырга“).

Фәнни әдәбиятның һәр бүлегендә үзенең аерым тип китаплары бар, мәсәлән, иҗтимагый-политик бүлектә гел диярлек брошюролардан торган агитация-масса әдәбияты бар (мәсәлән, Ярославский Ем. „Фашизм крестьяннарга нәрсә алып килә“), хәрби бүлектә—Совет Армиясенең уставлары һәм наставлениеләре (мәсәлән, „ЭККА пехотасының строй уставы“), техник бүлектә—патентлар, стандартлар, география бүлегендә—атласлар, география карталары.

Һәрбер бүлектә фәнни китапларның барлык типларын булдыруга омтылырга кирәк, шуның белән бергә агитация-масса һәм фәнни-популяр әдәбиятны сайлауга аеруча игътибар бирергә кирәк.

Фәнни һәм матур әдәбият китаплары кыенлык ягыннан бик төрле булалар. Кайбер китапларны югары белемле укучылар, белгечләр генә аңлый алалар, икенче-

төрлеләрен—уртача хәзерлекле, җидееллык мәктәп күләмендә белемнәре булган укучылар да аңлый алалар. Башлангыч белем генә алган, хәзерлекләре аз булган кешеләр өчен махсус китаплар да була.

Массовый көтепханәләр нигездә киң укучылар даирәсе аңлый алырлык китапларны туплыйлар. Ләкин, белгечләр өчен дә, шулай ук үзлекләреннән теге яки бу фән тармагын өйрәнергә теләүче укучылар өчен дә кирәкле бик әһәмиятле фәнни әсәрләр массовый көтепханәдә булырга тиешләр.

Массовый көтепханә хәзерлекләре аз булган, башлап укучыларның сорауларын һәм ихтыяҗларын исәпкә алырга, классикларның шулай ук хәзерге заман язучыларның махсус алар өчен чыгарылган повестьларын, хикәяләрен, агитация-масса брошюраларын, табигать белеме, тарих, география, авыл хуҗалыгы, хәрби эш һ. б. лар буенча аңлаешлы һәм кызыклы китаплар тупларга тиеш.

## § 3. МАССОВЫЙ КӘТЕПХАНӘЛӘРНЕ КОМПЛЕКТЛАУ ПРИНЦИПЛАРЫ

Массовый көтепханәләр халыкның киң катлауларына хезмәт күрсәтәләр. Мәктәп балалары, яшүсмер эшчеләр, өлкән яшьтәге эшчеләр, эшче хатын-кызлар, колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар, шәһәр һәм авыл интеллигенциясе һ. б. аның укучылары була алалар. Бу укучыларның таләпләре бик төрле була, шунлыктан массовый көтепханә, махсус көтепханә шикелле, әдәбиятны бер-ике өч белем тармагы буенча туплау белән генә чикләнә алмый.

Массовый көтепханәне комплектлаган вакытта әдәбиятны һәрьяклап системалы рәвештә туплый бару таләп ителә. Көтепханәдә:

1) барлык белем тармаклары (иҗтимагый, табигать фәннәре, тарих, техника һ. б. ш. лар) буенча китаплар тупларга кирәк;

2) һәрбер белем тармагы буенча шушы белем тармагына кердә торган төп мәсьәләләрне һәм темаларны яктырта торган әдәбият тупларга кирәк;

3) һәрбер белем тармагы буенча төрле максатлар өчен кирәкле төрле типтагы китаплар—фәнни-тикшеренү эшләре өчен (фәнни әсәрләр); укыту

занятиеләре өчен (укыту ярдәмлекләре); үзлегеңнән белем алу өчен (популяр әдәбият); белешмәләр алу өчен (белешмә әсәрләр) һ. б. тупларга кирәк;

4) һәрбер белем тармагы буенча, укырга яңа гына башлаучылар өчен аңлаешлы иң ансат китаплардан алып, белгечләр өчен билгеләнгән иң катлаулы китапларга кадәр, кыенлык дәрәҗәсе төрлечә булган китаплар тупларга кирәк.

Китапларны шул рәвешчә туплаганда массовый көтепханә киң укучылар даирәсенең төрле-төрле таләпләрен канәгатьләндерә алачак. Нинди генә фән тармагы белән кызыксынмасыннар, китапларны нинди генә максатлар өчен (үзлегеңнән белем алу, белешмә һ. б.) сорамасыннар, укучылар үзләренең хәзерлек дәрәҗәләренә яраклы китапларны көтепханәдә табарлар.

Массовый көтепханәнең китап фонды ватаныбыз алдында торган бик әһәмиятле бурычларны: хәрбиоборона, хуҗалык-политик, культура-агарту бурычларын чагылдырырга тиеш. Халык хуҗалыгын, культураны торгызу һәм тагын да үстерү буенча совет кешеләренең фидакарь эше, партия һәм хөкүмәт карарлары, халыкара хәл—көтепханә вакытында һәм регуляр рәвештә китаплар тупларга тиешле булган бик әһәмиятле темалар менә шулар. Агымдагы политик тормышны тирәнтен һәм дөрес аңлауны марксизм-ленинизм теориясе бирә, шуннан көтепханәнең бурычы—марксизм-ленинизм классикларының—Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен мөмкин кадәр тулырак туплаудан гыйбарәт.

Массовый көтепханәнең китап фонды безнең совет иле алдында торган гомуми бурычларны гына түгел, бәлки ул хезмәт күрсәтә торган өлкәнең, районның, шәһәрнең, авылның үз бурычларын да чагылдырырга тиеш. Шәһәр көтепханәсе өчен китап сайлау—бер эш, авыл көтепханәсе өчен китап сайлау—икенче эш. Билгеле, һәр көтепханәгә, шәһәр көтепханәсенә дә, шулай ук район яки авыл көтепханәсенә дә бертигез дәрәҗәдә кирәк булган китаплар бар. Ләкин авыл көтепханәсенә кирәк булып һәм күп кешеләр тарафыннан укылып та, шәһәр көтепханәсендә тик ятачак һәм файдаланылмаячак китаплар да бар. Һәм әгәр дә без төрле авыл көтепханәләренә йөрүче укучыларның сорауларын чагыштырып карасак, ул чагын-

да аларда да бер үк төрле китапларны гына сорамаганлыкларын күрербез. Укучыларның теге яки бу китап белән кызыксынулары, андый китапларга сораулар күбесенчә җирле үзенчәлекләргә, район хуҗалыгының характерына, халыкның составына бәйләнгән була. Укучыларның соравында районның үткән тарихы да, район алдында торган яңа хуҗалык бурычлары да, халыкның культура дәрәҗәсе дә, аның милли составы да чагыла. Һерым китапларны сайлаганда һәм тулаем китап фондын комплектлаганда менә шуларның барысын да исәлкә алырга кирәк.

**Көтепханәне план буенча тулыландыра торырга кирәк.** Көтепханә өчен нинди дә булса китапларның гомумән җыелмасы гына түгел, бәлки совет укучысы өчен бик әһәмиятле һәм кирәкле булган китапларның сайлап тупланган җыелмасы кирәк.

Һәрбер көтепханә, беренче чиратта, төп әдәбиятны, „китап ядросы“ дип йөртелгән әдәбиятны, беренче дәрәҗәдә әһәмиятле булган китаплар минимумын сайлап җыюга омтылырга тиеш.

„Китап ядросын“ ничек сайлап җыярга соң? Мәсәлән, авыл көтепханәсе өчен нинди әдәбиятның төп әдәбият икәнлеген каян белергә соң?

Бу сорауга „Авыл көтепханәләре өчен төп әдәбиятны күрсәткеч“ җавап бирә. Бу күрсәткеч СССР ның В. И. Ленин исемендәге һәм Ленин орденлы Дәүләт көтепханәсе тарафыннан төзелеп Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы тарафыннан басылган һәм авыл көтепханәләренә тәкъдим ителгән һәм ул ике меңләп китапны эченә ала.

Көтепханәне комплектлаганда төп әдәбиятны күрсәткеч (яки типовой каталог белән) кулланып эш итәргә кирәк. Яңа оештырыла яки яңадан торгызыла торган көтепханә күрсәткечтә тәкъдим ителә торган китапларның барысын да берьюлы, бер алымда гына ала алмас. Бу китаплар үткән елларда чыкканлыктан, китап базарында аларны табу кыен булачак. Ләкин бу хәл көтепханә эшчесен хәйран калдырырга тиеш түгел. Бик әһәмиятле китаплар яңадан, кабаттан басылып чыгалар һәм, әгәр дә сатуда иске басмалары юк икән, бу китапларның яңа басмаларын алуга исәп тотарга мөмкин.

Башта менә мондый эшләрне эшләү бик әһәмиятле: көтепханә фондында булган китапларны төп әдәбият

күрсәткече белән чагыштырып, күрсәткечтә тәкъдим ителеп тә китап фондында булмаган китапларны белергә һәм билгегә алырга кирәк. Җитешми торган китапларның исемлеген язып алгач, китапханә эшчесе киләчәктә үзенең бөтен көчен шул китапларны табуга куя. Бу эшкә актив караганда, китапханә фонды төп әдәбият белән тулылана барачак һәм акрынлап күрсәткечтә тәкъдим ителгән составка якыная барачак. Шуның белән бергә, моннан өч ел элек чыккан күрсәткечнең соңгы елларда чыккан китап продукциясен чагылдырмавын истә тотарга кирәк. Шуңа күрә китапханәләрне комплектлаганда күрсәткечкә өстәмә итеп 1942 елдан соң чыккан библиографик ярдәмлекләрдән дә файдаланырга кирәк.

## § 4. КИТАПХАНӘ ЭШЧЕСЕ КИТАПЛАРНЫ НИЧЕК ӨЙРӘНӘ

Китапларны дөрес сайлап җыю өчен, аларны белергә кирәк. Китапларны белү—китапханә эшчесенең эше уңышлы булуда иң әһәмиятле шартларның берсе. Китапларны белүгә аларны көн саен системалы рәвештә өйрәнә бару юлы белән ирешелә. Ләкин бу вакытта шундый бер кыенлык килеп чыга: китапханәдә меңнәрчә китап бар, һәр елны уннарча мең исемдә яңа китаплар чыгып тора. Китапханә эшчесе китапларны ничаклы гына тырышып укымасын, ул барлык яңа чыга торган китапларны гына түгел, хәтта китапханәдә булганнарын да укып чыга алмас. Шунлыктан китапханә эшчесенә, китапларны тоташ укудан тыш, аларны өйрәнүнең бүтән методларын да кулланырга туры килә. Билгеле, аеруча әһәмиятле булган китапларны, һәр бүлектәге яхшы китапларны китапханә эшчесе төпле рәвештә өйрәнә, укый һәм кат-кат укый, ләкин күп китаплар белән китапханә эшчесе аларны карап чыгу һәм сайлап уку юлы белән таныша.

Китапны караганда китапханә эшчесе иң элек аның титул битенә, ягъни тышлыктан соңгы беренче биткә игътибар итә. Титул битендә түбәндәгеләр була: авторның фамилиясе, китапның исеме, издательство исеме, китап басылган урын һәм ел, кайвакытларда—подзаголовоклар һәм надзаголовоклар да була.

Авторның фамилиясе, әгәр дә ул китапханә эшчесенә таныш булса (мәсәлән, И. Павлов, Т. Лысенько, И. Папанин), мәгълүм дәрәҗәдә китапның характерлый,

аның фәнни яки художество өстенлекләре турында сөйли.

Фәнни китапларның исемнәре аларның эчтәлеген азмы-күпме төгәл билгелиләр, мәсәлән, „Немец илбасарларны рус халкы ничек кыйнады“ (тарихи эчтәлекле брошюра), „Кешеләр санарга ничек өйрәнделәр“ (математика тарихы китабы) һ. б.

Матур әдәбият әсәрләренең исемнәре дә аларның эчтәлеген бирәләр, ләкин бик ул кадәр ачык итеп түгел, бәлки образлы формада, мәсәлән, Н. Островский „Корыч ничек чыныкты“ (гражданнар сугышы елларында яшь буынның чыныгуы турында.)

Подзаголовок китапның эчтәлеген аңлатып бирә (мәсәлән, А. Н. Толстойның „Икмәк“ исемле повестеның „Царицын оборонасы“ дигән подзаголовогы бар), яки әсәрнең формасын билгели (доклад, речь, роман, поэма һ. б.), яки китапның вазифасын күрсәтә (башлангыч мәктәпнең 3 нче һәм 4 нче класслары өчен дәреслек, инженерлар һәм техниклар өчен белешмә китабы, үзлекләреннән белем алу белән шөгыльләнүчеләр өчен ярдәмлек), яки китап кемнәргә карата чыгарылган булса, укучыларның шул группасын билгели (урта яшьтәге балалар өчен эшләнгән, яшьләр өчен повесть һ. б.).

Подзаголовокта китап редакторының яки тәрҗемәчесенең фамилиясе, ничәнче (икенче, өченче һ. б.) басмасы икәнлеге күрсәтелә. Китап турында: аның эчтәлеге, формасы, кемнәр өчен чыгарылганлыгы турында фикер йөртү өчен бу мәгълүматларның барысы да бик әһәмиятле.

Күп кенә совет издательстволарының исемнәре китапның нинди өлкәдәге белем тармагына караганы турында сөйлиләр: Дәүләт политик әдәбият издательствосы (Госполитиздат), Дәүләт техник әдәбият издательствосы (Гостехиздат), Воениздат, Профиздат, Сельхозгиз һ. б.

Детгиз, „Молодая гвардия“ кебек издательстволарның исемнәре китапның кемнәргә карата (балалар өчен, яшьләр өчен) чыгарылуын күрсәтә, Учпедгиз (РСФСР Мәгариф министрлыгы каршындагы Дәүләт укыту-педагогика әдәбияты издательствосы) һәм Гослитиздат (Дәүләт матур әдәбият издательствосы) китапның нинди әдәбият төренә (укыту әдәбияты, матур әдәбият) керүен күрсәтә.

Китапның кайчан чыкканын белү бик әһәмиятле: мәгълүм хәлләрдә чыккан елына карап китапның искерү дәрәҗәсе турында фикер йөртергә була.

Китапның авторы, исеме, издательствосы, басылган елы—китапны билгеле бер басма итеп характерлый торган бик әһәмиятле билгеләр булып санала. Төрле исемлекләр төзегәндә, аерым китапларны күрсәткәндә әлбәттә китап турындагы шушы мәгълүматларның барысын да китерергә кирәк.

Кайчакта титул битенең иң башында, авторның фамилиясе өстендә надзаголовок бирелә: китапның нинди сериягә керү исеме (мәсәлән, „Правда“ издательствосы сериясе—„Фронт тормышыннан“, Детгиз сериясе—„Мәктәп көтепханәсе“, „Советский писатель“ издательствосы сериясе—„Шагыйрь көтепханәсе“, Гослитиздат сериясе—Тарихи романнар һ. о.), яки китапны басарга әзерләгән фәнни учреждениенең исеме (Маркс—Энгельс—Ленин институты, СССР Фәннәр Академиясе һ. б.) языла.

Титул битенең икенче ягында яки китапның соңгы битендә китапны чыгаруга бәйләнешле мәгълүматлар урнаштырыла: җаваплы редакторы кем, китап нинди типографиядә басылган, күпме данәдә басылган, басарга кайчан кул куелган, басма табакларда китапның күләме нинди, басма табакта күпме хәреф һ. б. ш. Басылган данәләр саны тираж дип йөртелә. Китапның тиражына карап аның ни дәрәҗәдә массовый булуы турында хөкем итәргә була. Тар даирә укучылар өчен чыгарыла торган китаплар кечкенә тираж белән басылалар. Беренче дәрәҗәдә әһәмиятле һәм киң масса арасында таратуга исәп тотып чыгарылган аеруча мөһим китаплар берничә йөз мең, ә кайчакта миллионнарча данә тираж белән чыгарылалар.

Китапның титул битен карап чыгу китап турында тәмам нигезле йомгак ясауга һәрвакытта да мөмкинлек биреп бетерми. Китап белән җентекләбрәк танышырга, аның текстын, рәсемнәрен, кушымталарын да карап чыгарга кирәк. Китапның төрле өлешләреннән аеруча игътибарны тарта торганы сүз башы белән эчтәлек була. Гадәттә сүз башында китап турында күп кенә мөһим мәгълүматлар: аның ничек төзелүе, кемнәр өчен чыгарылуы, теге яки бу мәсьәләнең нинди күләмдә тикшерелүе һ. б. турында мәгълүматлар бирелгән була. Кайвакытларда сүз башында китапка рекомендация бирелә,

аның яхшы яклары күрсәтелә. Китаптан дөрес файдалану өчен, көтепханә эшчесенә боларның барысын да белү бик мөһим.

Эчтәлек бүлекләрнең исемлеген бирә, шул бүлекләрнең исемнәренә карап китапның эчтәлеген яхшырак төшенеп була.

Сүз башын һәм эчтәлекне караганнан соң көтепханә эшчесе сайлап-сайлап текстны укуга керешә һәм китапта иң әһәмиятле урыннарын тотып алырга тырыша. Сайлап-сайлап уку китапның язылыш рәвеше белән танышырга һәм аның укырга кыенлыгы яки ансатлыгы, ни дәрәҗәдә кызыклы итеп язылганлыгы турында нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирә.

Китап белән эш иткәндә аның басылыш рәвеше дә: хәрефе, рәсемнәре, тышлыгы, китапка бирелгән һәртөрле кушымталар—карталар, диаграммалар, кыен сүзләрнең сүзлекләре һ. б. лар да бик әһәмиятле урын тоталар.

Эре хәреф белән басылган китап гадәттә яңа укый башлаган кешеләр өчен чыгарыла.

Яхшы, ачык басылган рәсемнәр китапны җанландыралар, аның материалын күргәзмәлерәк итәләр, аның эчтәлеген яхшырак үзләштерергә ярдәм итәләр.

Бизәп эшләнгән тышлык укучының китапка игътибарын тарта һәм анарда аны карау һәм аның белән танышу теләген тудыра.

Көтепханә эшчесе китапның басылыш рәвешен исәпкә ала һәм бер үк китапның төрле басмаларыннан, хакы көтепханә өчен бик кыйммәт булмаса, яхшырак итеп басылган басмасын алуны яхшырак күрә.

Китапны карап һәм аны сайлап-сайлап укып, көтепханә эшчесе китап турында кирәкле белемнәрнең минимумын алырга, китапка бәйләнеше булган күп кенә сорауларга үзенә үзе җавап бирергә омтыла. Китап турында иң кирәкле мәгълүматлар түбәндәгеләр:

1. Автор (редактор; тәрҗемә китап булганда — тәрҗемәче).
2. Китапның исеме (һәм ул нәрсә турында сөйли).
3. Китап кайда, кайчан һәм кем тарафыннан чыгарылган.
4. Китап эчтәлеге буенча нинди белем тармагына караган (мәсәлән, астрономиягә).
5. Китапта нәрсә турында сөйләнә (мәсәлән, кояш тотылу турында).
6. Китап ничек язылган (кыенмы яки ансатмы, катлаулымы яки гадиме, кызыклымы яки түгелме).
7. Китап әдәбиятның кайсы тибына керә (фәнни-популяр, уку-укыту, белешмә һ. б.).

8. Китап нинди укучылар өчен чыгарылган.

9. Китап ничек басылган, аның басылыш рәвеше нинди.

10. Китап көтепханәгә кирәклеме, бу көтепханәдә аңардан җитәрлек дәрәҗәдә файдаланырга мөмкинме.

Китапны өстән-өстән генә карап чыгу бу сорауларның барысына да җавап алырга мөмкинлек биреп бетерми. Шуның өстенә китапның идея-политик әһәмияте, аның фәнни яки художестволы яклары кебек мөһим мәсьәләләр җавапсыз кала. Бу мәсьәләләрне хәл итү өчен китапның эчтәлегенә бик төпле итеп критик анализ ясау таләп ителә.

Шуңа күрә, көтепханә эшчесе, китапның үзе белән танышу өстенә, критика һәм рекомендация библиографиясе материалларыннан—рецензияләрдән, күзәтүләрдән һ. б. лардан файдаланырга тиеш.

## 5. КИТАПЛАРНЫ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ КӨТЕПХАНӘНЕ КОМПЛЕКТЛАУ ӨЧЕН БИБЛИОГРАФИЯДӘН НИЧЕК ФАЙДАЛАНЫРГА

СССР да ел саен ун меңнәрчә исемдә китаплар, брошюралар, журналлар һәм бүтән төрле матбугат әсәрләре чыгарыла. Шул кадәре күп санда чыккан басма әсәрләрне өелеп бетерү бик кыен һәм үткән елларда басылып чыккан гаять күп китапларны истә тоту тагын да кыенрак. Бу эштә укучыга һәм көтепханә эшчесенә библиография (сүзнең туры мәгънәсендә—китап тасвиры) ярдәмгә килә. Библиография басылып чыккан китапларның бөтенесен исәпкә ала, аларны белем тармаклары буенча системага сала, китапларга бәя бирә, бик яхшы китапларны аерып күрсәтә һәм аларны киң укучылар даирәсенә тәкъдим итә. Матбугат әсәрләрен теркәү эше белән Бөтенсоюз китап палатасы шөгыльләнә. Бу палата күп кенә библиографик журналлар чыгара: „Китап елъязмасы“ (СССР да чыга торган барлык китаплар шунда теркәлә), „Журнал мәкаләләре елъязмасы“ (биредә иң әһәмиятле журналларга кергән мәкаләләр теркәлә) һәм „Газета мәкаләләре елъязмасы“ (биредә үзәктә һәм урыннарда чыга торган иң әһәмиятле газеталарның мәкаләләре теркәлә). Библиографик журналлардан тыш Бөтенсоюз китап палатасы библиографик күрсәткечләр, ягъни төрле мәсьәләләр буенча әдәбият исемлекләре басып чыгара.

Библиографик материалларны иң зур көтепханәләр төзи: СССР ның В. И. Ленин исемендәге һәм Ленин орденлы Дәүләт көтепханәсе, М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге һәм Хезмәт Кызыл Байрак орденлы Дәүләт публичный көтепханәсе, Дәүләтнең публичный тарихи көтепханәсе һ. б. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы массовый көтепханәләр өчен библиографик ярдәмлекләр төзи һәм бастырып чыгара, шулай ук дәүләтнең зур публичный көтепханәләренең библиографик хезмәтләрен бастырып чыгара.

Китапларны өйрәнүдә библиография көтепханә работникларына бәя биреп бетергесез ярдәм итә. Библиографик чыганаклар буенча без яңа китапларның чыкканын белеп алабыз, аннотацияләр буенча аларның эчтәлекләре белән танышабыз.

Аннотация (туры мәгънәсе: заметка, искәрмә) — китапның кыскача характеристикасы ул; анда китап турында иң кирәкле белешмәләр: автор, китапның темасы яки эчтәлеге, нинди укучыга каратып чыгарылганлыгы языла.

**Мисал:**

**Горбатов, Б.**

**Буйсынмас кешеләр** (Тарас семьясы). Татгосиздат, 1944 ел, 138 бит.

Ватанга бирелгән һәм дошманга буйсынмаучы совет кешеләре турында повесть. Вакыйга Украинаның немецлар тарафыннан оккупацияләнгән зур промышленность үзәгендә бара. Потомственный эшче Тарас Яценко заводның карт эшчеләрен немецларга каршылык күрсәтү өчен берләштерә, үзенең подпольеда партия оештыручысы булып эшли торган улына оккупантларга каршы көрәштә ярдәм итә. Тарасның сөекле кызы — комсомолка Настя немец палачлары кулыннан һәлак була. Аның үлүе Тарасның ачуын тагын да ныграк үстерә һәм Кызыл Армия якынлаша башлагач, ул кулына корал алып явыз илбасарларны шәһәрдән куа башлый.

Аннотациянең кыскалыгы китапка тулы бәя бирергә мөмкинлек бирми, ләкин аны тәкъдим итү мөмкинлеген бирә. Массовый көтепханә работниклары һәм укучылар өчен мондый аннотацияләр бик кирәк.

Китапка тагын да тулырак характеристиканы рецензия бирә. Анда тәнкыйть күзлегеннән чыгып китапка киң бәя бирелә, аның яхшы һәм кимчелекле яклары тулы итеп күрсәтелә.

Күп газеталарда һәм журналларда тәнкыйть, библиография бүлекләре бар. Шуның белән бергә махсус журналларда шул журнал багышланган белем тармагыннан булган китапларга рецензияләр басыла. Иҗтимагый-политик китапларга һәм брошюраларга карата язылган рецензияләрне „Правда“, „Известия“ „Культура и жизнь“ кебек газеталардан, „Большевик“, журналыннан һ. б. эзләргә; тарихи әдәбиятка рецензияләрне — „Исторический журнал“ дан; матур әдәбият әсәрләренә рецензияләрне — „Знамя“, „Новый мир“, „Октябрь“, „Совет әдәбияты“ журналларыннан, „Правда“, „Известия“, „Литературная газета“ битләреннән эзләргә кирәк.

Мәсәлән, „Правда“ газетасында 1943 елның 24 сентябрендә Джон Б. Пристлиның „Грэтлида караңгылык“ дигән повестена Д. Заславскийның рецензиясе басылган иде.

Темалары буенча якынрак булган байтак кына басма әсәрләрне яки бертөсле әсәрләр сериясен эченә алган рецензия — тәнкыйть-библиография күзәтүе дип атала. П. Фатеевның „Тормыш һәм үлем турында, нәфрәт һәм мәхәббәт турында“ дигән мәкаләсе мона мисал булып хезмәт итә ала („Большевик“ журналы. 1942 ел. № 15). Монда „Правда“ издательствосы тарафыннан чыгарыла торган „Фронт тормышыннан“ дигән хикәяләр һәм очерклар сериясенә күзәтү бирелгән. С. Ермолаевның 1942 елны „Спутник агитатора“ журналының 18 нче номерында басылган күзәтүе дә шул ук сериягә багышланган.

Массовый китапханәләр өчен аннотация төсендә язылган рекомендация күрсәткечләре, әдәбият исемлекләре, рекомендация каталоглары бик әһәмиятле.

Мәсәлән, „Ватан сугышында хәрби китап“ дигән күрсәткечтә (массовый китапханәләр өчен төп әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт китапханә-библиография издательствосы. 1942 ел. 88 бит) массовый китапханәләргә тәкъдим ителгән 322 китап китерелгән. Китапларның күбесе аннотация белән тәэмин ителгән. Ахырда ярдәмче күрсәткечләр бирелгән: исемнәр күрсәткече, серияләр күрсәткече. Бу күрсәткечләр библиографик ярдәмлектән файдалануны шактый җиңеләйтәләр.

Үзлегеннән белем алуга ярдәмгә багышланган библиографик күрсәткечләр системалы уку программалары, уку планнары, уку даирәләре

дип аталалар. Мондый күрсәткечләрдә гадәттә кереш мәкаләләр, уку турында методик киңәшләр, тәкъдим ителә торган китапларның үзлегеннән белем алу белән шөгыльләнүче кеше укырга тиешле булган тәртиптә язылган исемлекләре бирелә. Мәсәлән, „Астрономия“ шундый күрсәткечләр исәбенә керә. Үзлегеннән белем алу белән шөгыльләнүче өчен программа. Проф. К. Л. Баев төзегән. Проф. П. П. Паренаго редакциясендә. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940 ел. 32 бит.

Көтепханә эшчесе өчен библиографиянең зур әһәмияте бар: ул аңа әдәбиятны өйрәнүдә, китап фондын комплектлауда, укучыларга китаплар тәкъдим итүдә, китап күргәзмәләре оештыруда булышлык итә. Библиография—коммунистик тәрбиянең җитди коралы, көтепханә эшчесе аңардан тулысы белән файдаланырга тиеш.

Көтепханә эшчесе газеталарда һәм журналларда басыла торган рецензияләрне күзәтеп барырга, библиографик күрсәткечләрне һәм тәкъдим ителә торган исемлекләрне карап барырга тиеш. Нинди дә булса бер китапны тәкъдим итә торган рецензияне укыгач, көтепханә эшчесе бу китапны билгеләп ала: кәгазь кисәгенә яки карточкага китапның авторының фамилиясен һәм аның инициалларын, китапның исемен, подзаголовогын (булса), издательствосын, китапның чыккан урынын һәм елын, шулай ук рецензия басылган чыганакны (журналның исемен, елын, №, битләрен, рецензия авторының фамилиясен) язып ала.

Мисал

> Соболев, Леонид.
> Диңгез җаны. Хикәяләр.
> М. Госполитиздат. 1942. 416 бит.
> Рец.: „Пропагандист“ журналы. 1943. № 11—12. 41—43 бит.
> (Л. Кассиль. Совет сугышчыларының нык торучанлыгы һәм батырлыгы турындагы китап.)

Шундый карточкалардан көтепханә эшчесенә китап фондын комплектлауда ярдәм итә торган библиографик картотека төзелә.

Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы массовый көтепханәләргә тәкъдим ителә торган яңа

китапларга аннотацияле басма карточкалар басып чыгара.

Аннотацияле карточкалар түбәндәге төстә булалар:

**Сергеев, И.**

52
С. 32.

**Күк йозендәге гаҗәп күренешләр.** Б. А. Воронцов—Вельяминов редакциясендә. М. „Молодая гвардия" 1944, 30 бит. Рәсемнәре белән 1 сум (Табигать һәм кеше турында беседалар). 50 000 экз.

Массовый укучыга каратып чыгарылган популяр брошюра. Эчтәлеге: Җирнең формасы һәм галәмнең төзелеше турында борынгы халыкларда булган ялгыш карашлар. Күк йөзендәге аңлаешсыз күренешләрне (кояш һәм ай тотылуны, кометаларны һ. б.) аңлатырга маташканда юк-барга ышануларның килеп чыгуы. Кешелекне галәмнең төзелешен һәм күк йөзендәге күренешләрне дөрес, фәнни аңлауга алып килгән юллар. Кояш һәм Ай тотылу нәрсәдән була. Кометалар нәрсәләр алар. „Йолдызлар агылу"ны фән ничек аңлата. Күк кабагы ачылуның сере нәрсәдә. Салават күпере нәрсәдән була. Ялган кояшлар һәм күктәге балкып торган әвернәләр ничек хасил була. Миражлар ничек һәм нәрсәдән килеп чыгалар.

1. Галәм — төзелеш. 2. Күк йөзе механикасы.

Көтепханәнең бу карточкаларны алдыруы мәслихәт. Карточкаларда басылган аннотацияләр буенча көтепханә эшчесе яңа чыккан китаплар һәм брошюралар белән тиз таныша ала. Карточканың артына шушы китап турындагы рецензия басылган чыганакны язып куеп, көтепханә эшчесе карточканы библиографик картотека өчен файдалана ала.

## § 6. КӨТЕПХАНӘНЕҢ КИТАП ФОНДЫН НИЧЕК ӨЙРӘНЕРГӘ

Көтепханәне дөрес комплектлау өчен бөтен фондны, фондның бүлекләрен, аерым китапларны көн саен, системалы рәвештә өйрәнә торырга кирәк. Көтепханә фондын өйрәнгәндә ярдәмлекләр булып көтепханәнең инвентарь кенәгәләре, көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсе (дүртенче бүлекне кара), көтепханәнең статистик отчетлары, аның каталоглары (бишенче бүлекне кара) хезмәт итәләр. Ләкин фондны өйрәнү өчен системалы каталог, ягъни көтепханәдә булган һәм бү-

лекләр буенча аерып куелган китаплар исемлеге бик әһәмиятле.

Фондны өйрәнгәндә библиографик ярдәмлекләр зур булышлык итәләр.

Тулаем көтепханә фонды турында көтепханә эшчесенә нәрсәләр белергә кирәк соң?

Иң элек — фондның күләмен, ягъни көтепханәдә булган китаплар, журналлар һәм брошюралар санын белергә кирәк.

Бу сорауга җавапны көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсе бирә. Бу кенәгәдә әдәбиятның керүе һәм чыгуы исәпкә алына бара һәм булган китапларга, журналларга һәм брошюраларга йомгаклар ясала. Инвентарь кенәгәсе китапларның саны турындагы сорауга дөрес җавап бирми, чөнки ул, беренчедән, көтепханәдә булган брошюраларның барысын да эченә алмый, икенчедән, фондтан чыккан китапларны язудан гына гыйбарәт.

Көтепханәдә булган әсәрләрнең гомуми санын белеп алганнан соң, без аны укучылар саны белән чагыштырып карыйбыз һәм уртача алганда бер укучыга ничә китап туры килүен беләбез. Көтепханәнең нормаль эшләве өчен бер укучыга кимендә 5—6 китап булдырырга кирәк.

Укучыларның милли составын да исәпкә алырга кирәк һәм, әгәр дә алар арасында рус милләтеннән бүтән милләт хезмәт ияләре булса, көтепханәдә шул милләтләр телендә язылган китаплар барлыгын тикшерергә кирәк. Мондый китаплар булмаган хәлдә аларны алу чарасын күрергә кирәк.

Көтепханә фондында булган әсәрләрнең гомуми санынннан тыш, аерым рәвештә китаплар, журналлар һәм брошюралар санын белергә кирәк.

Агитация-масса әдәбиятына керә торган брошюраларны вакытында һәм күпләп алырга кирәк. Шуның белән бергә агымдагы мәсьәләләр буенча брошюралар шактый тиз искерәләр, шунлыктан брошюралар фондын әледән-әле карый торырга һәм аны искергән әсәрләрдән арындырырга кирәк.

Бу вакытта РСФСР Наркомпросының „Көтепханәдән алынырга тиешле искергән әдәбият“ дигән күрсәткече буенча эш итәргә кирәк. Исемлек № 1 (М. РСФСР Наркомпросы. 1941 ел. 46 бит) һәм РСФСР Министрлар Советы каршындагы культура-агарту эшләре коми-

тетының шуннан соңгы күрсәтмәләре буенча эш итәргә кирәк.

Искергән китапларны шушы ярдәмлек нигезендә аерып алганнан соң, көтепханә эшчесе аларның исемлеген төзи һәм шул исемлекне культура-агарту эшләренең өлкә бүлегенә раслатырга җибәрә. Исемлек раслангач, аерып алынган әдәбиятны көтепханә макулатура итеп „Союзутиль“ оешмаларына тапшыра. Китапларны исемлектән чыгару түбәндәге формада язылган акт белән рәсмиләштерелә:

## АКТ

**РСФСР НКП ның 194.........ел.........№..........приказы буенча китапларны исемлектән чыгару турында,...........................көтепханәсендәге** искергән әдәбиятны исемлектән чыгару турындагы бу акт................ данәдә һәм.....................сум...............тиенлек сумага язылды.

| Тәртип № | РСФСР НКП приказы исемлегендәге тәртип № | Авторы һәм китапның исеме | Ничәнче басма | Басылган урыны | Издательствосы | Басылган елы | Инвентарь номеры | Бүлеге | Бәясе | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | сум | тиен | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

*Көтепханә мөдире (директоры) имзасы*..........................................

*Актны раслаган кеше имзасы һәм должносте*

Раслау датасы.............................................

Фондны характерлау өчен китапларның бүлекләр буенча бүленешен белү бик мөһим: иҗтимагый-политик, табигать фәне, авыл хуҗалыгы, техник, матур әдәбият һ. б. ш.

Бүлекләрне чама белән менә мондый нисбәттә тотарга мөмкин: иҗтимагый-политик бүлек (философияне, тарихны, географияне, хәрби эшне кертеп)—фондның өчтән бер өлеше; фәнни-техник бүлек (математика, табигать белеме, медицина, авыл хуҗалыгы, техника)—фондның өчтән бер өлеше; матур әдәбият бүлеге (әдәбият белеме һәм тел белеме белән бергә)—фонд-

ның өчтән бер өлеше. Билгеле, китап фондының төп өч бүлегенең күрсәтелгән нисбәте төрле көтепханәләр өчен беркадәр башкачарак та булуы мөмкин.

Инде йомгаклар ясыйк һәм көтепханә фонды турында аны дөрес комплектлау өчен кирәкле мәгълүматларны санап үтик.

1. Фондта күпме китап бар?

2. Китаплар бүлекләр буенча ничек бүленәләр?

3. Бу районда яшәүче рустан башка милләтләргә хезмәт күрсәтү өчен китаплар бармы? Рус милләтеннән булмаган халыкның саны белән чагыштырганда бу әдәбият җитәрлекме?

4. Көтепханәгә йөрүче бер укучыга ничә китап туры килә?

5. Брошюралар көтепхане фондының нинди өлешен тәшкил итәләр?

6. Искергән брошюралар фондтан чыгарылганнармы?

Шушы сорауларның һәрберсенә җавап бирү мәгълүм дәрәҗәдә көтепханә фондына характеристика бирә һәм комплектлау буенча киләчәктә нинди эшләр алып барырга кирәклекне күрсәтә.

Ләкин, фондка характеристика бирү күбесенчә саннардан гына гыйбарәт булган мондый гомуми мәгълүматларга гына нигезләнә алмый. Фондны эчтәлеге буенча өйрәнү белән шөгыльләнергә, һәр бүлек буенча китапларның конкрет составы белән танышырга кирәк. Моның өчен китапларның үзләрен карап чыгарга һәм библиографиядән киң файдаланырга кирәк.

Көтепханә фондын эчтәлеге буенча өйрәнеп, без аның төп бүлекләрен карап чыгабыз һәм һәр бүлекнең массовый көтепханәгә кирәкле әдәбият белән тәэмин ителешен тикшерәбез. Иң элек без иҗтимагый-политик бүлектәге китаплар составы белән танышабыз. Бу вакытта без түбәндәге әдәбиятның ничаклы тулы итеп җыелганлыгына аеруча игътибар бирәбез:

а) Марксизм-ленинизм классикларының төрле басмалардагы әсәрләре (К. Маркс һәм Ф. Энгельс „Әсәрләре“, К. Маркcның һәм Ф. Энгельсның „Ике томлык сайланма әсәрләре“, В. И. Ленин „Әсәрләре“, В. И. Ленинның „Ике томлык сайланма әсәрләре“, И. В. Сталинның „Ленинизм мәсьәләләре“, 11 нче басмасы; марксизм-ленинизм классикларының массовый тираж белән чыккан аерым әсәрләре).

б) Марксизм-ленинизм классиклары турында биографик әдәбият (мәсәлән, „Ленин Владимир Ильич“. Тормышы һәм эше турында кыскача очерк. Татгосиздат. 1947 ел. „Иосиф Виссарионович Сталин“ (кыскача биография). Татгосиздат. 1947 ел), И. В. Сталин „Ленин турында“. Татгосиздат. 1947 ел).

в) ВКП(б) тарихы буенча әдәбият—„ВКП(б) тарихы. Кыскача курс, Ленин В. И. һәм Сталин И. В. „Партия төзелеше турында“ (ике томлык), ВКП(б) программасы һәм уставы, ВЛКСМ программасы һәм уставы. Берия Л. „Закавказьедагы большевистик оешмалар тарихы турындагы мәсьәләгә карата“ (6 нчы басма), большевиклар партиясенең бик күренекле эшлеклеләре турында биографик әдәбият.

г) Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбият.

Сталин И. В. „Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында“. 5 нче басма. Казан. Татгосиздат. 1946 ел. Сталин И. В. „Бөек Октябрь социалистик революциясенең 27 еллыгы“. Казан. Татгосиздат. 1944 ел.

Кызыл армиянең җиңүләре турындагы, Советлар Союзы геройлары турындагы, Москваны, Ленинградны, Одессаны, Севастопольне, Сталинградны героик саклаучылар турындагы, халык өчен үч алучы партизаннар турындагы, безнең герой яшьләребез (Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина һ. б.) турындагы китаплар.

Тылдагы эшчеләрнең, колхозчыларның, интеллигенциянең хезмәт геройлыгы турындагы әдәбият. Фашист илбасарларның ерткычлыклары турындагы китаплар (чит ил эшләре халык комиссары В. М. Молотов ноталары, Ярославский Ем. „Фашизм крестьяннарга нәрсә алып килә“ һ. б.). Гитлерчылар тарафыннан оккупацияләнгән илләрдәге „яңа тәртип“ турындагы, бу илләр халыкларының явыз немецлар изүенә каршы көрәшүе турындагы китаплар. Азатлык сөюче халыкларның гитлерчыларга каршы бердәм фронты турындагы китаплар.

д) СССР да социалистик төзелешнең казанышлары турындагы, совет строеның бөек көче турындагы, СССР халыкларының дуслыгы турындагы, Сталин Конституциясе турындагы, Сталинчыл бишьеллыклар турындагы китаплар.

е) Партия һәм хөкүмәт карарлары.

ж) Агитаторларга, пропагандистларга, докладчыларга ярдәмгә чыгарыла торган әдәбият („Беседаны ничек үткәрү турында агитаторга истәлек“ һ. б.).

з) Белешмә әдәбият (мәсәлән: сүзлекләр).

Хәрби-оборона әдәбиятының зур әһәмияте бар. Бу бүлекне карап чыкканда без всевобуч командирларына һәм сугышчыларына ярдәмгә чыгарылган әдәбиятка, аерым гаскәр төрләре турындагы әдәбиятка, Совет Армиясенең уставларына һәм наставлениеләренә, һава һөҗүменнән, химия һөҗүменнән оборона һәм санитария оборонасы буенча әдәбиятка, хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның семьяларына пособиеләр, пенсияләр һәм льготалар турындагы әдәбиятка аеруча игътибар бирәбез.

Укучылар тарихи әдәбиятны күп сорыйлар. Бу бүлектә беренче чиратта борынгы, урта һәм яңа тарих буенча дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләре, СССР тарихы буенча, рус халкының героик тарихы турында, бигрәк тә рус халкының немец илбасарларга каршы көрәше турында дәреслек һәм популяр әдәбият; безнең бөек бабаларыбыз турында (мәсәлән, Осипов К. „Суворов“, Брагин М. „Полководец Кутузов“ һ. б.), рус халкы культурасының һәм татар халкы культурасының күренекле вәкилләре турындагы әдәбият булырга тиеш.

Район һәм авыл көтепханәләрендә авыл хуҗалыгы әдәбиятын яхшылап җыярга кирәк. Биредә колхоз производствосын оештыру буенча китаплар, кырчылык, терлекчелек, түтәл бакчачылыгы, җимеш бакчачылыгы, болынчылык һ. б. буенча шушы район хуҗалыгының гомуми юнәлешенә һәм аның җирле шартларына яраклы популяр әдәбият; авыл хуҗалыгын механикалаштыру буенча, тракторларны, авыл хуҗалыгы машиналарын һәм коралларын тәрбияләп йөртү турындагы әдәбият булырга тиеш (мәсәлән, Берман, „Трактор эше әлифбасы“). Колхоз председательләре өчен, бригадирлар өчен, ат караучылар, сыер савучылар, умартачылар һ. б. өчен белешмә әдәбият сайлауга аеруча игътибар бирергә кирәк.

Табигать фәне белемнәрен пропагандалауның зур әһәмияте бар.

1944 елда ВКП(б) Үзәк Комитеты „Фәнни-агарту пропагандасы оештыру турында“ карар кабул итте.

„ВКП(б) Үзәк Комитеты үзенең карарында табигать фәннәре белемнәрен пропагандалауның хәзерге шартларда киң хезмәт ияләре катлауларының культура дәрәҗәсен тагын да күтәрү һәм культурасызлык, юк-барга ышанулар һәм хорафатлар калдыкларын бетерү эшендә аеруча әһәмиятле урын алганлыгын күрсәтеп үтте" („Пропагандист" журналы. 1944 ел. № 18. 5 бит).

Фәнни-агарту пропагандасы бурычларын исәпкә алып, көтепханәнең массовый популяр фәнни әдәбият белән, мәсәлән: астрономиядән (Баев һәм Шишаков китаплары һ. б.), физикадан (Перельман Я. „Кызыклы физика" һ. б.), химиядән, геологиядән, минералогиядән, биологиядән (Тимирязев К. А. „Дарвин теориясе турында кыскача очерк", Югов „К. А. Тимирязев", Поль де Крюи „Микроб аулаучылар" һ. б.), кешенең барлыкка килүе турында (М. А. Гремяцкий китаплары), ботаникадан, зоологиядән массовый популяр әдәбият белән тәэмин ителгәнлеген тикшерергә кирәк. „Молодая гвардия" издательствосының „Табигать һәм кеше турында беседалар" дигән сериясенә кергән китаплар белән көтепханәне тәэмин итү бигрәк тә әһәмиятле.

Һәрбер массовый көтепханәдә медицина әдәбиятын булдырырга кирәк. Әлбәттә врачларга гына кирәкле махсус әсәрләрне генә түгел, бәлки кеше тәненең төзелеше һәм тормышы турында, гигиенадан һәм санитариядән, йогышлы авырулар һәм аларга каршы көрәш чаралары турында, балаларны тәрбияләү турында, балалар авырулары, аларны булдырмау һәм дәвалау чаралары турында массовый популяр китаплар булдырырга кирәк.

Физкультура-спорт әдәбиятын булдыруга игътибар бирергә, көтепханә фондында гимнастикадан, спортның төрле төрләре буенча (йөгерү, йөзү, чаңгы спорты һ. б.), бик күп таралган спорт уеннары (футбол, баскетбол һ. б.) турында, шахмат һәм шашка турында китапларның барлыгын-юклыгын тикшерергә кирәк

Массовый көтепханә техника тарихыннан популяр әдәбият белән, электротехника, авиация, автомобиль эше, радиотехника китаплары белән, файдалы казылмаларны чыгару турында, машиналарның төзелеше һәм эшләве турында, хәзерге заман техникасының казанышлары, техниканың сугыштагы роле һ. б. турында

популяр әдәбият белән тәэмин ителергә тиеш. Массовый профессия эшчеләре өчен ярдәмлекләр һәм укучыларның һөнәр белемен үстерү өчен кирәк булган производство-техника әдәбияты булдыруга аеруча игътибар бирергә кирәк.

География бүлеген өйрәнгәндә без көтепханәдә СССР ның крайлары, өлкәләре һәм республикалары турында, аларның табигате һәм халкы турында, чит илләр турында, атаклы тикшеренүчеләрнең сәяхәтләре турында, совет Арктика экспедицияләре турында (мәсәлән, Папанин И. Д. „Зур боз өстендәге тормыш“ һ. б.) популяр әдәбият барлыгын карарга тиешбез.

Массовый көтепханә фондында матур әдәбият зур урын алырга тиеш. Бу бүлекне өйрәнгәндә матур әдәбиятның түбәндәге төп төрләре ни дәрәҗәдә тупланганлыгын тикшерергә кирәк:

а) рус әдәбияты классикларының әсәрләре (Фонвизин, Радищев, Крылов, Жуковский, Грибоедов, Пушкин, Лермонтов. Гоголь, Герцен, Тургенев, Гончаров, Л. Толстой, Некрасов, А. Н. Островский, Салтыков-Щедрин, Г. Успенский, Короленко, Чехов, М. Горький, Маяковский һ. б.);

б) СССР да яшәүче башка халыкларның классик әдәбият әсәрләре—украин халкының (Шевченко, Коцюбинский, Иван Франко һ. б.), грузин халкының (Шота Руставели, „Юлбарыс тиресе кигән батыр“), әрмән, азербайжан халыкларының, татар халкының (Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Һади Такташ һ. б.) классик әсәрләре;

в) Чит илләр әдәбияты классикларының әсәрләре—инглиз классикларының (Шекспир, Байрон, Диккенс һ. б.), Америка классикларының (Марк Твен, Лонгфелло һ. б.), француз классикларының (Бальзак, Стендаль, В. Гюго, Флобер, Золя, Мопассан, А. Франс, һ. б.), испан (Сервантес), итальян (Данте) һ. б. классикларының әсәрләре;

г) телдән-телгә күчә торган халык иҗады әсәрләре (рус халкының мәсәлләр җыентыгы, әрмән халык эпосы—„Давид Сасунский“ һ. б.);

д) хәзерге совет язучыларының иң яхшы әсәрләре (мәсәлән, Фурмановның „Чапаев“, Серафимовичның „Тимер ташкын“, Шолоховның „Тын Дон“ һәм „Күтәрелгән чирәм“, Н. Островскийның „Корыч ничек чыныкты“ һәм „Давылда туганнар“, А. Н. Толстойның

„Икмәк“, „Петр Беренче“, „Газап чигүчеләр“, С. Н. Сергеев-Ценскийның „Севастополь страдасы“, „Брусилов һөҗүме“, Новиков-Прибойның „Цусима“, Первенцевның „Кочубей“, А. Фадеевның „Тар-мар“, В. Янның „Чингиз Хан“, С. Бородинның „Дмитрий Донской“, дигән әсәрләре, П. Тычино, Рыльский, М. Бажан, Сулейман Стальский, Джамбул, Янки Купало, Якуб Колас һ. б. әсәрләре);

е) аеруча—Бөек Ватан сугышы турындагы темаларга язылган әсәрләр, мәсәлән, Шолохов „Нәфрәт фәне“, „Алар Ватан өчен сугыштылар“, П. Павленко „Рус повесте“, В. Гросман „Халык үлми ул“, Первенцев „Сынау“, Ванда Василевская „Салават күпере“, Б. Горбатов „Буйсынмас кешеләр“, Панферов „Үз күзләрем белән“, К. Симонов „Көннәр һәм төннәр“, „Лирика“, „Рус кешеләре“, Корнейчук „Фронт“, „Правда“ издательствосының „Фронт тормышыннан“ дигән серияләре, Бөек Ватан сугышы турындагы хикәяләрнең, очеркларның, шигырьләрнең тематик җыентыклары;

ж) хәзерге чит ил язучыларыннан фашизмга каршы булганнарының әсәрләре (Пристли „Грэтлидә караңгылык“, Энгстранд „Норвегия язы“, Дж. Стейнбек „Ай батты“ һ. б.)

Без мисал өчен фәнни һәм матур әдәбият әсәрләреннән бик азын гына күрсәтеп үттек. Киң итеп алар библиографик күрсәткечләрдә һәм типовой каталогларда, мәсәлән, „Авыл көтепханәләре өчен төп әдәбият күрсәткече“ ндә саналалар. Ниһаять, авыл көтепханәләрендә һәм балалар бүлеге булган район көтепханәләрендә балалар әдәбияты булырга тиеш, атап әйткәндә—кече яшьтәге балалар өчен булган китаплар (Маршак, Михалков, А. Барто, Бианки һ. б. әсәрләре); урта һәм зур яшьтәге балалар өчен булган китаплар (А. Гайдар, С. Григорьев, Л. Кассиль, М. Ильин, Б. Житков, Ж. Верн, Майн-Рид, Марк Твен һ. б. әсәрләре) булырга тиеш.

Көтепханә фондының бүлекләрен бер-бер артлы эзлекле рәвештә карап чыгып, һәр бүлекнең составын авыл көтепханәләре өчен төп әдәбият күрсәткече белән һәм бүтән библиографик ярдәмлекләр белән чагыштырып, иң яхшы һәм бик тәкъдим ителгән китаплар белән танышып, көтепханә эшчесе фондның составын өйрәнер һәм булдырырга һәм укучыларга тәкъдим итәргә кирәкле китаплар турында белем алыр.

## § 7. КӨТЕПХАНӘ ӨЧЕН КИТАПЛАРНЫ КАЙДАН ҺӘМ НИЧЕК АЛЫРГА

Көтепханә фондына әдәбиятны түбәндәге юллар белән өсти торырга мөмкин:

1) китап магазиннарыннан, көтепханә коллекторларыннан, китап-газета киоскларыннан китаплар сатып алу юлы белән;

2) вакытлы матбугат әсәрләренә (журналларга, газеталарга) алдан язылу юлы белән;

3) китапларны ирекле рәвештә халык арасыннан җыйнау юлы белән;

4) дәүләт әдәбият фондыннан китаплар алу юлы белән (әгәр дә көтепханә немецлар оккупациясеннән азат ителгән районда булса).

Массовый көтепханәләрне комплектлауның төп чыганаклары менә шулар. Аларның иң әһәмиятлесе—өлкә (край) көтепханә коллекторы, ягъни махсус рәвештә көтепханәләрне китаплар белән тәэмин итү эшен алып бара торган китап магазины.

Коллектор беренче чиратта үзе белән договор төзегән көтепханәләрне китаплар белән тәэмин итә.

Договор төзегәндә көтепханә үзе сатып алырга тиеш булган әдәбиятның тулай суммасын күрсәтергә һәм 25% күләмендә аванс кертергә кирәк. Көтепханәнең бурычы—кирәкле китапларга вакытында заявка биреп тору, коллекторның счетлары буенча вакытында акча түләү, коллектор тарафыннан оештырыла торган библиографик күзәтү җыелышларына бару.

Кайбер өлкәләрдә һәм крайларда үзәкләштерелгән тәртиптә комплектлау үткәрелә: район һәм авыл көтепханәләрен комплектлауга бирелгән барлык акча культура-агарту эшләренең өлкә бүлегенең банктагы агымдагы счетына күчерелә, ул көтепханәләрне китаплар белән тәэмин итү турында коллектор белән договор төзи. Коллектор тәэминатында тормый торган көтепханәләр үзләренә якын булган китап магазиннары белән элемтә тотарга һәм, кирәк булса, алар белән договор төзергә тиешләр. Коллектор тәэминатында торучы көтепханәләр якындагы китап магазиннарыннан да файдалана алалар. Китап комплектлау өчен көтепханәгә бирелгән акчаның бер өлешен шушы магазиннардан әдәбият сатып алуга калдырырга кирәк. Иске басмаларны табу өчен аерым типтагы китап магазин-

нарына—гадәттә өлкә үзәгендә була торган букинистик (иске һәм тотылган китаплар белән сату итүче) магазиннарга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Союзпечатьның китап-газета киосклары китап алу өчен көтепханәләргә ярдәмче чыганак булып хезмәт итә алалар.

Вакытлы матбугат әсәрләрен алцан язылу юлы белән алалар. Ел азагында (чама белән ноябрь-декабрьда) көтепханә үзенә кирәкле журнал һәм газеталарның исемлеген төзи һәм якындагы почта бүлегендә яки хат ташучы аркылы аларны яздыра. Яздырганда берьюлы бөтен елга яздырырга, һәрхәлдә—ярты елдан кимгә язылмаска киңәш бирелә. Язылуны рәсмиләштерә торган документны (квитанцияне һ. б. ш.) көтепханәнең эш кәгазьләрендә сакларга кирәк.

Авыл көтепханәсе яздырырга тиешле газеталар: „Правда" яки „Известия", „Комсомольская правда", „Социалистическое земледелие", өлкә һәм район газеталары. Район көтепханәсенә саналган газеталарның барысы да кирәк һәм шуның өстенә „Труд", „Пионерская правда", „Военное обучение", „Учительская газета", „Советское искусство" газеталары да кирәк.

Журналлардан авыл көтепханәсендә беренче чиратта түбәндәгеләр булырга тиеш: „Политпросветработа", „Крестьянка", „Колхозное производство", „Огонёк", „Крокодил", „Агротехсоветы колхозам", „Совет әдәбияты".

Район көтепханәсенә, югарыда саналганнардан тыш, тагын күп кенә журналлар — иҗтимагый политик журналлар („Большевик", „Пропагандист", „Партийная жизнь"), хәрби журналлар (бигрәк тә „За оборону"), техник журналлар (бигрәк тә „Техника молодежи"), авыл хуҗалыгы журналлары („Социалистическое сельское хозяйство", „МТС" һәм укучыларның сорауларына карап, башкалар), әдәби журналлар — („Новый мир", „Знамя"), яшьләр һәм балалар журналлары („Смена", „Пионер", „Вожатый", „Мурзилка", „Дружные ребята") яздырырга киңәш бирелә. Укучылар өчен әһәмиятле булган журналларны беренче чиратта яздыру өчен, журналларга язылуны рәсмиләштерү алдыннан укучылар белән сөйләшергә киңәш бирелә.

Авыл һәм район көтепханәләрендә кайбер хәлләрдә комплектлау өчен халык арасында һәм жирле оешмаларда китаплар җыю кебек өстәмә чыганактан да файдаланырга киңәш бирелә. Төрле учреждениеләрдә

һәм оешмаларда (авыл советында, район сәламәтлек саклау бүлегендә, район газетасы редакциясендә һ. б.) тупланган китаплар күп вакыт файдаланылмыйча, тик ята.

Төрле оешмаларда булып та, эш буенча үзләренә кирәк булмаган китапларның массовый көтепханәләр фондына тапшырыла баруына һәм шулай итеп аларның бөтен халык файдаланырлык булып әверелүләренә ирешергә кирәк.

Халык арасыннан китап җыйганда үз көтепханәң өчен генә түгел, бәлки азат ителгән районнар көтепханәләре өчен дә җыярга кирәк, шуның белән бергә китаплар җыю эшен җитди политик кампания итеп, урындагы партия оешмасы җитәкчелегендә, аны матбугатта киң яктыртып, ярдәмгә укытучыларны һәм мәктәп балаларын, комсомолецларны һәм пионерларны тартып үткәрергә кирәк.

Җыелган китаплар арасында авыл яки район көтепханәсенә яраксыз китапларның булуы мөмкин. Мондый китаплар өлкә көтепханәләренә тапшырылалар.

## § 8. КӨТЕПХАНӘЛӘР АРАСЫНДАГЫ АБОНЕМЕНТ

Көтепханә укучыларның китапларга булган сорауларын исәпкә ала һәм аларны канәгатьләндерергә тырыша. Сорала торган китаплар аның фондында булмаганда, көтепханә аларны сатып алу чарасын күрә. Ләкин моны һәрвакытта да эшләп булмый, күп вакыт сорала торган китаплар сатылып беткән булып чыга. Шуның өстенә укучылар, бигрәк тә белгечләр тарафыннан сорала торган китапларның барысы да массовый көтепханәгә кирәкле үк булып бетми. Сирәк сорала торган, бик аз белгечләр өчен генә кирәк булган китапны сатып алуның көтепханә өчен мәгънәсе юк. Теге яки бу укучы шундый китапларны сораган хәлләрдә көтепханә бу сорауны көтепханәләр арасындагы абонемент ярдәмендә канәгатьләндерә.

Көтепханәләр арасындагы абонемент тәртибендә өлкә көтепханәсеннән китаплар алу өчен район яки авыл көтепханәсе өлкә көтепханәсенә заявка-йөкләмә язып җибәрә. Заявкада көтепханәнең тулы исеме, аның дөрес почта адресы, көтепханә мөдиренең фамилиясе, исеме

һәм атасының исеме күрсәтелә. Йөкләмәләр исә түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча алына торган китапларның тулысынча саклануын һәм вакытында кайтарып бирелүен тәэмин итү.

2. Китаплардан файдалануның көтепханәләр арасындагы абонемент ача торган көтепханә тарафыннан билгеләнгән барлык кагыйдәләренә буйсыну.

3 Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу мөмкинлеге турында үз укучыларыңа киң рәвештә белдерү.

Заявкага көтепханә мөдире тарафыннан кул куела һәм ул көтепханә буйсынган оешма тарафыннан таныклана.

Заявка-йөкләмәне язып биргәннән соң район яки авыл көтепханәсе өлкә көтепханәсенең абонементы булып исәпләнә. Өлкә көтепханәсеннән үткән елларда чыккан китап һәм журналларны алганда район яки авыл көтепханәсенең берьюлы күп дигәндә 20 том китап һәм журнал алырга хакы бар. Өлкә көтепханәсе урнашкан шәһәрдәге көтепханәләргә китаплар бер ай ярым-ике ай срок белән бирелә. Китапларны почта аша җибәрү вакыты китаплардан файдалану срогына керә. Район яки авыл көтепханәсе, көтепханәләр арасындагы абонемент буенча алган китапларны үз фондыннан аерым рәвештә аерым шкафларда яки аерым киштәләрдә тота һәм саклый.

Укучының көтепханәләр арасындагы абонемент тәртибендә генә алырга мөмкин булган китапны соравы „Укучы таләпләре листогы“ ярдәмендә рәсмиләштерелә.

**Укучы таләпләре листогы**

Укучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Автор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Китапның исеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Көтепханә эшчесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сорау җибәрелде . . . . . . . елда . . . . . . . . . числода
Китап алынды . . . . . . . . елда . . . . . . . . . числода
Шушы № . китапны (инвентарь номеры языла) . . . . .
. . . . . . . . . . . . . елның . . . . . числосына
кадәр срок белән алдым.

Укучы имзасы: . . . . . .

Бу листок район яки авыл көтепханәсендә кала һәм китапларны укучыга бирүне рәсмиләштерү өчен файдаланыла.

Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча алынган китаплар укучыга өенә алып китәргә бирелмиләр, бәлки уку залында файдалану өчен генә бирeләләр.

Әгәр дә көтепханә эшчесе үз көтепханәсе китапларының саклануын күзәтергә тиеш икән, көтепханәләр арасындагы абонемент тәртибендә башка көтепханәләрдән алынган китапларны ул бигрәк тә нык сакларга тиеш. Бу китапларны югалтканда яки бозганда район яки авыл көтепханәсе өлкә көтепханәсенә шундый ук китаплар кайтарып бирергә, шулай эшләргә мөмкинлек булмаган хәлләрдә — өлкә көтепханәсе белән сөйләшү буенча аларның бәясен түләргә тиешләр.

Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча сорала торган һәр китапка заказ бланкысы языла. Бланкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1. Көтепханәнең тулы исеме.
2. Китапның авторы һәм исеме яки теманың исеме.
3. Укучының эше һәм белеме.
4. Заказ датасы.

Заказ бланклары өлкә көтепханәсенә җибәреләләр һәм шунда калалар. Заказ бирелгән китапларны (яки китаплар комплектын) алгач, район яки авыл көтепханәсе китапларның алынуын раслап өлкә көтепханәсенә ачык хат жибәрә. Китаплар кайтарылгач, өлкә көтепханәсе район яки авыл кәтепханәсенә китапларның алынуын раслап хат җибәрә.

Өлкәдәге көтепханәләргә китаплар җибәргәндә почта расходларын өлкә көтепханәсе түли, ә кире җибәргәндә — район яки авыл көтепханәләре түлиләр.

Һәр посылка яхшылап төрелгән булырга тиеш. Авырлыклары 2 килограммнан да артык булмаган посылкаларны кәгазьгә төрү дә җитә. 2 килограммнан алып 8 килограммга кадәр авырлыктагы посылкалар махсус ящиклар белән яки нык кәгазьгә төреп, өске һәм аскы якларына фанера такталар куеп бәйләп җибәреләләр. Посылкалар почта переводы буенча урындагы почта бүлегенә тапшырылалар. Посылка җибәрү турындагы квитанцияләр көтепханәнең эш кәгазьләрендә саклаңалар.

---

## *III БҮЛЕК*

# МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘЛӘРДӘГЕ КИТАПЛАРНЫ КЛАССИФИКАЦИЯЛӘҮ ҺӘМ КЕТТЕРИЗАЦИЯЛӘҮ

## § 1. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘЛӘРДӘГЕ КИТАПЛАРНЫ КЛАССИФИКАЦИЯЛӘҮ

Көтепханә фондының составына төшенү өчен, билгеле белем тармаклары, темалар, мәсьәләләр буенча китапларны табып алу ансат булсын өчен, көтепханәдә булган барлык китапларны, аның барлык фондын, китапларның эчтәлегенә карап, бүлекләргә аерырга кирәк. Китапларны бүлекләргә аерү аларны классификацияләү дип атала.

Совет көтепханәләрендә китапларны унарлы классификацияләү кулланыла. Аның асылы шунда: барлык фәнни китаплар төп 10 бүлеккә бүленәләр. Бүлекләр шартлы рәвештә 0 дән 9 га кадәр гарәп цифрлары белән билгеләнәләр:

0 Гомуми бүлек
1 Философия
2 Дин һәм дингә каршы пропаганда турында
3 Иҗтимагый-политик әдәбият
4 Тел белеме
5 Табигать белеме һәм математика
6 Техника һәм агротехника. Медицина
7 Сәнгать. Уеннар. Спорт
8 Әдәбият белеме һәм тәнкыйть
9 Тарих. География

Китапны классификацияләп, без аның нинди белем тармагына һәм, димәк, унарлы классификациянең кайсы бүлегенә керүен билгелибез, һәм китапның титул битенә бүлек билгесен (индексны) куябыз.

Мисаллар:

**Китаплар**

| | Индекслар |
|---|---|
| Александров Г. Марксизмның философик элгәрләре | 1 |
| Ярославский Е. Аллалар ничек туалар, яшиләр һәм үләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . | 2 |
| Политик сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . | 3 |
| Ушаков Д. Н. Орфографик сүзлек . . . . . . . . . | 4 |
| Келлер Б. А. Җирдә тереклекнең килеп чыгуы һәм үсүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . | 5 |
| Гумилевский Л. И. Тимер юл . . . . . . . . . . . . | 6 |
| Рейнак С. Сәнгатьләр тарихы („Аполлон") . . . . . . | 7 |
| Горький М. Сайланма әдәби-тәнкыйть мәкаләләре . . | 8 |
| СССР тарихы. Кыскача курс. 3 һәм 4 класслар өчен дәреслек. А. В. Шестаков редакциясендә . . . . . | 9 |
| Аусвейт Л. Җир шарын ничек тапкэннар . . . . . . | 9 |
| Авыл көтепханәләре өчен төп әдәбият күрсәткече . . . | 0 |

Матур әдәбиятка классификация индексы бирелми.

Төрле мәсьәләләр буенча язылган мәкаләләрдән торган китаплар, мәсәлән, энциклопедик сүзлекләр, төрле эчтәлекле мәкаләләр җыентыклары, гомуми бүлеккә керәләр.

Көтепханә эше һәм библиография буенча әдәбият та шул ук бүлеккә керә.

Әгәр дә китапларны төп ун бүлек буенча аеру белән генә чикләнсән, хәтта 3—4 мең китабы булган авыл көтепханәсендә дә фондның һәр бүлегендә шактый күп китап булып чыгачак, һәм анда да әле китапларны табу җиңел булмаячак.

Мәсәлән, 6 нчы бүлектә техника, медицина, авыл хуҗалыгы, йорт хуҗалыгы, элемтә, кустарь промыселлары кебек төрле тармаклар буенча әдәбият җыйналачак. Шуңа күрә бүлекләрне тагын бүлекчәләргә аерырга кирәк. Һәр бүлек 10 бүлекчәгә бүленә, алар да шулай ук 0 дән алып 9 га кадәр цифр белән билгеләнәләр. Бүлекчәнен билгесе бүлек билгесенә кушыла, нәтиҗәдә ике урынлы сан килеп чыга. Мәсәлән, 5 нче бүлекнең түбәндәге бүлекчәләре була:

51 Математика
52 Астрономия
53 Физика
54 Химия
55 Геология
56 Палеонтология

57 Биология
58 Ботаника
59 Зоология

6 нчы бүлектә: 61 — медицина, 62 — техника, 63 — авыл хуҗалыгы, 64 — йорт хуҗалыгы һ. б.

3 нче бүлек түбәндәге бүлекчәләрне эченә ала: ЗК — марксизм-ленинизм, 31 — статистика, 32 — политика, 33 — экономика һәм политэкономия, 34 — хокук, 35 — идарә (дәүләт аппараты, власть органнары, илнең оборонасы, армия), 36 — социаль тәэминат, 37 — халык мәгарифе һ. б.

Фондлары зур булган көтепханәләр өчен бүлекчәләргә аеру гына житми, тагын да ваграк бүленешләр кертергә туры килә. Бу бүленешләр дә 0 дән алып 9 га кадәр саннар белән билгеләнәләр һәм билгеләр бүлекчә билгесенә кушып языла лар, нәтиҗәдә өч урынлы сан килеп чыга, мәсәлән:

51 Математика
511 Арифметика
512 Алгебра
513 Геометрия һ. б.

Китап фондлары зур булмаган авыл һәм район көтепханәләрендә китапларны бүлекләр һәм бүлекчәләр буенча классификацияләү житә, ләкин кайбер хәлләрдә шактый ваграк индекслардан файдаланырга туры килә.

Унарлы классификация үткән йөзнең 70 нче елларында Американың күренекле көтепханә эшчесе Мельвиль Дьюи тарафыннан төзелеп, XX гасыр башларында Брюссельдәге Халыкара библиография институты тарафыннан беркадәр үзгәртеп эшләнде.

1921 елда унарлы классификация Главполитпросвет тарафыннан Советлар республикасының массовый көтепханәләре өчен мәҗбүри кагыйдә итеп кабул ителде. Совет тормышы тудырган мәсьәләләргә һәм күренешләргә карата унарлы классификация күп тапкырлар янадан үзгәртеп эшләнде, ләкин аның гомуми структурасы үзгәрешсез кала килде. Соңгы тапкыр унарлы классификация таблицасын Л. Н. Троповский яңадан эшләде. 1942 елда Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы унарлы классификация таблицасының массовый көтепханәләр өчен Л. Н. Троповский тара-

фыннан төзәтелгән һәм тулыландырылган 3 нче басмасын чыгарды. Бу басмага 3 нче бүлеккә Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбиятны эченә ала торган яңа бүлекчә — 32В бүлекчәсе кертелде.

1944 елда Л. Н. Троповскийның „Кечкенә көтепханәләр өчен унарлы классификациянең кыскача таблицалары“ басылып чыкты (М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы). Бу китап авыл һәм кечкенә район көтепханәләре өчен чыгарылган. Ул унарлы классификациянең бик әһәмиятле рубриклары әлифба тәртибендәге күрсәткеч белән тәэмин ителгән (37—80 бит).

Китапны классификацияләгәндә без аның эчтәлеге белән танышабыз һәм шул юл белән төп 10 бүлекнең кайсысына кертергә кирәклекне билгелибез. Аннары унарлы классификация таблицасына мөрәҗәгать итәбез, китапны без керткән бүлекнең рубрикларын карыйбыз һәм аны кайсы бүлекчәгә кертергә кирәклеген табабыз.

Янәшә ике белем өлкәсенә, мәсәлән, физикага һәм химиягә караган мәсьәләләрне тикшерә торган китаплар очрый. Мондый китапларны гомумирәк бүлеккә, бу хәлдә — табигать фәне бүлегенә (5 нче бүлеккә) кертергә кирәк. Янәшә булмаган, бер-берсеннән бөтенләй аерыла торган ике тармакка кагыла торган китапларга төп индекс аның төп эчтәлегенә карап бирелә һәм өстәмә индекс китапта азрак дәрәҗәдә яктыртылган мәсьәләгә карап бирелә.

Ләкин, икеле, өчле һәм шуңа ошашлы катлаулы индексларны бик еш кулланырга кирәкми. Күп вакытта бер үк китапта бик күп төрле белем тармаклары турында сөйләнә торган була. Без китапның шундый күп төрле эчтәлегенең барысын да индекслар белән билгеләп бетерә алмыйбыз. Без китапның төп эчтәлеген, китапта яктыртылган төп мәсьәләне исәпкә алырга һәм аны тиешле бүлеккә яки бүлекчәгә кертергә тиешбез.

Әсәрләр җыентыкларын классификацияләгәндә аларны тулысынча, китапның төп эчтәлегенә карап, бер бүлеккә яки бер бүлекчәгә кертү гадәткә алынган. Мәсәлән, Маркс һәм Энгельс әсәрләре — 3К1 бүлекчәсенә, В. И. Ленин әсәрләре — 3К2 бүлекчәсенә, И. В. Сталин әсәрләре — 3К3 бүлекчәсенә кертелә.

Марксизм-ленинизм классиклары әсәрләренең аерым китаплары классификация вакытында төп индекстан (3К1, 3К2, 3К3) тыш өстәмә индекслар алуы да мөмкин.

Мәсәлән, иптәш Сталинның „Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында“гы китабы, ЗКЗ индексыннан тыш, өстәмә рәвештә 32В индексын алачак (Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбият), В. И. Ленинның Л. Толстой турындагы мәкаләләре ЗК2 индексыннан тыш — өстәмә рәвештә 8 индексын алачак (әдәбият белеме).

Л. Н. Троповский классификациясенең 1944 елда чыккан кыскача таблицаларына кушымта итеп бирелгән рубрикларның әлифба тәртибендәге күрсәткече китапларны классификацияләү эшен бик җиңеләйтә.

Күрсәткечтә барлык рубриклар әлифба тәртибендә саналган, шуның белән бергә һәрберсенә каршы таблицада үзенә туры килә торган индекс күрсәтелгән, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Кошчылык . . . . . . . . . . . . . . . | 636 |
| Кошлар . . . . . . . . . . . . . . . . | 59 |
| Пулеметтан атыш . . . . . . . . . . . . | 356 |
| Пулеметлар . . . . . . . . . . . . . | 356 |
| СССР буенча юл күрсәткечләр . . . . | 91 |
| Музейлар буенча юл күрсәткечләр... музейларны кара. | |
| Сәяхәтләр . . . . . . . . . . . . . | 91 |
| СССР ның төрле өлкәләренә сәяхәтләр | 91 С |
| Хәбәрләшү юллары (техника һәм эксплоатация) . . . . . . . . . . . . . . . . | 625 |
| Умартачылык . . . . . . . . . . . . . | 638 |

Мәсәлән, „Умартачылык турында белешмә“ дигән китапны классификацияләгәндә без күрсәткечкә мөрәҗәгать итәбез, „Умартачылык“ сүзен һәм аның янында 638 индексын табабыз.

## § 2. КИТАПЛАРНЫ КЕТТЕРИЗАЦИЯЛӘҮ

Китапның индексын билгеләгәч, без аны титул битенең яки, китапның титул бите булмаса, тышлыгының югары башында уң яки сул почмакка язып куябыз. Индекс астына автор билгесе дигән нәрсә куела. Автор билгеләре бер үк бүлекнең китапларын тиз генә механик рәвештә тезеп кую өчен кирәк. Автор билгесе автор фамилиясенең баш хәрефеннән һәм ике (яки өч) цифрдан тора. Әгәр дә китапта авторның фамилиясе күрсәтелмәгән булса (китап коллектив хезмәт белән чыгарылса, официаль материалдан торса, андый хәл

еш була), ул чакта автор билгесен китап исеменең беренче хәрефе буенча куялар.

Автор билгеләре Америка көтепханә эшчесе Кеттер тарафыннан тәкъдим ителгән аерым таблицалар буенча билгеләнәләр. Кеттер булуы мөмкин булган авторлар фамилияләренең беренче иҗекләрен әлифба тәртибендә тезеп чыккан һәм шул иҗекләргә номер суккан. Автор билгеләрен шушы таблицалар буенча эзләп табу китапларны кеттеризацияләү дип атала. Рус көтепханәләре өчен Кеттер таблицалары Л. Б. Хавкина тарафыннан яңадан эшләнде.

Таблицаларда һәр ике хәрефкә (А һәм Б, В һәм Г һ. б.) бер бит бирелгән. Битнең уртасы буенча 11 дән 99 га кадәр ике урынлы цифрлар баганасы басылган, һәр цифр каршысына уң яклап һәм сул яклап авторларның фамилияләр башлану мөмкин булган иҗекләр тезелгән. Мисал өчен автор таблицаларының беренче битенең баш өлешен китереп үтик.

| | | |
|---|---|---|
| А | 11 | Б |
| Аа | 12 | Ба |
| Аб | 13 | Бав |
| Абе | 14 | Баг |
| Аби | 15 | Бад |
| Абр | 16 | Баж |
| Абс | 17 | Баз |
| Ав | 18 | Бан |
| Аве | 19 | Бак |
| Ави | 20 | Бал |

Китерелгән өземтәдә 15 цифрын алып карыйк. Аның каршысында уң як баганада „Бад“ иҗеге тора, бу иҗек белән башлана торган фамилияләр, мәсәлән, „Бадаев“, Б15 автор билгесе алалар. „Бажов“ фамилиясе өчен автор билгесе Б16 булыр, „Базилевич“ фамилиясе өчен — Б17 булыр. Китапларны киштәләргә тезгәндә, без бер бүлек эчендә автор билгеләре белән эш итәбез: башта автор билгесе Б15 булган китаплар тезелә, аннан соң автор билгесе Б16 булган китаплар, аннары — автор билгесе Б17 булган китаплар тезелә.

Марксизм-ленинизм классикларының автор билгеләре түбәндәгеләр:

Маркс — М27
Энгельс — Э63
Ленин — Л45
Сталин — С76

Аерым авторы булмаган китаплар өчен автор билгесе китап исеменең беренче иҗеге буенча бирелә, мәсәлән:

Программа и устав ВКП(б) — П78
История ВКП(б). Краткий курс — И90
Резолюции XVIII Всесоюзной
конференции ВКП(б) — Р34

Автор билгесе бүлек билгесе астында языла һәм ике билге бергәләп **китапның шифрын** тәшкил итәләр.

Китап өчен аның шифрын эзләп табу китапны шифрлау дип йөртелә.

Матур әдәбият әсәрләренә индекс бирелми, матур әдәбият китабының шифры автор билгесеннән генә тора.

**Мисаллар:**

Пушкин А. С. Евгений Онегин — П91
Гоголь Н. В. Тарас Бульба — Г58
Лермонтов М. Ю. Безнең заман герое — Л49
Толстой Л. Н. Сугыш һәм солых — Т53
Горький М. Ана — Г71

Ике катлы фамилияле авторлар өчен автор билгесе беренче фамилия (яки фамилиянең беренче кисәге) буенча бирелә, мәсәлән, Новиков-Прибой А. С. — Н73.

Әгәр дә китапның берничә авторы булса, ул чагында автор билгесе беренче булып язылган автор фамилиясе буенча бирелә.

Журналлар автор билгеләрен үз исемнәренең беренче сүзе буенча алалар, мәсәлән, „Совет әдәбияты" журналы — С74[1].

---

[1] Автор таблицаларын куллану кагыйдәләре белән тулырак итеп түбәндә күрсәтелгән брошюраның кереш мәкаләсе буенча танышырга була: Хавкина Л. Б. „Кітер методы буенча автор таблицалары (ике урынлылар)". Янадан каралган һәм тулыландырылган 11 нче басмасы. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942.

## IV БУЛЕК

### КӨТЕЙХАНӘНЕҢ КИТАП БАЙЛЫГЫНА УЧЕТ

### § 1. КӨТЕПХАНӘГӘ АЛЫНГАН ӘДӘБИЯТНЫ КАБУЛ ИТҮ

Көтепханәгә алынган китаплар тиешле документлар (счет, счет күчермәсе, накладной) буенча кабул ителәләр. Көтепханә эшчесе китапларны накладной белән яки счетка кушымта итеп җибәрелгән исемлек белән барлый, алынган китапларның гомуми санын исәпли, килгән документта: „фәлән кадәр китап алдым“ дип билге ясый, кул куя һәм китапны алу датасын куя.

Әгәр дә китаплар көтепханәгә тиешле документсыз килеп керсәләр, мәсәлән, берәр оешмадан яки аерым кешедән бүләк булсалар, ул чакта түбәндәге формада акт төзелә:

**АКТ №______**

„......“..................191......ел. Бу акт тиешле документсыз алынган түбәндәге китапларны көтепханәгә кабул итү турында язылды.

Китаплар ——————————торучы ———————————
Фамилиясе,

.............................................дан алынды. Саны.........данә китап һәм
исеме. атасының исеме

брошюра, ................ номер журнал,барлыгы.........сумлык——————
..........тиенлек.

| Тәртип №№ | Автор һәм китапның исеме | Данәләр саны | Сумасы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Сум | Тиен |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| һ. б. | | | | |

Актта саналган әсәрләрне көтепханәгә тапшыручы кеше имзасы.

Көтепханә мөдире имзасы.

Әгәр дә документ буенча кабул ителә торган китаплар арасында китаплар җитмәүчелек яки бер китапның икенче китап белән алыштырылуы беленсә, яки ертылган, бозылган китаплар килеп чыкса, ул чакта акт ике данә языла. Актның бер данәсе көтепханәдә кала, икенчесе китапны җибәрүчегә (китап магазинына, көтепханә коллекторына) тапшырыла. Актка җитмәгән китапларны җибәрүне, ялгыш җибәрелгәннәрен яки ертылганнарын алыштыруны сорап язылган требование кушып җибәрелә.

## § 2. КӨТЕПХАНӘГӘ АЛЫНГАН КИТАП, БРОШЮРА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРНЫҢ АЕРЫМ УЧЕТЫ

Көтепханәләрдә китапларның ике төрле учеты: „индивидуаль“ учет һәм „суммар“ учет алып барыла.

Китаплар, брошюралар һәм журналларның индивидуаль учеты өчен „инвентарь кенәгәсе“ була. Инвентарь кенәгәсе түбәндәге формада була.

Инвентарь кенәгәсенең һәр битенә номер сугылган һәм көтепханә нинди оешма карамагында булса, шул оешма тарафыннан таныкланган булырга тиеш. Инвентарь кенәгәсе бөтенләй тулгач аңа көтепханә мөдире кул куярга тиеш. Инвентарь кенәгәсен көтепханәнең бик әһәмиятле документы итеп яхшылап сакларга кирәк. Фондка яңа баштан инвентаризация үткәрелгәндә дә инвентарь кенәгәсен юк итәргә юл куелмый. Фондка янадан инвентаризация ясау бик кирәкле хәлләрдә генә, шуның белән бергә культура-агарту эшләре бүлегенең рөхсәте белән генә үткәрелә.

Көтепханәгә алынган барлык китаплар, әлбәттә, инвентарь кенәгәсенә языла баралар. Һәр китап өчен бер юл бирелә.

Китапның исеме озын булып, бер юлга сыймаса, кыскартып языла, мәсәлән, „Сокращенный курс математики и хозяйственных вычислений“ — „Сокр. курс матем. и хоз. вычислений“. Инвентарь кенәгәсенә язылганны, кагыйдә буларак, сызарга яки төзәтергә ярамый, ә төзәтү кирәк булган хәлләрдә „Искәрмә“ графасында „Төзәтелгәнгә ышанырга“, дип билге ясала, шунда ук көтепханә мөдире кул куя.

Көтепханәгә алынган китапларның барысы да инвентарь кенәгәсенә язылмый. Көтепханә тарафыннан күпләп сатып алынган массовый брошюралар гадиләштерелгән форма буенча махсус „Брошюралар теркәү дәфтәре“нә язылалар.

### Брошюраларны теркәү дәфтәре

| 1945 ел | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Язу датасы | Тәртип № | Автор һәм китапның исеме | Данәләр саны | Бәясе: Бер данәнең | | Бәясе: Барлык данәләрнең | | Кетепханә фондының хәрәкәт кенәгәсенә язылышы | Искәрмә |
| | | | | с | т | с | т | | |
| 26/IV | 203 | Бакчачы истәлеге | 19 | 1 | — | 19 | — | 25 | |
| 28/IV | 204 | „Беренче май“ | 14 | — | 25 | 3 | 50 | „ | |
| „ | 205 | Агитатор блокноты № 12 | 5 | — | 40 | 2 | — | „ | |

Брошюраларны теркәү дәфтәренә брошюраның һәр данәсе аерым язылмый, бәлки бер исемдәге брошюралар, күпме данә булуларына карамастан, берьюлы һәм бер тәртип номеры белән язылалар.

Тәртип номерларын инвентарь номерларыннан аеру өчен тәртип номерларына „б“ хәрефе өстәлә, мәсәлән, б) 327 дип языла. Брошюраларны теркәү дәфтәренә язылырга тиешле брошюралар комплектыннан берничә данә (2—3—4) брошюра аерып алына, һәрберсе аерым номер астында инвентарь кенәгәсенә языла.

„Калын“ журналлар, мәсәлән, „Новый мир“, „Октябрь“, „Совет әдәбияты“ алган саен аерым номерлары белән инвентарь кенәгәсенә языла баралар, „юка“ журналлар („Огонёк“, „Крокодил“) — төпләнгән комплектлар белән язылалар. Журналларның көтепханәгә тулысы белән һәм вакытында килүен тикшерү өчен „журналлар картотекасы“ кулланыла.

Журналларны теркәү карточкасы түбәндәге формада була:

| Журналның исеме | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ел | Январь | Февраль | Март | Апрель | Май | Июнь | Июль | Август | Сентябрь | Октябрь | Ноябрь | Декабрь |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

## § 3. КӨТЕПХАНӘДӘН ЧЫГА ТОРГАН ӘДӘБИЯТКА АЕРЫМ УЧЕТ

Көтепханәгә китаплар кереп кенә тормый, бәлки төрле сәбәпләр белән аннан чыгып та торалар. Көтепханәдән бер яки берничә китапның чыгып китүе акт белән рәсмиләштерелә.

**Әдәбиятны көтепханә исемлегеннән чыгарганда төзелә торган акт формасы**

**АКТ №**

„. . . .“ . . . 194 . . . ел. Бу акт: барлыгы . . . сумлык . . . . данә китапны, . . . . данә брошюраны, . . . данә журналны, . . . . . . сәбәпле . . . . көтепханә исемлегеннән чыгару турында төзелде. ................................................................

| Тәртип №№ | Чыккан китапларның инвентарь № | Автор һәм китапның исеме | Бәясе | | Бүлек | Нинди документлар нигезендә чыгарылды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сум | Тиен | | |
| | | | | | | |

Көтепханә мөдире имзасы . . . . . . . . . . .
Актны раслаучы кеше имзасы . . . . . . . . .

## Тургенев исемендәге шәһәр китапханәсе китап фондының хәрәкәт кенәгәсе

### I кисәк. Китаплар, брошюралар, журналлар алыну

| Язу датасы | Тәртип буенча язу № | Китаплар, брошюралар һәм журналлар кайдан алындылар | Тиешле документның датасы яки № | Алынган һәм инвентарьга теркәлергә тиешле китаплар, брошюралар һәм журналлар барлыгы: Гомуми саны | Шул исәптән журналлар | Гомуми суммасы: Сум | Тиен | Алынган һәм инвентарьга теркәлергә тиешле китаплар, брошюралар, журналларның бүленеше. Эчтәлеге буенча. Ижтимагый-политик әдәбият (1, 2, 3 һәм 9 бүлекләр): Ижтимагый-политик әдәбиятның барлыгы | Шул исәптән Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләре | Шул исәптән хәрби әдәбият (355—359) | Табигать белеме һәм математика (5) | Техника (6 бүлек, 61 һәм 63 тән башка) | Авыл хуҗалыгы техникасы (63) | Матур әдәбият | Балалар әдәбияты | Башка әдәбият (0, 4, 61, 7, 8, 91 һәм 92 бүлекләр) | Теле буенча: Татар телендә | Рус телендә | | | Шунын өстенә брошюраларны теркәү дәфтәренә язылырга тиешле брошюралар алынды: Саны | Суммасы: с | т | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1945 ел. 1 янв. бар иде | | | | 6506 | 204 | 16289 | 55 | 1934 | 826 | 365 | 585 | 327 | 624 | 1832 | 280 | 924 | 42 | | | | 820 | 365 | 20 | |
| 1945 ел. 1 кварталындагы керемнәр күчермәсе | | | | 258 | — | 567 | 45 | 46 | 30 | 16 | 12 | 16 | 22 | 122 | 24 | 16 | 4 | | | | 55 | 21 | 30 | |
| 1945 ел. 21/III | 19 | Бибколлектор | 1596 | 38 | — | 139 | 40 | 8 | 2 | 1 | 3 | 4 | 2 | 16 | — | 5 | 1 | | | | — | — | — | |

Искергән әдәбиятны исемлектән төшерү (чыгару) РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының приказлары һәм инструкцияләре нигезендә һәм аерым исемлекләр буенча эшләнә.

Искергән әдәбиятны көтепханә исемлегеннән чыгару турында РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының соңгы приказы 1941 елның 28/II ендә чыкты, шул ук елны Мәгариф Халык Комиссариаты 1 нче номерлы исемлекне—„Көтепханәләр исемлегеннән чыгарылырга тиешле искергән әдәбият“ исемлеген бастырып чыгарды.

Актта түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә: 1) китапның инвентарь №, 2) автор һәм китапның исеме, 3) бәясе, 4) бүлек, 5) исемлектән чыгару сәбәбе, 6) исемлектән чыгару нигезе (китапны югалту турында укучының гаризасы, китапның тузуы турында акт һ. б. ш.).

Актка көтепханә мөдире кул куя һәм, көтепханә нинди оешма карамагында булса, актны шул оешма раслый.

Китапларны исемлектән чыгару турындагы барлык актлар номерлар тәртибендә аерым папкага тегеләләр һәм аклану документы итеп саклыналар. Китапларны исемлектән чыгару турында инвентарь кенәгәсенә ясала торган билге түбәндәгечә эшләнә: инвентарь язуының соңгы графасына: „фәлән елның фәлән числасында төзелгән акт № . . . буенча исемлектән чыгарылды“ дип языла. Исемлектән чыгарылган китаплар турында инвентарь кенәгәсенә язылган язуларны һич тә сызып ташларга ярамый. Исемлектән чыгарылган китапларның карточкалары көтепханә каталоглары арасыннан алыналар. Бер квартал, ярты ел, бер ел үткәч үткән чор эчендә фондтан чыккан китапларга йомгак ясала.

## § 4. КӨТЕПХАНӘ ФОНДЫ ХӘРӘКӘТЕНӘ ГОМУМИ ТУЛАЙ УЧЕТ

Һәрбер алынган яки чыккан китапны индивидуаль тәртиптә учетка алудан тыш китапларның керүенә һәм чыгуына гомуми тулай учет алып барыла.

Көтепханәнең китап байлыгын тулай учетка алу өчен **көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсе** хезмәт итә.

Ул ике кисәктән тора:

1 нче кисәк. Китаплар, журналлар һәм брошюралар кереме (61 нче битне кара).

2 нче кисәк. Китаплар, журналлар һәм брошюралар чыгымы.

Алынган китапларның һәр партиясе, кабул ителгәннән соң ук, көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсенең беренче кисәгенә языла бара. 1 нче графада — язу датасы, 2 нче графада—язуның тәртип №, 3 нче графада—китапның каян алынуы, 4 нче графада—документның № ы һәм датасы, 7 нче һәм 8 нче графаларда— инвентарь кенәгәсенә язылырга тиешле барлык китапларның гомуми бәясе языла. Шуннан соңгы графаларны тутыру беркадәр хәзерлек эшләре алып баруны сорый. Иң элек шушы алынган китаплар ике өлешкә бүленә: а) инвентарь кенәгәсенә язылырга тиешле китаплар, журналлар һәм брошюралар һәм б) брошюраларны теркәү дәфтәренә язылырга тиешле брошюралар. Бу брошюраларның саны исәпкә алына да аларның гомуми данә саны һәм бәясе соңгы графадан алдагы гына графага языла. Аннары инвентарь кенәгәсенә язылырга тиешле данәләрнең гомуми исәбе алына да 5 нче графага языла.

Бу әсәрләрдән журналлар аерып алына һәм аларның саны 6 нчы графада күрсәтелә. Аннары, инвентарь кенәгәсенә язылырга тиешле барлык әсәрләр бүлекләргә бүленә: иҗтимагый-политик әдәбият, табигать белеме һәм математика, техника, авыл хуҗалыгы, матур әдәбият, балалар әдәбияты, башка китаплар. Һәр бүлектәге китаплар саны 9—17 графаларга языла.

Иҗтимагый-политик әдәбияттан: а) марксизм-ленинизм классиклары әсәрләре, б) хәрби әдәбият аерым рәвештә исәпләнә.

Марксизм-ленинизм классиклары әсәрләренең саны 10 нчы графага, хәрби китаплар саны—11 нче графага языла.

Әгәр дә көтепханәгә рус телендә генә түгел, бәлки СССР да яшәүче башка халыклар телләрендә яки чит илләр телләрендә китаплар алынса, ул чакта төрле телләрдәге бу китапларның санын язу өчен 18—21 нче графалардан файдаланыла.

Алынган китапларның һәр партиясен язу өчен бер юл бирелә. Бит тулгач, барлык графалар буенча го-

муми йомгаклар ясала һәм бу йомгаклар икенче битнең беренче юлына күчереләләр.

Шуның өстенә һәр үткән квартал саен һәм һәр үткән ел саен алынган китапларның саны исәпләнә һәм шулай итеп китап байлыгының үсүе беленә.

Китапларның чыгышы көтепханә фонды хәрәкәте кенәгәсенең икенче кисәгендә исәпкә алыналар. Монда тәртибе белән түбәндәгеләр языла: 1) язу датасы, 2) китапларның исемлектән чыгуы турындагы актның тәртип № ы, 3) исемлектән чыккан китапларның, журналларның һәм брошюраларның гомуми бәясе, 4) көтепханәнең инвентарь кенәгәсенә язылган китапларның, журналларның һәм брошюраларның данәләр саны, 5) көтепханәнең инвентарь кенәгәсендә булып, исемлектән чыккан китапларның, журналларның һәм брошюраларның бүленеше (көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсенең беренче кисәгенең 9—21 нче графаларында күрсәтелгән бүлекләр һәм телләр буенча ук), 6) исемлектән чыккан китапларның, журналларның һәм брошюраларның чыгу сәбәпләре буенча (тузу, укучылар тарафыннан кайтарылмау, искерү, башка сәбәпләр буенча) бүленеше, 7) брошюраларны теркәү дәфтәренә язылып, исемлектан чыккан брошюраларның данә саны.

Көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсен һәрбер массовый көтепханә алып барырга тиеш.

## § 5. КӨТЕПХАНӘ ФОНДЫН ТИКШЕРҮ

Көтепханә китаплары, журналлары һәм брошюралары дәүләт яки җәмәгать оешмалары акчасына сатып алыналар һәм социалистик милек булып исәпләнәләр. Аларны дөрес исәпкә алырга һәм яхшылап сакларга кирәк. Китапларның яхшы саклануын тәэмин итә торган шартларның берсе—көтепханә фондын регуляр рәвештә тикшереп тору. Китаплары 10000 томга кадәр булган кечкенә көтепханәләрдә тикшерү ел саен үткәрелә, китаплары 10000 томнан артык булган көтепханәләрдә—ике елга бер тапкыр үткәрелә.

Китаплары 10000 томга кадәр булган көтепханә фондын тикшерү өчен, булган китаплар һәм брошюралар инвентарь кенәгәсе һәм брошюраларны теркәү дәфтәре буенча барлап чыгыла. Көтепханә эшчеләреннән берәү китапларны тәртибе белән киштәдән ала, аларның авторларын, исемнәрен һәм инвентарь номерларын

әйтеп тора. Икенче работник исеме чыккан шушы китапны инвентарь кенәгәсеннән эзләп таба һәм „Тикшерү билгесе“ дигән графада шартлы билге (әвернә, плюс галәмәте) куя. Брошюраларны теркәү дәфтәре буенча булган брошюраларны тикшергәндә („Искәрмә“ графасында) көтепханәдә булган һәр исемнең даналәр саны күрсәтелә.

Аннары инвентарь кенәгәсендә һәм брошюраларны теркәү дәфтәрендә укучылар кулындагы яки күчмә көтепханәләргә бирелгән китаплар һәм брошюралар турында билгеләр ясала.

Инвентарь кенәгәсендә бернинди билге куелмыйча калган китаплар көтепханәдә юк һәм югалган дип саналырга тиешле булалар.

Китаплары 10.000 томнан артык булган көтепханәләрдә китап фондын тикшерүне топографик каталог ярдәмендә үткәрергә киңәш бирелә.

Топографик каталог түбәндәге үрнәк буенча язылган карточкалардан төзелә:

| | |
|---|---|
| | 9845 |
| П 91 Пушкин А. С. | |
| Поэмалар | |

Китапның һәр данәсенә топографик каталогта бер карточка була; китаплар киштәләрдә нинди тәртиптә торсалар, бу карточкалар да нәкъ шундый ук тәртиптә торалар.

Топографик каталог карточкаларның берничек тә югалуына мөмкинлек калдырмый торган шартларда (бикле шкафта һ. б. ш.) сакланырга тиеш.

Көтепханә фондын тикшергәндә бер работник китапларны киштәләрдән ала да аларның авторларын, китапның исемен һәм инвентарь номерларын әйтеп тора.

Икенче работник топографик каталогта шушы китапның карточкасын эзләп таба, карточкага һәм китапка штемпель суга яки билге ясый. Киштәләрдәге китаплар һәм топографик каталогтагы карточкалар бертөсле тәртиптә торганлыктан, фондны топографик каталог белән барлау инвентарь кенәгәсе буенча барлауга караганда шактый тизрәк бара. Шуның өстенә китап-

1945 ел

# ИНВЕНТАРЬ КЕНӘГӘСЕ

| Язу датасы | Инвентарь № | Тикшерү билгесе | | | Автор һәм китапның исеме | Басмасы | | | Китапның бәясе | | Төпләү бәясе | | Көтепханә фондының хәрәкәт кенәгәсенә язу № | Бүлек | Чыгу билгесе (акт № һәм дата) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Ничәнче | Урыны | Елы | Сум | Тиен | Сум | Тиен | | | | |
| 25.V | 7201 | | | | Сталин, И. Сов. Союзының Бөек Ватан сугышы турында | 4 | М. | 1944 | 1 | 50 | | | 26 | З | | |
| | 7202 | | | | " " " | 4 | " | 1944 | 1 | 50 | | | | З | | |
| | 7203 | | | | " " " | 4 | " | 1944 | 1 | 50 | | | | З | | |
| | 7204 | | | | " " " | 4 | " | 1944 | 1 | 50 | | | | З | | |
| | 7205 | | | | Иосиф Виссарионович Сталин (Кыс. биог.) | | Л. | 1944 | 2 | 50 | | | | З | | |
| | 7206 | | | | Афанасьев һәм Шапошников. Уч. русс. яз. ч. I | 12 | М. | 1944 | — | 35 | | | | 4 | | |
| | 7207 | | | | Драгунов, М. В. Фронт бригадалары | | М. | 1944 | 3 | — | | | | З | | |
| | 7208 | | | | Чехов, А. П. Тулы әсәрләр җыентыгы I том | | М. | 1944 | 15 | — | | | | Б | | |
| | 7209 | | | | Мамин-Сибиряк, Д. Н. Сайланма әсәрләр | | Молотов | 1944 | 5 | — | | | | Б | | |
| | 7210 | | | | Новый мир, № 1 | | М. | 1945 | 5 | — | | | подп. | О | | |
| 28.V | 7211 | | | | Знамя, № 1 | | М. | 1945 | 5 | — | | | подп. | О | | |
| | 7212 | | | | Энгстранд, С. Норвегия язы | | М. | 1944 | 8 | — | | | 27 | Б | | |
| | 7213 | | | | Ватан турында. Җыентык | | М. | 1944 | 6 | — | | | | Б | | |
| | 7214 | | | | Маркс һәм Энгельс архивы, 9 том | | Л. | 1941 | 5 | — | | | | З | | |
| | 7215 | | | | Сталин, И. Халыкка мөрәҗәгать | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| | 7216 | | | | " " " " | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| | 7217 | | | | " " " " | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| | 7218 | | | | " " " " | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| | 7219 | | | | " " " " | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| | 7220 | | | | " " " " | | М. | 1945 | — | 20 | | | | З | | |
| 30.V | 7221 | | | | Кюри, Е. Мари Кюри тормышы | | М. | 1944 | 8 | — | 1 | — | | 92 | | |
| | 7222 | | | | " " " " " | | М. | 1944 | 8 | — | 1 | — | | 92 | | |
| | 7223 | | | | Большая Сов. Энциклопедия, 50 том | | М. | 1944 | 25 | — | — | — | 28 | 0 | | |
| | 7224 | | | | " " " | | М. | 1944 | 25 | — | — | — | | 0 | | |
| | 7225 | | | | " " " | | М. | 1944 | 25 | — | — | — | | 0 | | |

ларны топографик каталог ярдәмендә тикшерүне бер үк вакытта фондның берничә бүлеге буенча эшләргә мөмкин. Аннары топографик каталог белән укучылар формулярлары, күчмә көтепханәләргә бирелгән китап ларның формулярлары һәм китапның бирелүен таныклый торган бүтән документлар барлап чыгыла.

Топографик каталогның тикшерү турында билге ясалмый калган карточкалары каталогтан алынып, инвентарь номерлары тәртибендә тезелеп куела. Шушы карточкалар нигезендә югалган китапларның исемлеге төзелә һәм бу исемлек көтепханәне тикшерү актына теркәлә. Шушы исемлек ярдәмендә югалган китапларның исемлектән чыгарылуы турында инвентарь кенәгәсендә билге ясала. Бу вакытта булган китаплар турында инвентарь кенәгәсендә бернинди билге куелмый, „көтепханәне тикшерү билгесе" дигән графа тутырылмыйча кала.

Көтепханәне тикшерү йомгаклары турында көтепханәнең хуҗасы булган оешма вәкиле катнашы белән акт төзелә. Актта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1. Нинди документлар тикшерелде (инвентарь кенәгәләре; көтепханә фондын үткәндәге тикшерү актлары; исемлектән чыгарылган китапларга төзелгән актлар-исемлекләр; күчмә көтепханәләргә бирелгән китапларның формулярлары; укучылар формулярлары).

2. Көтепханәдә күпме китап һәм брошюра булырга тиеш (инвентарь кенәгәләре буенча күпме китап һәм брошюраларны теркәү дәфтәре буенча күпме брошюра исәпләнә; актлар буенча күпме китап һәм брошюра исемлектән чыгарылган; исемлектән чыгарылган китапларны һәм брошюраларны чигергәч, фондта күпме китап һәм брошюра исәпләнә).

3. Тикшерү нәтиҗәсендә нәрсәләр беленде: киштәләрдә күпме китап, журнал һәм брошюра бар, укучылар кулында күпме китап исәпләнә, күчмә көтепханәләргә күпме китап бирелгән, инвентарьга кергән китапларның, журналларның һәм брошюраларның күпмесе җитми, һәм брошюраларны теркәү дәфтәренә язылган брошюраларның күпмесе җитми; җитми торган китапларның, журналларның һәм брошюраларның гомуми бәясе нинди.

4. Нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр (укучылар кулында озак торган китапларны җыю турында, китап байлыгын учетка алуны һәм аны саклауны яхшырту турында).

Тикшерүнең максаты—фактта китапларның барлыгын һәм җитмәгәнлеген ачыклау гына түгел, бәлки шулай ук китапларның югалу сәбәпләрен ачыклау һәм бу сәбәпләрне бетерү. Тикшерү көтепханә фондын саклауның ничек оештырылуын, көтепханәдә китапларның саклануы өчен көрәшнең ничек алып барылуын бик ачык күрсәтеп бирә. Көтепханәне тикшергән вакытта китапларның бик аз гына булса да җитмәве көтепханә эшчеләренең игътибарын үзенә тартырга тиеш һәм аларны китапларның саклануы буенча кискен чаралар күрергә мәҗбүр итәргә тиеш.

## Көтепханәнең китап байлыгын тикшерү актының үрнәк формасы

## АКТ №...

.............................................................. көтепханәсенең
(көтепханәнең исеме)
китап фондын тикшерү турында.

194......елның ............................ аеның.................көнендә без түбәндә кул куючы көтепханә мөдире...............................................
(фамилиясе, исеме һәм
................................................һәм......................................ның вәкиле.........
атасының исеме) (учреждение исеме)
.............................................................. түбәндәгеләр турын-
(фамилясе, исеме һәм атасының исеме)
да шушы актны төзедек:

194 ......елның „..........“ нән алып „..........“ нә кадәр вакыт эчендә без .................................................. көтепханәнең китап фондын
(көтепханә исеме)
.............................................. юл белән тикшерү үткәрдек.
(тикшерү ысулы күрсәтелә)

Түбәндәге документлар тикшерелде:

а) Инвентарь кенәгәләре.............................................
(инвентарь кенәгәләренең номерларын һәм һәр кенәгәдәге беренче һәм соңгы номерны күрсәтергә.)

б) Көтепханәнең китап фондын үткән тикшерү вакытында 194......елның „..........“ ндә төзелгән актны.

в) Ике тикшерү арасында инвентарьдан чыгарылган китапларга төзелгән акт-исемлекләр.............................................
(актларның номерларын күрсәтергә).
..............................................................................................

г) Күчмә көтепханәләргә китап бирүне таныклый торган документлар.

д) Абонемент укучыларына китап бирүне таныклый торган документлар.

е)..............................................................................
..............................................................................................

Тикшерү нәтиҗәсендә беленде:

1. Инвентарь кенәгәләре буенча.......................................
(санны язып күрсәтергә)
том китап, журнал һәм брошюра инвентарьга алынган исәпләнә.

Шуның өстенә „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар ..................

2. Шулардан элек актлар буенча чыгарылган:

а) инвентарьга алынган .................. кадәр китап,
(санны язып күрсәтергә)
журнал һәм брошюра;

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган .................. кадәр брошюра.

3. Инвентарьдан чыгарылганнарны чигергәннән соң, яңадан исәпкә алу моментына барлыгы түбәндәгечә исәпләнә:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том
(санны язып күрсәтергә)

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. кадәр.

**Тикшергәндә беленде:**

1. Китап киштәләрендә барлары:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том
(санны язып күрсәтергә)

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. данә.

2. Укучылар кулында исәпләнә:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том
(санны язып күрсәтергә)

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. данә.

3. Күчмә көтепханәләрдә:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том
(санны язып күрсәтергә)

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. данә.

4. Төпләүдә һәм ремонтта .................. том.

Барлыгы 194...... елның .................. нә исәпкә алынды:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. данә.

**Җитми:**

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. том
(санны язып күрсәтергә)

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар .................. данә.

**Гомуми суммасы:**

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар .................. сум .................. тиен.

(Җитмәгән томнарның тулы исемлеге актка кушымта итеп бирелә)

.................. том китап, журнал һәм брошюраның инвентарьга язылмаганлыгы беленде.

Укучыларга бирелгән әдәбиятны тикшергәндә укучыларның түбәндәгечә бурычлылыгы ачылды:

Укучыларга 194……елга кадәр бирелеп тә тикшерү вакытына кайтарылмаган:

а) инвентарьга алынган китаплар, журналлар һәм брошюралар……………………том

б) „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралар ……………………данә.

Укучыларга 194……елда бирелгәннәрдән тикшерү моментына срогына кайтарылмаган……………………том.

Нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр (җитмәгән әдәбият турында, срогына кайтарылмаган китаплар турында, китапларның учетын, саклануын яхшырту һәм башкалар буенча).

Имзалар:

## § 6. КӨТЕПХАНӘ ФОНДЫН ТАПШЫРУ ҺӘМ КАБУЛ ИТЕП АЛУ

Көтепханә мөдирләре алышынганда көтепханә фондын тикшерү яки яңадан учетка алу аеруча кирәкле. Көтепханә мөдире көтепханәнең һәр китабы өчен җавап бирә. Икенче эшкә күчкәндә ул үзенә ышанып тапшырылган китап байлыгы турында отчет бирергә тиеш.

Китап байлыгын тапшырганда-кабул иткәндә түбәндәге форма буенча акт языла:

### АКТ

**Көтепханәнең китап байлыгын тапшыру-кабул итү турында**

194—ел ……………нең……………көне.

Без түбәндә кул куючы ……………………………………
(фамилияләр күрсәтелә)

бу актны шул турыда төзедек: көтепханәне ……………………
(тапшыручының

……………………………………тән……………………………………
фамилиясе) (кабул итүченең фамилиясе)

кә тапшырганда ……………………………………
(тикшерү юлы күрсәтелә)

тикшергәндә түбәндәгечә табылды:

1. Көтепханәнең барлык инвентарь кенәгәләре буенча…………… китап, журнал, брошюра исәпләнә; шуның өстенә „брошюраларны теркәү дәфтәре“нә язылган брошюралар……………данә исәпләнә.

2. Инвентарь кенәгәсенә кертелгән китаплардан……………данә китап, һәм „брошюралар теркәү дәфтәренә“ язылган брошюралардан……………данә брошюра көтепханәдә бар.

3. Инвентарьга кертелгән китапларның..................данәсе, брошюраларны теркәү дәфтәренә язылган брошюраларның ..................данәсе укучылар кулында.

4. Инвентарьга кертелгән китапларның..................данәсе һәм брошюраларны теркәү дәфтәренә язылган брошюраларның———данәсе күчмә көтепханәләрдә.

5. .............. данә китап төпләүдә.

6. Инвентарьга кертелгән китапларның..................данәсе һәм „брошюраларны теркәү дәфтәренә“ кергән брошюраларның .............. данәсе актлар буенча исемлектән чыгарылган.

7. Көтепханәдә..................данә китап һәм..................данә брошюра инвентарьга алынмаган.

8. 194......елда............китап, 194—елда..........китап укучылар кулында калган.

Көтепханәне тапшыручы имзасы.

Көтепханәне кабул итеп алучы имзасы.

## *V БУЛЕК*

## КӨТЕПХАНӘДӘГЕ КИТАПЛАРНЫ КАТАЛОГКА САЛУ

### § 1. КӨТЕПХАНӘДӘ КАТАЛОГЛАР НИК КИРӘК, АЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

Укучылар көтепханәдә нинди авторларның, нинди мәсьәләләр буенча нинди китаплары барлыгын белә алсыннар өчен көтепханәләр китапларга каталоглар төзиләр. Каталоглар билгеле тәртиптә төзелә.

Каталог көтепханә фондына юл күрсәткеч булып тора, укучыларга булган әдәбият белән танышырга һәм кирәкле китапны сайларга мөмкинлек бирә. Көтепханә эшчесенә каталог фондны комплектлаганда, китапларны укучыларга тәкъдим иткәндә, белешмә-библиография эшләре үткәргәндә, китап күргәзмәләре оештырганда ярдәм итә.

Кечкенә массовый көтепханәләрдә каталогларның ике төрлесе: системалы һәм алфавитлы каталоглар кулланыла. Системалы каталогта унарлы классификациянең төп бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүленгән көтепханә фонды чагыла. Шулай итеп, системалы каталог һәр бүлекнең һәм бүлекчәнең составын күрсәтә, төрле белем тармаклары буенча көтепханәдә нинди әдәбият бар дигән сорауга җавап бирә.

Алфавитлы каталог, бүлекләргә бүлмәстән, көтепханәнең барлык китапларын эченә ала. Бу каталогка китаплар авторлар фамилияләренең (һәм авторлы булмаган китапларның үз исемнәренең) алфавит тәртибе буенча языла.

Алфавит каталогы: көтепханәдә теге яки бу авторның китаплары бармы? Көтепханәдә бу авторның, атап әйткәндә, нинди китаплары бар? дигән сорауларга җавап бирә.

Һәрбер массовый көтепханәнең, минимум сыйфатында системалы каталогы булырга тиеш. Фонды 10 000 томнан артык булган көтепханәләр өчен алфавитлы каталогның булуы мәҗбүри, фонды шуннан кечкенәрәк булган көтепханәләр өчен мәҗбүри түгел, ләкин булуы яхшы.

Тагын да зуррак көтепханәләрдә системалы һәм алфавитлы каталоглардан тыш предметлы каталог кулланыла. Предметлы каталогта әдәбият предметлар, темалар һәм китапларда сөйләнелә торган мәсьәләләр буенча сайлана. Предметлы рубрикларның исемнәре каталогта алфавит тәртибендә урнаштырылалар, һәр предмет буенча әдәбият рубрик эчендә дә шулай ук авторлар фамилияләренең алфавит тәртибендә дә саналалар.

Предметлы каталог аерым мәсьәләләр буенча, кайвакытларда бик тар мәсьәләләр буенча, әдәбиятны эзләп табу өчен зур уңайлыклар бирә. Мәсәлән, укучыга вулканнар турында әдәбият кирәк. Системалы каталог буенча без табигать белеме бүлеген эзләп табарга тиешбез, бу бүлектә „геология“ бүлекчәсен табарга, бу бүлекчәдә төрле китаплар арасыннан вулканнар турында сөйли торган китапларны эзләп табарга тиешбез. Предметлы каталог булганда „вулканнар“ дигән рубрикны табу җитә, вулканнар турында көтепханәдә булган барлык әдәбият шушы рубрикта күрсәтелгән булачак.

Ләкин предметлы каталогны зур көтепханәләр генә төзи алалар. Авыл һәм район көтепханәләре системалы каталог төзү белән генә чикләнәләр. Укучыларга системалы каталогтан файдалануны җиңеләйтү өчен аңа рубрикларның мөмкин кадәр тулырак алфавитлы күрсәткечен белергә кирәк.

Каталогларның төп төрләре менә шулар. Зур көтепханәләр практикасында тагын каталогларның башка төрләре дә кулланыла: топографик каталог (монда китаплар киштәләргә куелган тәртипләрендә үк саналалар), китап исемнәре каталогы, аналитик каталог (журналларга һәм җыентыкларга кергән аерым мәкаләләр каталогы) һ. б.

Каталогны төзү һәм аннан файдалану өчен аның формасының әһәмияте бар. Файдалану өчен китап формасындагы басма каталоглар бик уңайлы. Ләкин басма каталогларга яңа китапларны кертү кыен була, һәр бүлеккә карата өстәмә каталоглар бастырырга һәм алар-

ны кушымта итеп бирергә туры килә һ. б. ш. Фондка яңа әдәбият өстәлә торганлыктан басма каталог артка кала.

Шуңа күрә безнең кpropagationөтепханәләрдә карточкалы каталоглар кулланыла. Һәр китап аерым үрнәктәге карточкада тасвир ителә.

Карточкалар, каталогның төренә карап, системалы яки алфавитлы тәртиптә тезеп куелалар. Системалы һәм алфавитлы каталоглар көтепханәнең китап фондын тулысы белән чагылдырырга тиешләр. Яңа килгән китаплар тоткарсыз рәвештә каталогларга кертелергә тиешлеләр. Моңа карточкалар ярдәмендә ирешелә дә. Көтепханәгә яңа китаплар, брошюралар һәм башкалар шул карточкаларда тасвир ителәләр. Дөрес, карточкалы каталогтан файдалану басма каталогтан файдалануга караганда уңайсызрак. Бик күп карточка актарырга һәм карарга, күп вакыт әрәм итәргә туры килә, ләкин карточкалы каталогның басма каталогка караганда шактый тулырак булуы бу уңайсызлыкны каплый.

## § 2. КИТАПЛАРНЫ ТАСВИР ИТҮНЕҢ ТӨП КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Көтепханә каталоглары карточкалардан тора. Һәр китап аерым карточкада тасвир ителә. Шулай да, әгәр дә бер үк исемдәге яки бер үк басмадагы китап берничә данә булса, алар барысы да бер карточкага языла. Көтепханә каталогының карточкалары стандарт формада һәм күләмдә булалар (биеклеге 7,5 см., киңлеге 12,5 см.). Каталог карточкасының 11 горизонталь линиясе һәм 2 вертикаль (сул якта) линиясе була. Өстәге горизонталь юл һәм вертикаль линияләр кызыл буяу (яки куе кара буяу) белән басылган булалар. Вертикаль линияләр яңа юлларны дөрес башлау өчен хезмәт итәләр.

Карточканың түбәндәге башында карточкаларны тимер чыбык белән беркетү мөмкин булсын өчен тишек тишелгән була.

Карточкаларга язган язулар, ансат укырлык булсын өчен, басма хәрефләрне хәтерләтә торган махсус көтепханә кулъязмасы белән языла (1 нче рәсем).

Китапны тасвир итү аның титул бите буенча һәм түбәндәге кагыйдәләрне игътибарга алып эшләнә:

1) Әгәр дә фәнни китап тасвир ителсә, сул як югары почмакта беренче юлга индекс языла, аның астына автор билгесе языла. Әгәр дә матур әдәбият китабы тасвир ителсә, ул чакта сул як югары почмактагы беренче юлга автор билгесе языла.

## Рус алфавиты

А Б В Г Д Е Ж З И К Л М Н О П Р С

Т У Ф Х Ц Ч Ш Щ Э Ю Я

а б в г д е ж з и к л м н о п р с т у ф х

ц ч ш щ ъ ы ь э ю я

1 нче рәсем. Көтепханә кулъязмасы.

2) Өстәге горизонталь линиягә, сул як вертикаль линиядән башлап, авторның фамилиясен язалар. Авторның фамилиясе, титул битендә ничек бирелүенә карамастан, баш килештә языла. Мәсәлән: „Александр Сергеевич Пушкин әсәрләре“ дигәнне „Пушкин, А. С. Әсәрләр“ дип языла.

Әгәр дә китапның авторы булмаса яки дүрт һәм аннан күбрәк авторлы булса, бу китап үзенең исеме буенча тасвир ителә, мәсәлән: „ВКП (б) ның XVIII Бөтенсоюз конференциясе резолюцияләре“.

3) Өстән икенче юлга, уң як вертикаль линиядән башлап, китапның исемен, ә аның артыннан ук—подзаголовогын язалар. Кыскартып язарга да мөмкин, тик җитәрлек дәрәҗәдә аңлашылырлык булсын. Мәсәлән, „тулыландырылган һәм төзәтелгән икенче басмасы“ урынына „тулы һәм төзәт. 2 нче басм.“ дип язалар;

„Иванов редакциясендә һәм аның кереш сүзе белән“ урынына „Иванов ред. һәм кер. сүз“ дип, „русчадан (французчадан, инглизчәдән, немецчадан) тәрҗемә“ урынына „рус. (франц., ингл., нем.) тәрҗ.“ дип язалар. һ. б.

4) Китапның исеменнән (яки подзаголовогыннан) соң бераз буш урын калдыралар, аннары китапның басылган урыны, елы, издательство исеме кебек мәгъ-

лүматлар языла. Китап басылган урыннарының исемнәре тулысынча язылалар. Москва белән Ленинград кыскартып: М. һәм Л. дип кенә языла. Издательствоның исеме дә кыскартып, ләкин яхшы аңлашылырлык итеп языла. Мәсәлән, „Государственное издательство политической литературы“ урынына—Госполитиздат дип, „Государственное издательство совхозной и колхозной литературы“ урынына — Сельхозгиз дип, „Государственное издательство художественной литературы“ урынына—Гослитиздат дип языла һ. б.

Китапның басылган елы гарәп цифрлары белән „ел“ сүзен өстәмичә генә язылалар, мәсәлән: „1941“, „1942“ яки „1943“. Бу мәгълүматлар бер-берсеннән нокталар белән аерылалар: М. Гослитиздат. 1943.

Шушы мәгълүматлардан соң яңа юлда бит саны бирелә, мәсәлән: 135 бит. Әгәр дә китап рәсемле, карталы булса, бу түбәндәгечә билгеләнә: „135 бит рәсемле“ яки „135 бит карталы“.

6. Әгәр дә китапның титул битендә надзаголовок булса, ул тасвирлауның азагында җәя эчендә бирелә, мәсәлән: („Тарихи романнар“), („Шагыйрь көтепханәсе“), (СССР Фәннәр Академиясе), (РСФСР Наркомпросы).

Каталог карточкаларында китапларны тасвир итү үрнәге:

| | | |
|---|---|---|
| 32 В | Ярославский, Е. | |
| Я 76 | | Большевиклар—рус халкының иң яхшы па- |
| | триотик традицияләрен дәвам иттерүчеләр. М. | |
| | „Молодая гвардия“. 1942. | |
| | | 12 бит „(Пропагандист-комсомолецка ярдәмгә“). |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Китапларны тасвир иткәндә түбәндәге аерым хәлләрне күздә тотарга кирәк:

1. Әгәр дә китап аерым-аерым басылган берничә кисәктән яки томнан торса, аның барлык кисәкләре һәм томнары бер карточкага язылалар. Әсәрләр җыентыклары да бер карточкага җыеп тасвир ителәләр.

2. Әгәр дә авторның фамилиясе яки кушаматы төрле басмаларда төрлечә бирелсә, автор фамилиясенең билгеле бер формасын алырга һәм барлык хәлләрдә шуны язарга кирәк. Мәсәлән, Салтыков-Щедрин әсәрләренең төрле басмаларында яки авторның чын фамилиясе— „М. Е. Салтыков“ бирелә, яки кушаматы—„Н. Щедрин“, яки чын фамилиясе һәм җәя эчендә кушаматы—„М. Е. Салтыков“ (Н. Щедрин), яки фамилиясенә кушаматын өстәп—„М. Е. Салтыков-Щедрин“дип бирелә. Бер форманы сайлап алырга һәм тасвир ителә торган китапта ничек күрсәтелүенә карамастан, авторның фамилиясен шул рәвешчә яза бирергә кирәк. Ул вакытта М. Е. Салтыков-Щедрин әсәрләренә язылган карточкалар каталогта бер урынга җыйналган булырлар.

3. Әгәр дә китапның индексы ике катлы булса һәм ул системалы каталогның ике бүлегенә кертелергә тиеш булса, ул чагында ике карточка языла: берсе— төп карточка, икенчесе—өстәмә карточка. Өстәмә карточкада беренче индекс яки шифр саклана һәм шуның өстенә сул як түбәнге почмакта икенче индекс яки шифр күрсәтелә.

## § 3. СИСТЕМАЛЫ КАТАЛОГТА КАРТОЧКАЛАРНЫҢ КУЕЛЫШЫ ҺӘМ АНЫҢ ФОРМАЛАШТЫРЫЛУЫ

Каталог карточкалары биеклеге карточкадан беркадәр тәбәнәгрәк, озынлыгы 40 см. чамасы булган агач тартмаларга куелалар. Һәр тартмага чама белән 1000 карточка сыя.

Карточкалар унарлы классификациянең бүлекләре буенча куелалар—0, 1, 2, 3, һ. б., һәр бүлек эчендә аның төп бүлекчәләре буенча, һәр бүлекчә эчендә— автор билгесенә ярашлы рәвештә авторлар фамилияләренең алфавиты буенча куелалар.

ЗК1 (Маркс һәм Энгельс әсәрләре), ЗК2 (В. И. Ленин әсәрләре), ЗК3 (И. В. Сталин әсәрләре) бүлекчәләрендә

карточкаларны урнаштыруда аерым тәртип кулланыла. Бу бүлекчәләрдә бер үк авторның әсәрләре урнаштырылганлыктан, автор билгесе китап исеменең беренче сүзе буенча бирелә һәм карточкалар тиешле рәвештә тезеп куелалар. Башта әсәрләр җыентыкларының карточкалары, аннары сайланма әсәрләрнеке һәм ниһаять—аерым әсәрләрнең карточкалары тезелә.




2 нче рәсем. Системалы каталогта бүлекнең бүленеш үрнәге.

Барлык бүтән бүлекләрдә һәм бүлекчәләрдә Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләренең шушы бүлегенә яки бүлекчәсенә карый торган китапларына өстәмә карточкалар беренче итеп—алфавиттан тыш—куела (мәгълүм ки, марксизм-ленинизм классикларының әсәрләренә төп карточкалар ЗК1, ЗК2, ЗКЗ бүлекчәләрендә җыйнала), аннары партия һәм хөкүмәт карарлары әсәрләренә язылган карточкалар, аннан соң авторларның алфавиты буенча барлык бүтән карточкалар куела.



3 нче рәсем. Системалы каталог тартмасы.

Каталогта карточкаларны табу эшен җиңеләйтү өчен аның һәр бүлеге һәм бүлекчәсе алдына бүлгечләр, ягъни бүлек (яки бүлекчә) билгесе һәм аның исеме язылган

чыгынтылы карточкалар куела. Бүлекләрне бүлгечләрдә аларның бүлекчәләрен язып куярга киңәш бирелә. Һәр каталог тартмасына анда нинди бүлекләр барлыгын күрсәтә торган язу язып куярга кирәк.

Каталог тартмасы өстенә каталогның төп бүлекләренең һәм бүлекчәләренең алфавитлы исемлеген элеп куярга кирәк. Бу исемлек системалы каталогта карточкаларны ничек эзләргә кирәклекне күрсәтер.

## § 4. АЛФАВИТЛЫ КАТАЛОГТА КАРТОЧКАЛАРНЫҢ КУЕЛЫШЫ ҺӘМ АНЫҢ ФОРМАЛАШТЫРЫЛУЫ

Карточкаларның алфавит тәртибендә (алфавитлы) куелышы матур әдәбият бүлегендә, шулай ук фәнни бүлекләрнең һәм бүлекчәләрнең эчендә системалы каталогта да кулланыла. Алфавитлы каталогта барлык карточкалар авторлар фамилияләренең яки китап исемнәренең (авторы булмаганда) алфавиты тәртибендә куелалар. Карточкаларны алфавит тәртибендә тезеп куюның төп кагыйдәләре түбәндәгечә:

1. Карточкаларны тезеп куйганда, эшне җиңеләйтү өчен автор билгеләреннән файдаланып, нәкъ алфавит белән эш итәргә кирәк.

2. Автор билгеләре бертөсле булганда авторлар фамилияләренең шуннан соңгы иҗекләрен игътибарга алырга һәм карточкаларны тезеп куйганда фамилиянең соңгы иҗегенә кадәр алфавит тәртибен сакларга кирәк. Мәсәлән, автор билгеләре бертөсле (В 19) булган авторларның—Васильев, Василевский, Василевская, Васильева, Васнецов кебек авторларның карточкаларын мондый тәртиптә тезәргә кирәк: Василевская, Василевский, Васильев, Васильева, Васнецов.

3. Авторларның фамилияләре бертөсле булганда, карточкалар автор инициалларының алфавиты тәртибендә тезелеп куелалар, мәсәлән:

Васильев А.
Васильев А. Н.
Васильев И. Н.
Васильев К. Л.
Васильев К. С. һ. б.

4. Ике катлы фамилияле авторларның карточкалары беренче фамилияләре бертөсле булган авторлар карточкаларыннан соң куелалар, мәсәлән:

Новиков И. А.
Новиков-Прибой А. С

яки

Лебедев А. И.
Лебедев-Кумач В. И.

яки

Сергеев С. Н.
Сергеев-Ценский С. Н.

5. Бер үк авторның аерым әсәрләренең карточкаларын тезеп куйганда билгеле тәртипне саклап эш итәргә кирәк. Башта әсәрләрнең тулы җыелмаларының карточкалары, аннары төрле җыентыкларның карточкалары, аннан соң—аерым әсәрләрнең карточкалары аларның исемнәренең алфавиты тәртибендә куелалар.

**Мисал:**

Пушкин А. С. Тулы әсәрләр җыелмасы.
Пушкин А. С. Әсәрләр.
Пушкин А. С. Драмалар.
Пушкин А. С. Дубровский.
Пушкин А. С. Евгений Онегин.
Пушкин А. С. Капитан кызы.
Пушкин А. С. Белкин повестьлары һ. б.

яки

Гончаров И. С. Обломов.
Гончаров И. С. Обрыв (Тирән чокыр)
Гончаров И. С. Гади вакыйга.

6. Бер үк китапның төрле басмаларының карточкалары кире-хронологик тәртиптә куелалар, башта иң соң чыкканнарының, аннары элек чыкканнары куела, мәсәлән:

Сталин И. В. Ленинизм мәсьәләләре. 11 нче басма.
Сталин И. В. Ленинизм мәсьәләләре. 10 нчы басма.
Сталин И. В. Ленинизм мәсьәләләре. 9 нчы басма.

7. Авторлары булмаган һәм үзләренең исемнәре буенча тасвир ителгән китапларның карточкалары авторларының фамилияләре буенча тасвир ителгән китапларның карточкалары белән аралаштырып куелалар, ләкин бу вакытта алфавит тәртибендә тезеп кую турында элек күрсәтелгән барлык кагыйдәләр җиренә җиткереп үтәлергә тиеш.

Алфавитлы каталогта хәрефле бүлгечләр кулланыла (А. Б. В. һ. б.). Бер үк бүлгеч артына тезелгән карточкалар бик күп булганда, иҗекләрне сайлаганда

автор таблицаларыннан файдаланып, ижекле бүлгечләр кулланырга мөмкин. Ниһаять, бер үк авторның әсәрләре күп булганда, фамилияләр күрсәтелгән бүлгечләр кулланалар. Мондый бүлгечләр белән беренче чиратта Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен, матур әдәбият классиклары, зур галимнәр, фәнни белемнәрне атаклы популярлаштыручылар әсәрләрен аерырга кирәк.

Алфавитлы каталогның һәр тартмасында шушы тартмага урнаштырылган карточкаларны эченә алган хәрефләр язып куела. Алфавитлы каталог өстенә шушы каталогтан ничек файдаланырга кирәклекне, андагы карточкаларның нинди тәртиптә тезеп куелганлыгын аңлата торган плакат элеп куярга киңәш бирелә.

## § 5. ТӘКЪДИМ ИТҮ ӨЧЕН ТЕМАТИК КАРТОЧКАЛАР

Массовый көтепханәләрнең укучылары үзләренә кирәкле әдәбиятны каталоглар буенча эзләп табуны еш кына авырсыналар. Кайвакытларда бу авырсынуның сәбәбе каталогның укучыларга таныш булмаган унарлы классификация системасы буенча эшләнгән булуыннан килә. Кайбер укучыларны каталогларның карточка формасында булуы читенсетә; чөнки нинди дә булса бер бүлекнең яки бүлекчәнең китаплары белән танышу өчен уннарча һәм йөзләрчә карточка карарга туры килә. Кайвакытларда укучылар, көтепханә гаебе белән—каталогларның начар хәлдә булуы, аларның шыксыз язылуы, каталогның ничек төзелгәнлеге турында күрсәтмәләрнең булмавы аркасында, каталоглардан аз файдаланалар.

Көтепханәләр каталогларны җентекләп алып барырга тиешләр, яңа әдәбиятны вакытында аңа кертә барырга, каталогларны тәмам тәртипле тотарга, каталогларның ачык итеп язылулары, бүлгечләр белән, аңлатма язулары белән тәэмин ителгән булулары турында кайгыртырга тиешләр. Көтепханә эшчеләре каталогларны пропагандаларга, укучылар белән сөйләшкәндә китапларны каталоглар буенча ничек эзләргә кирәклеген аңлатырга һәм күрсәтеп бирергә, укучыларны каталоглардан файдаланырга өйрәтергә тиешләр.

Хәзерге моментта бик әһәмиятле булган әдәбиятны пропагандалау максаты белән, төп каталогларга өстәмә рәвештә, тематик картотекалар төзелә. Мәсәлән, һәр көтепханәдә, „Совет халкының Бөек Ватан сугышы“ дигән темага әдәбият картотекасы алып барырга кирәк. Темалар сайлау өчен журналларда басыла торган лекцияләр, беседалар һәм докладлар тематикасыннан файдаланырга кирәк. Данлыклы даталарга һәм бик әһәмиятле иҗтимагый-политик кампанияләргә багышланган картотекалар төзергә мөмкин. Авыл көтепханәләрендә язгы чәчү кампаниясе, игеннәрне урып-җыю эшләре турындагы әдәбият картотекалары төзү файдалы. Картотекага билгеләнгән тема буенча бөтен әдәбиятны кертү мәҗбүри түгел, иң яхшы, иң күп тәкъдим ителгән китапларны, брошюраларны һәм газета-журнал мәкаләләрен сайлап алу җитә.

Картотекаларны газета-журнал мәкаләләре белән тулыландыру өчен системалы рәвештә газета-журналларны карап барырга, ягъни бик мөһим мәкаләләрне алардан аерым карточкаларга язып алырга кирәк. Газета һәм журнал мәкаләләрен пропагандалау көтепханәнең ресурсларын шактый киңәйтә һәм укучыларның вакытлы матбугаттан файдалануын көчәйтә. Үзенең мөмкинлекләренә карап, көтепханә системалы рәвештә язып бару өчен журналлар даирәсен, беренче чиратта „Большевик“, „Пропагандист“, „Партийная жизнь“, „Знамя“, „Новый мир“ журналларын, „Правда“, „Известия“, „Комсомольская правда“ газеталарын һәм башкаларны сайлый.

Билгеләнгән журналлардан мәкаләләрнең барысы да язып алынмый, бәлки бик әһәмиятлеләре генә язып алына. Мәкаләләр карточкаларда түбәндәге үрнәктә тасвир ителәләр:

> *Агитация һәм пропаганда.*
>
> Авыл халкы өчен политик докладлар турында (баш мәкалә). „Спутник агитатора“ журналы. 1944 ел. № 10, 1—4 бит.

Уң як югары почмакка тематик рубрик языла. Картотекалар төзегәндә иң әһәмиятлесе—рубриклар системасын билгеләү. Рубрикларны тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләреннән, Бөек Ватан сугышы турындагы

материалларны классификацияләү схемасыннан алырга мөмкин (Л. Н. Троповскийның „Унарлы классификация“ исемле китабының өченче басмасына кушымтаны кара).

Газета-журнал мәкаләләре картотекаларына күбесенчә агитаторлар, пропагандистлар, укытучылар, өлкән классларда укучылар мөрәҗәгать итәләр. Тәҗрибә шуны күрсәтә. Тик көтепханәдә нинди картотекалар алып барылуы турында укучыларга киң белдереп торырга гына, тиешле белдерүләр эләргә һәм һәр картотекага кергән тематик рубрикларның исемлекләрен эләргә кирәк. Картотекалар көтепханә эшчеләренә массовый эш алып барганда, китап күргәзмәләре оештырганда, укучыларга библиографик белешмәләр биргәндә ярдәм итәләр.

## VI БУЛЕК

## КӨТЕПХАНӘДӘ КИТАПЛАРНЫ РӘСМИЛӘШТЕРҮ, ТЕЗЕП КУЮ ҺӘМ САКЛАУ

### § 1. КӨТЕПХАНӘДӘ КИТАПЛАРНЫ РӘСМИЛӘШТЕРҮ

Көтепханәгә алынган һәр китапны, хосусый кешеләрнең китапларыннан аеру өчен, үзенә бер төрле рәвештә рәсмиләштерәләр.

Классификация нәтиҗәсендә титул битенең уң як яки сул як югары почмагына (һәр көтепханәдә — билгеләнгән бер урынга) китапның шифры языла.

Китапларны килгән документ белән барлаганнан соң титул битенең йөз ягына, 17 нче биткә көтепханәнең исеме язылган штамп басыла.

Һәр китапта титул битенә, 17 нче биткә, шулай ук кечкенә кесәчеккә инвентарь номеры языла.

Штамп китапның шушы көтепханәнеке икәнлеген белдерү өчен хезмәт итә. Штамп сугу өчен көтепханә туры почмак төсендәге штемпель ясатып алырга тиеш. Штемпель урынына көтепханәнең түгәрәк печатен сугарга рөхсәт ителми. Әгәр дә китапта аерым кәгазьләргә басылган рәсемнәр, карталар, схемалар булса, аларга да рәсемнәрне бозмаслык итеп штамп сугыла.

Китапларны киштәләргә тезеп куюны һәм аларны эзләп табуны тизләтү өчен китаплар ярлыклар белән тәэмин ителәләр. Ярлык — квадрат яки алты почмаклык төсендәге кәгазь кисәге ул. Аңа кара яки тушь белән бик ачык итеп китапның шифрын, авторның фамилиясен, китапның исемен, том номерын, кисәген яки чыгарылышын язып куялар. Ярлык китапның корешогына, аның түбәнге кырыеннан ике сантиметр ара калдырып ябыштырыла. Юка китапларда ярлыклар тыш-

лыкның алгы ягына сул яклап югары башына ябыштырылалар. Издательство яхшылап төпләп чыгарган китаплар, мәсәлән, В. И. Ленин әсәрләренең томнары, энциклопедияләр, матур итеп эшләнгән һәм кыйммәт тора торган басма китаплар, ярлыклар белән тәэмин ителмиләр.




4 нче рәсем. Китап ярлыкларының үрнәкләре.

Ярлыклар ярдәмендә китапларны, ачып карамастан, шул ярлыкларга язылган язулар буенча гына тезеп куярга була.




5 нче рәсем. Китап формуляры.

Китапларны бирү өчен, статистик исәпләүләр өчен китап формулярлары кулланыла. Китап формулярында шифр, инвентарь номеры, автор һәм китапның исеме, томы, кисәге, чыгарылышы һәм бәясе күрсәтелә (бәяне күрсәтү мәҗбүри түгел). Китап формуляры китап тышлыгының эчке ягына аска табарак ябыштырып куелган кесәгә салып куела.

Формулярлар китапларны көтепханәнең бер бүлегеннән икенчесенә, мәсәлән, абонемент фондыннан уку залына бирүне исәпкә алу өчен файдаланылалар. Китап формулярлары күчмә эштә киң кулланылалар.

Төпләнгән китапларда тышлык белән титул бите арасына форзац дип аталган бер бит кәгазь куела. Форзацка сроклар кәгазе ябыштырыла. Китапларны

биргәндә аны кайтару срогы шушы кәгазьгә языла (шундый юл белән көтепханә китапны кайтару срогын укучының хәтеренә төшерә). Сроклар кәгазенә укучының номеры да языла. Әгәр дә укучы үз номерын онытса, бу көтепханә эшчесенә аның формулярын эзләп табарга мөмкинлек бирә.



6 нчы рәсем. Китап кесәсе.

Штамп суккач, ярлык, кесә һәм сроклар кәгазен ябыштыргач, китап формулярын язгач, китапны көтепханә техникасы кагыйдәләре буенча тәмам эшкәртелгән яки рәсмиләштерелгән дип исәпләргә була.

## § 2. КИТАПЛАРНЫ ТЕЗЕП КУЮ

Китаплар киштәләргә системага салынган алфавит тәртибендә тезелеп куелалар: башта унарлы классификациянең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча, бүлек һәм бүлекчәләр эчендә — авторлар фамилияләренең алфавиты буенча (икенче төрле әйткәндә — автор билгеләре буенча) тезеп куелалар. Системалы каталогта карточкалар нинди кагыйдә буенча тезелеп куелса, китаплар да шул ук кагыйдә буенча тезеп куелалар. Ләкин бу кагыйдәләрдән кайбер чигенүләр дә булырга мөмкин. Киштәләрдә вак бүлекчәләрне аеру мәҗбүри түгел. Китапларны киштәгә тезеп куйганда күп кенә бүлекчәләрне бер бүлеккә кушарга һәм шушы бүлек эчендә китапларны авторларының һәм аерым автары булмаган китаплар исемнәренең алфавит тәртибе буенча тезәргә мөмкин.

Киштәләргә китаплар, бик үк тыгыз итмичә, сулдан уңга таба тезеп куелалар. Һәр киштәдә уң яклап 20—25 см. киңлегендә буш ара калдырыла.

Китапларны тезүне һәм сайлап алуны җиңеләйтү өчен киштә бүлгечләре — кечкенә фанера такталар кулланыла. Аларга тушь, буяу яки кара белән индекс һәм бүлек исеме язып куела.

Бүлгечләр бүлекләр арасына язулары күренеп торырлык итеп кабыргалары белән куелалар. Бүлгеч фанераның ике ягына да языла. Бүлгечләрне ак кәгазь

ябыштырып катыргыдан, иске тышлыклардан ясарга була. Киштәләрнең карнизларына, шкафларга да шунда тезелгән китапларның нинди бүлеккә яки бүлекчәгә керүен күрсәтеп язып куела.

Үзләрендә ошаш эчтәлекле әдәбият җыйналган бүлекләрне (1, 3, 9) киштәләрдә янәшә куярга мөмкин.

Бик әһәмиятле һәм укучылар еш сорый торган әдәбият бүлекләре китап бирә торган җиргә якын урнаштырылалар. Марксизм-ленинизм классиклары әсәрләре, агымдагы мәсьәләләр буенча иҗтимагый-политик әдәбият, матур әдәбият шундый бүлекләргә керә. Марксизм-ленинизм классиклары әсәрләре 3 нче бүлекнең башында, ЗК рубригы белән куелалар. Хәлбуки, бүтән бүлекләр буенча (мәсәлән, тарихтан) китаплар сайлаганда да Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен тәкдим итәргә кирәк. Бу бүлекләрнең башына шушы бүлеккә карап та, ЗК бүлегендә тора торган китаплар урынына ул китапларның исемнәре язылган фанера яки катыргы куела.

Матур әдәбият авторлар фамилияләренең алфавиты буенча тезеп куелалар. Кечкенә һәм уртача көтепханәләрдә аны классик әдәбият, хәзерге әдәбият, совет һәм чит илләр әдәбияты дип аерырга киңәш бирелми. Ләкин Бөек Ватан сугышы темасына язылган матур әдәбиятны аерырга мөмкин. Шигырьләр һәм пьесалар җыентыкларын аеру да ярый.

Матур әдәбиятны тезеп куйганда, гомуми алфавитлы бүлгечләрдән тыш, бик күп укыла торган авторлар өчен персональ бүлгечләр кулланырга мөмкин.

Журналлар китаплардан аерым рәвештә исемнәренең алфавиты буенча, ә һәр исем эчендә — еллары һәм номерлары буенча тезеп куелалар. Агымдагы ел журналлары китап бирү урынына якын гына аерым киштәгә куелалар. Журналларның әле яңа гына алынган соңгы номерлары „Яңа журналлар“ дип язылган витринага яки тактага яки (абонемент яисә уку залы бинасында) өстәл өстенә куелалар.

Белешмә әсәрләр аерым киштәгә яки аерым шкафка куелалар. Белешмә әсәрләр өйгә бирелмиләр.

Библиографик материаллар да аерым киштәгә куелалар. Укучыларга алардан мөстәкыйль рәвештә файдаланырга рөхсәт ителә.

Брошюраларны теркәү дәфтәренә язылган брошюралар китаплардан аерым рәвештә системалы-алфа-

витлы тәртиптә тезеп куелалар. Искергән брошюралар номерлары буенча сайлап алынып, төргәкләп бәйләп куелалар һәм көтепханә фондыннан чыгарырга рөхсәт алынганчы аерым рәвештә сакланалар. Аеруча актуаль әһәмиятле брошюралар китап бирүче көтепханә эшчесенә якын гына урында аерым ящикларда тематик тәртиптә урнаштырылалар.

Балалар әдәбияты зурлар әдәбиятыннан аерым, махсус фонд итеп, системалы-алфавитлы тәртиптә тезеп куелалар. Китапларны киштәгә куйганда балалар әдәбиятын аеру өчен, балалар китапларының шифры алдыннан Д хәрефе куялар.

## § 3. КИТАПЛАРНЫ, ЖУРНАЛ ҺӘМ ГАЗЕТАЛАРНЫ САКЛАУ

Китапларны тезеп кую һәм саклау өчен көтепханәләрдә шкафлар, стеналарга беркетелгән киштәләр һәм стеллажлар, ягъни ишексез-нисез ачык киштәле шкафлар кулланылалар. Кирәк булганда ябык шкафлардан да, шулай ук стенага кадакланган киштәләрдән дә файдаланырга туры килә, ләкин иң уңайлысы — китапларны стеллажларга куеп саклау.



7 нче рәсем. Китаплар стеллажы (бер яклы).

Стеллажларның бер яклылары һәм ике яклылары була. Бер яклы стеллажлар стена буена куелалар, ә ике яклылары — китап саклау бүлмәсенең уртасына параллель рәт итеп, араларына ике якка да яктылык төшеп торсын өчен уңайлы итеп тәрәзәләргә буй яклары белән куелалар. Стеллажларны артык тыгыз куярга киңәш бирелми, алар арасында 90—100 см. киңлегендә үтәр юл калдырылырга тиеш.

Көтепханәгә мөмкин кадәр күбрәк китап урнаштыру өчен стеллажларның бер яклыларын да, ике яклыларын да кулланырга кирәк.

Бер яклы стеллажның нормаль күләме түбәндәгечә: биеклеге — 203 см., киңлеге—100 см., тирәнлеге — 22 см., киштәләр арасы — 28 см., киштә тактасының калын-

лыгы — 2 см., цоколның (нигезнең) биеклеге — 15 см., карнизның биеклеге — 10 см. була.

Ике яклы стеллаж да шундый ук күләмдә, ләкин аның тирәнлеге 44 см. га җитә. Һәр стеллажның алты киштәсе була. Бер яклы стеллажның һәр киштәсенең арт ягында һәм ике яклы стеллажның һәр киштәсе уртасында китапларны төшеп китүдән саклый торган тәбәнәк кенә планкалар була.

Зур форматтагы журналларны һәм китапларны саклау өчен махсус стеллажлар кулланыла. Бу стеллажларның киштә аралары бер яклы стеллажларныкыннан зуррак (34 см.) һәм тирәнрәк (31 см.) булалар. Мондый шкафларда төпләнгән журналларны утыртып тезеп куярга, ә төпләнмәгәннәрен — яткырып өеп сакларга була.



8 нче рәсем. Газеталар өчен этажерка.

Иске газеталарны (газета подшивкаларын) саклау өчен түбәндәге күләмдәге стеллажлар кулланыла: биеклеге — 203 см., киңлеге — 150 см., тирәнлеге — 44 см. Мондый стеллажның 11 киштәсе була һәм алар уртадан бүленгән булалар. Агымдагы айның газеталарын саклау өчен биеклеге 150 см., киңлеге 60 см. һәм тирәнлеге 40 см. булган этажеркалар кулланыла.

Киштәләрне һәрвакыт тәртипле итеп тотарга, көтепханәгә алынган яңа китапларны һәм укучылар китереп тапшырган китапларны вакытында киштәләргә урнаштыра барырга кирәк. Көтепханәдә китапларның төрле җирдә — идәндә, тәрәзә төпләрендә, абонемент өстәле астында, шкафлар һәм стеллажлар башында өелеп ятуына һич тә юл куярга ярамый. Китапларның киштәләргә куелышында тәмам тәртип саклау — аларның саклануының бер шарты ул.

Китаплар саклана торган бина коры, якты булырга, анда вентиляция булырга тиеш. Китапларны подвал биналарда сакларга ярамый.

Әгәр дә китап саклый торган урын белән абонемент бер бүлмәдә булса, аларны бүлмә итеп яки һич

булмаса өстәлләр белән аерырга кирәк. Китап саклана торган урынга чит кешеләр кертелми.

Китапларны саклауда китап саклана торган бинаны карап тотуның зур әһәмияте бар: бу бина һәр көнне бик яхшылап җыештырылырга һәм җилләтелергә тиеш. Кышкы көннәрдә бинаны җыештыру һәм идәннәрен юу эшен мич якканчы эшләргә кирәк.

Тузан һәм юешлек китапларга зур зыян китерәләр. Тузан китапларны пычрата һәм кәгазьгә микроблар һәм бактерияләр үтеп керүгә булышлык итәләр. Юешлектән китаплар күгәрәләр, китапларның тышлыклары һәм төпләре бозыла. Шуңа күрә тузанга һәм юешлеккә каршы көрәшкә аеруча игътибар бирергә кирәк.

Көтепханәдә янгыннан саклану кагыйдәләрен яхшылап үтәү таләп ителә. Көтепханә бинасында тәмәке тарту бик нык тыела, китап стеллажларын мичләргә якын куярга ярамый, мичләрне якканда аерата саклык белән эш итәргә кирәк.

Көтепханәдә янгын сүндерү өчен кирәкле җиһазлар: янгын сүндергеч, чиләк яки сулы кисмәк, ящикларга һәм кечкенә капчыкларга тутырылган ком, көрәк һ. б. булырга тиеш.

Хәзергә кадәр тулаем көтепханә фондын саклау турында сөйләнде. Һәр китапның вакытыннан элек тузуына каршы да чаралар күрергә кирәк. Көтепханә китабы, кагыйдә буларак, төпләнгән булырга тиеш. Әгәр дә ул типографиядә төпләнеп чыгарылмаган булса, аны мастерскойга биреп төпләтергә кирәк. Беренче чиратта иң кыйммәтле һәм күп укыла торган китаплар төпләтелә. Укучылар китапны кайтарып биргәндә аны карап алырга кирәк. Әгәр ничек тә зарарланган булса, китапны ремонт ясау өчен аерып куярга кирәк. Укучылар активы ярдәмендә вак ремонт эшләрен: ертылган битләрне ябыштыру, тапларны бетерү, укучылар язган язуларны һәм ясаган рәсемнәрне бетерү эшләрен оештырырга кирәк. Битләре ертылган, язгалап бетергән, пычранган китапларны укырга бирергә ярамый.

Брошюралар мөмкин кадәр каты кәгазьдән эшләнгән папкалар яки тышлыклар белән тәэмин ителәләр. Брошюраның кирәге беткәч, аның папкасын яки тышлыгын бүтән брошюралар өчен файдаланырга мөмкин.

---

## VII БҮЛЕК

## АБОНЕМЕНТТА ҺӘМ УКУ ЗАЛЫНДА ЭШЛӘҮ

### § 1. УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ, АНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ

Үткән бүлекләрдә сөйләнгәннәрнең бөтенесе — китапханәне оештыру, аның фондын комплектлау, китап байлыгын учетка алу, китапларны классификацияләү һәм каталогка салу, аларны китапханәчә рәсмиләштерү һәм киштәләргә тезеп кую — менә шулар бөтенесе дә китапханәнең иң әһәмиятле эшен үтәүгә, укучыларның культура сорауларын канәгатьләндерүгә хәзерлек кенә. Китапханәнең барлык организацион-техник эше укучыларга китаплар һәм бүтән төрле матбугат әсәрләре белән мөмкин кадәр тулырак һәм киңрәк хезмәт күрсәтү бурычларына буйсындырылырга тиеш. Укучыларга хезмәт күрсәтү һич тә китапларны механик рәвештә бирүдә түгел. Бу — җанлы эчтәлек белән тулы эш, укучының культура-политик дәрәҗәсен һәм производство квалификациясен күтәрү максатын нигез итеп алган агитация-пропаганда эше. Китапханә Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен пропагандаларга, укучыларны большевиклар партиясе тарихы белән таныштырырга, без кичерә торган тарихи чорның бурычларын һәм үзенчәлекләрен аңлауда аларга ярдәм итәргә тиеш.

Китапханә укучыларны совет патриотизмы рухында тәрбияләргә, тарихи-фәнни һәм тарихи-матур әдәбият ярдәмендә укучыларга СССР ның үткәндәге героик тарихын, безнең бөек бабаларыбызның образларын, рус культурасының әһәмиятен һәм мәһабәтлеген, аның гүзәл вәкилләренең тормышын һәм казанышларын күрсәтергә тиеш. Китапханә укучыларны агымдагы поли-

тика мәсьәләләре белән таныштырып торырга, бик әһәмиятле вакыйгалар турында аларга информация ясап барырга, укучыларга партия һәм хөкүмәт карарларын аңлатырга тиешләр.

Көтепханә, табигать күренешләрен материалистик нигездә аңлату өчен, фән, техника һәм культура казанышларын төшендерү өчен китаплардан, брошюралардан, журнал мәкаләләреннән файдаланып, фәнни-агарту пропагандасы алып барырга тиеш.

Көтепханә укучыларга үзләренә кирәкле белемнәрне гомуми, хәрби, техник, авыл хуҗалыгы белемнәрен алуда ярдәм итәргә тиеш. Массовый көтепханәдә укучылар белән эшләүнең эчтәлеге гомумән менә шундый.

Бу эшләрне үткәргәндә укучының индивидуаль үзенчәлекләре белән — аның яше, гомуми һәм махсус хәзерлеге, аның интереслары һәм сораулары белән хисаплашырга кирәк. Укучыларга дифференциация ясап якын килергә, төрле укучыларга төрлечә хезмәт күрсәтергә кирәк. Бер үк төрле мәсьәлә буенча көтепханә эшчесе төрле укучыларга төрле китаплар тәкъдим итә, укучылар белән сөйләшкәндә аларның хәзерлек дәрәҗәләренә карап сүз алып бара.

Укучылар группасы белән яки аерым укучылар белән эшләүнең бурычларын билгеләү өчен, аларга якын килә белү, аларның интересларын төшенә белү, аларга үзләре өчен кызыклы һәм файдалы булырлык китапларны бирә белү өчен, көтепханә эшчесе укучыларны өйрәнергә тиеш. Көтепханә эшчесенең халык белән турыдан-туры бәйләнештә булуы, районның, авылның колхозның җәмәгать тормышында катнашуы укучыларны өйрәнүдә төп метод булып тора. Районның үзенчәлекләрен, җирле халыкның ихтыяҗларын һәм бурычларын өйрәнү өчен өлкә һәм район матбугаты күп материал бирә. Ниһаять, укучы белән эшләү процессында абонементта китаплар биргәндә, массовый чаралар үткәргәндә — көтепханә эшчесе даими рәвештә укучыларны өйрәнә, укучы үзенең совет гражданы һәм патриоты сыйфатындагы бурычын мөмкин кадәр яхшырак үти алсын өчен, аңа нинди китап тәкъдим итү турында уйлый.

Көтепханәнең статистик отчетын өйрәнеп, көтепханә эшчесе нинди әдәбиятның күбрәк кулларга бирелүен, укучылар тарафыннан күбрәк соралуын белеп ала. Укучы формулярын карап тикшереп, көтепханә

эшчесе шушы укучы тарафыннан нинди китапларның укылганлыгын һәм киләчәктә аңа нинди китаплар укырга тәкъдим итәргә кирәк икәнен күрә.

Көтепханә эшчесе укучыларның аерым группаларының сорауларын өйрәнергә тырыша. Хәзер промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының яңа кадрларының — производствога күптән түгел генә килгән яшьләрнең һәм хатын-кызларның интересларын өйрәнү аеруча мөһим. Укучыларның Ватан сугышы инвалидлары кебек төркеме аеруча игътибар бирүне таләп итә. Көтепханә бу укучыларга культура даирәсен киңәйтүдә дә, яңа профессияләр үзләштерүдә дә ярдәм итәргә тиеш.

Район һәм авыл көтепханәләре авыл укытучыларына әдәбият белән хезмәт күрсәтү эшен оештырырга тиешләр, моның өчен башта аларның сорауларын өйрәнү кирәк.

Шулай итеп көтепханәнең укучылар белән алып бара торган бөтен эше аларны өйрәнү һәм аларга аерым-аерым якын килү нигезенә корыла.

Укучы белән эшләү төрле формаларда — абонементта һәм уку залында китап бирү төсендә, укучыларга белешмә-библиография хезмәте күрсәтү төсендә, китапларны, газеталарны һәм бүтән төрле матбугат әсәрләрен пропагандалау төсендә гәүдәләнә. Башта абонементта һәм уку залында эшләүне тикшереп үтик.

## § 2. КӨТЕПХАНӘ ЭШЧЕСЕНЕҢ КИТАПЛАР БИРҮГӘ ХӘЗЕРЛӘНҮЕ

Н. К. Крупская абонементта эшләүнең әһәмиятен болай дип билгеләде: „Көтепханә эшендә төп нәрсә — абонементта эшләү. Укучының сорауларын оста итеп канәгатьләндерү, аның политик һәм культура ягыннан үсешенә һәм аның эш квалификациясен күтәрүгә булышлык итү — җаваплы эш ул“ („Красный библиотекарь“ журналы, 1939 ел, № 3, 71 бит).

Укучы белән сөйләшкәндә көтепханә эшчесе аңа китап сайлауда, укылган материалны үзләштерүдә, китап өстендә мөстәкыйль эшләү күнекмәләре алуда булышлык итә, кыскасы, уку белән индивидуаль җитәкчелек итүне тормышка ашыра.

Укучыларга китап бирү кебек бик әһәмиятле һәм җаваплы моментка көтепханә эшчесе көн саен хәзерләнергә тиеш. Бу хәзерлек нәрсәдән гыйбарәт соң?

Көтепханә эшчесе иң элек газеталарны карап чыга, җитәкче газеталарның — „Правда“, „Известия“, „Комсомольская правда“ газеталарының баш мәкаләләре белән таныша, аларның тематикасыннан чыгып укучыларга тәкъдим итәр өчен тиешле әдәбиятны сайлый.

Аннары көтепханә эшчесе күптән түгел генә алынган китапларны карый, аларның эчтәлеге белән таныша, теге яки бу китапны нинди укучыга тәкъдим итәргә кирәклек мәсьәләсен хәл итә.

Әгәр дә берәр журналның яңа номеры килсә, көтепханә эшчесе бик мөһим мәкаләләрне карап яки укып чыга, тәнкыйть һәм библиография бүлегенә аеруча игътибар бирә.

Әгәр дә үткәндәге китап бирү вакытыннан кайбер китаплар киштәләргә куелмый калган булса, көтепханә эшчесе аларны киштәләргә тезеп куя, шуның белән бергә китапларның укучыларга актив рәвештә тәкъдим ителергә тиешлеләрен китап бирү өстәлендә калдыра. Көтепханә эшчесе ярдәмче ящикларга куярга билгеләнгән китапларны тәртипкә сала, бер уңайдан аларга яңаларын өсти һәм искергән брошюралардан арындыра.

Көтепханә эшчесе шулай ук китап күргәзмәләрен карап чыга, аларга яңа китаплар өсти.

Газеталарны, журналларны, китапларны карап чыккач, китапларны пропагандалау буенча абонементта булган барлык средстволарны тәртипкә китергәч, көтепханә эшчесе укучыларны характерлый торган материалларга мөрәҗәгать итә: укучыларның сораулары дәфтәрен карый, көтепханәләр арасындагы абонемент буенча заказ бирергә кирәкле кайбер китапларны язып ала, элекке көнне аерым укучылар турында язылган язуларны карый.

## § 3. КӨТЕПХАНӘГӘ ЯҢА УКУЧЫЛАР ЯЗУ

Көтепханә эшчесенең укучы белән беренче очрашуының зур әһәмияте бар. Көтепханә эшчесенең коры һәм рәсми булуының укучыны көтепханәдән биздерүе мөмкин һәм, киресенчә, укучы белән җанлы һәм кызыклы итеп сөйләшү, китапларны уңышлы сайлап бирү укучыны көтепханәгә тартачак, аның укырга теләген арттырачак.

Яңа укучы кабул итү аның формулярын тутырудан башлана. Көтепханә эшчесе формулярның йөз ягына

укучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, өй һәм хезмәт адресын, паспорт номерын, партиялелеген һәм милләтен язып ала. Формулярның түбәнге өлешендә укучының җенесен, яшен, социаль хәлен һәм белемен характерлый торган мәгълүматларны ала. Шушы мәгълүматлар билгеле дәрәҗәдә көтепханә эшчесенә укучы белән алып барырга кирәкле эшнең гомуми характерын һәм юнәлешен күрсәтәләр. Мәсәлән, профессиясе буенча фрезеровщик, тәмам ителмәгән урта белемле яшь кеше һәм медицина вузында укучы студент — шушы ике яшь кеше көтепханә эшчесеннән китап сорыйлар. Көтепханә эшчесеннән боларның һәрберсенә аерым карау, әдәбиятны аерым рәвештә сайлау таләп итеlә. Ләкин һәрбер укучыга бары тик аның белгечлеге күзлегеннән генә карарга һәм әдәбиятны шушы билгегә карап кына тәкъдим итәргә ярамый. Укучыны социалистик Ватанның гражданины һәм патриоты сыйфатында политик тәрбияләүнең гомуми бурычларын да, укучының гомуми культура ихтыяҗларын да, аның укуының индивидуаль мотивларын да исәпкә алырга кирәк. Укучыны көтепханәгә нәрсә китергән, ул аңардан нәрсәләр алырга тели, китаплардан ул нәрсәләр эзли, элек ул нәрсәләр укыган, нинди мәсьәләләр белән кызыксына, газеталар укыймы һәм нинди газеталар укый, аңа нинди китаплар ошаган яки башкалардан бигрәк нинди китаплар ошый, нинди китапларга ул мохтаҗлык сизә,— көтепханә эшчесе өчен менә шуларның бөтенесен белү бик әһәмиятле. Шуңа күрә, укучы турындагы рәсми белешмәләр белән чикләнмәстән, көтепханә эшчесе аның белән аның интереслары турында, аның элек укыган китаплары турында, нинди авторларны һәм китапларны яратуы һ. б. турында сөйләшә. Ләкин, әгәр дә укучы көтепханә эшчесенең сорауларына теләр-теләмәс кенә җавап бирсә, тикшеренүне аның көтепханәгә икенче тапкыр килүенә кадәр кичектерергә кирәк. Укучыны көтепханәдән файдалану кагыйдәләре белән танышуга күчәргә, аңа көтепханә китаплары белән культуралы һәм сак мөгамәлә итәргә кирәклек турында әйтергә, кыскача гына итеп көтепханә фондын характерлап бирергә, көтепхананең эше турында сөйләргә, укучыга каталогларны, папкаларны, альбомнарны һәм башка төрле ярдәмче материалларны күрсәтергә кирәк.

## Кө̄тепханә укучысы формуляры (зурлар өчен)

а) Йөз ягы

№ 838
Фамилиясе *Евсеева*
Исеме, атасының
исеме *Лидия Андреевна*
Милләте *рус*
Партиялелеге *ВКП(б) кандидаты*

| | Яше | | |
|---|---|---|---|
| Ир. | | | |
| Хатын | 16 га кад. | 16—23 я | 23тән югары |

Эшче ______ | Укучы
______
Колхозчы ______ | Югары мәктәптә
Хезмәткәр ______
Башкалар ______ | Урта мәктәптә

Белеме

Башлангыч | УМ һәм ТБУМ | Югары

Өй адресы: *Парковая, 5 квар. 68*
Хезмәт адресы: *Штабная, корпус 1а, Коопремонт*
Телефон №______
Паспорт *№ IV КР № 328687*

Кө̄тепханә кагыйдәләрен беләм һәм үтәргә сүз бирәм,

19 4/V 45 ел (имза) *Евсеева*

б) Эчке ягы

| Китапны кайтару срогы | Инв. № | Бүлек | Автор һәм китапның исеме | Китап алу турында укучының имзасы | Китапны кайтарып алу турында кө̄тепханә эшчесе имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 14.IV | 3897 | 3 | Ярославский. Партия нәрсә таләп итә | Евсеева | Артемов |
| 14.IV | 4178 | | Симонов. Көннәр һәм төннәр | Евсеева | Артемов |
| 22.IV | 6878 | | Степанов Порт-Артур | Евсеева | |
| | 2113 | 3 | ВКП(б) программасы һәм уставы | Евсеева | Артемов |
| | 3567 | 3 | ВКП(б) тарихы. Кыс. курс | Евсеева | |
| 30.IV | 123 | 3 | Ленин. Нәрсә эшләргә? | Евсеева | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

## § 4. УКУЧЫЛАРГА КИТАПЛАР САЙЛАУ ҺӘМ ТӘКЪДИМ ИТҮ

Укучы белән бераз танышкач, аның өчен китаплар сайлауга күчәбез. Көтепханә эшчесе алдына: бу укучыга нинди китап тәкъдим итәргә? дигән сорау килеп баса.

Кайчакта укучылар үзләре бу бурычны җиңеләйтәләр һәм үзләре билгеле бер китапны сорыйлар. Ул вакытта көтепханә эшчесенең роле укучының шушы таләбен канәгатьләндерүгә кайтып кала. Ләкин укучыларның соравы һәрвакытта да ачык булып бетми. Кайвакытларда укучылар әсәрләрнең исемнәрен ялгыш әйтәләр, бер авторның әсәрен икенче авторныкы итеп күрсәтәләр. Көтепханә эшчесе укучының ялгышын төзәтергә яки аның соравын ачыкландырырга тиеш.

Мәсәлән, укучы „Кавказ әсире“ дигән китапны сорый. Пушкинның да, Лермонтовның да, Лев Толстойның да мондый әсәре бар. Көтепханә эшчесенә укучының нәкь менә кем әсәрен сораганлыгын белеп алырга туры килә.

Кайвакытларда укучыга китапның нинди практик максатлар өчен кирәклеген билгеләргә кирәк була, мәсәлән, укучы гомумән тракторлар турында китап сорый, ә аңа тракторның электр җиһазларына ремонт ясау турындагы китап кирәк була.

Сораган китапны икенче китап белән алыштыруны бик оста рәвештә һәм укучы сораган китапның аңа һич тә ярамаганлыгы бик ачык булганда гына эшләргә кирәк.

Сораган китаплар шушы моментта кулда, бүтән укучыларда булган яки көтепханәдә гомумән булмаган хәлләрдә башка китаплар белән алыштырырга туры килә.

Укучы сораган китап урынына бирелә торган китап тематикасы буенча соралган китапка ошашлы булырга һәм чама белән шул сораган китап тибында ук булырга тиеш (фәнни-популяр китап яки укыту ярдәмлеге, тарихи роман яки фаҗигаләр романы һ. б.).

Мәсәлән, укучы Н. А. Островскийның „Корыч ничек чыныкты“ исемле китабын сораса һәм ул китап көтепханәдә булмаса, ул чагында шул ук авторның тематикасы һәм төп идеясе буенча якынрак торган икенче әсәрен, атап әйткәндә „Давылда туганнар“ын тәкъдим итәргә була. Кайбер хәлләрдә бер язучының, мә-

сәлән, Диккенсның яки Вальтер Скоттның, бер әсәрен шул ук авторның икенче әсәрләре белән алыштырырга мөмкин. Ләкин күп кенә хәлләрдә алыштыру мөмкин булмый. Укучыга билгеле бер китап кирәк була, ләкин нинди дә булса бүтән китап түгел. Андый вакытларда район яки авыл көтепханәсе соралган китапны көтепханәләр арасындагы абонемент буенча өлкә көтепханәсеннән соратып ала.

Кайчакта укучының соравын әсәрнең басмаларын алыштыру юлы белән канәгатьләндерергә, ягъни аңа сораган әсәрнең аерым басмасын түгел, бәлки берәр томга, җыентыкка, журналга һ. б. кергән басмасын бирергә мөмкин була. Мәсәлән, көтепханәдә В. И. Ленинның „Ярышны ничек оештырырга" дигән мәкаләсенең аерым басмасы булмаганда, көтепханә эшчесе укучыга В. И. Ленинның ике томлык „Сайланма әсәрләре"нең икенче томын яки В. И. Ленин „Әсәрләр"енең өченче басмасының XXII томын бирә.

Көтепханәдә Б. Горбатовның „Буйсынмас кешеләр" дигән әсәре булмаса, „Октябрь" журналының 1943 елда чыккан 4—5 һәм 8—9 номерларын бирергә була. Көтепханәдә агымдагы политика мәсьәләләре буенча берәр брошюра булмаганда „Большевик", „Пропагандист" журналларында шул ук темага язылган мәкаләне эзләп табарга була. Әгәр дә укучыга СССР тарихының берәр чоры турында китап кирәк булса, ә көтепханәдә андый китап булмаса, СССР тарихыннан урта яки югары мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслек китабын бирергә була.

Гомумән алганда билгеле бер китапны сораганда укучыларның соравын мөмкин кадәр кире какмаска, аны канәгатьләндерү өчен көтепхәнәнең барлык ресурсларыннан—китапларыннан, журналларыннан, газеталарыннан файдаланырга, булмаган китапларны ошашлы китаплар белән алыштыру һәм көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу чарасын күрергә кирәк.

Күп вакыт укучылар көтепханә эшчесеннән аның „берәр китап бирүен", „кызыклырак китап сайлавын" үтенәләр. Мондый хәлдә укучыны нәкъ менә нәрсә кызыксындыруын белеп алырга кирәк.

Укучыга сайлар өчен күп кенә темалар тәкъдим итәргә мөмкин, мәсәлән, Бөек Ватан сугышы турында, гражданнар сугышы турында, партия тарихы буенча,

СССР тарихы буенча, авыл хуҗалыгы буенча, яки, укучының белгечлегенә туры китереп, нинди дә булса техника тармагы буенча. Формулярда булган мәгълүматка карап көтепханә эшчесе укучының профессиясен һәм аның гомуми хәзерлеген төшенеп ала, аның нинди китаплар укыганлыгын күрә. Көтепханә эшчесе шушы китаплар турында укучы белән сөйләшә, аңа китап бирү өстәле өстенә таратып куелган күп кенә китапларны яки ярдәмче ящикларда җыйналган брошюраларны карап чыгарга тәкъдим итә. Кайвакытларда сорауның ачык булмавы укучының агымдагы әдәбиятны белмәвеннән, соңгы вакытларда нинди китаплар чыкканын искәрмәвеннән килә. Мондый укучыны көтепханәдә булган китап күргәзмәләре һәм библиографик материаллар белән таныштырырга кирәк—тәкъдим ителә торган китаплар исемлекләре, рецензия альбомнары һ. б. белән таныштырырга кирәк.

Укучыга һәрбер китап биргән вакытта көтепханә эшчесе аның белән китаплар турында сөйләшергә, китаплар тәкъдим итәргә, кыска гына итеп китаплар белән таныштырырга тиеш. Китап биргәндә әлбәттә китаплар турында беседа алып барырга кирәк. Мондый беседаны үткәрү өчен көтепханә эшчесеннән иң элек китапларны белү таләп ителә.

Көтепханә эшчесе китап турында укучыга нәрсәләр сөйли ала соң?

Иң элек укучыны әсәрнең төп идеясе һәм темасы белән таныштыра ала. Мәсәлән, Ю. Тыняновның „Кюхля“ дигән әсәрен биргәндә бу әсәрнең Пушкинның якын дусты декабрист Кюхельбекер турындагы тарихи роман икәнлеген, романда Пушкинның лицейда уку еллары, 1825 елгы декабристлар восстаниесе тирән тасвир ителгәнлеген аңлатып бирергә мөмкин.

П. Бажовның „Малахитовая шкатулка“ исемле әсәрен биргәндә бу китапта Урал турында художестволы итеп эшләнгән халык хикәяләре җыелганлыгын, китапта әкиятләрдән алынган элементларның күп булуын һәм шуның белән бергә Уралдагы тау эшчеләренең крепостное право вакытындагы тормышы яхшы тасвир ителгәнен әйтеп бирергә мөмкин. Китапның эчтәлеген бик кыска гына итеп бирергә кирәк, киң итеп сөйләп биргәндә укучының китап белән кызыксынуын киметү мөмкин. Әгәр дә автор укучыга җитәрлек дәрәҗәдә билгеле булса, бик кыска гына аңлату белән чикләнергә

була. Әгәр дә автор укучыга билгеле булмаса, ул чагында язучының биографиясеннән аның иҗатын төшенергә ярдәм итәрдәй кайбер фактларны әйтергә кирәк. Мәсәлән, С. П. Бородинның „Дмитрий Донской“, В. Янның „Чингиз Хан“, И. Эренбургның „Парижның егылуы“, Сергеев-Ценскийнын „Севастополь оборонасы“, Л. Соболевның „Диңгез җаны“, Ванда Василевскаяның „Салават күпере“, А. Н. Толстойның „Газапта йөрү“, П. Бажовның „Малахитовая шкатулка“ исемле әсәрләрен биргәндә бу әсәрләрнең Сталин премиясе алуга ирешүләрен әйтеп үтәргә кирәк.

Классик фәнни әсәрләрне биргәндә без аларның фән тарихында тоткан урыннарын әйтеп үтәбез; фәнни-популяр китапларны биргәндә без укучыларның игътибарын бу китапта фәнни теорияләрнең җанлы итеп бирелүенә, фән тарихына бәйләнешле мәгълүматларның кызыклы итеп бирелүенә юнәлдерәбез.

Ышанычлы булсын өчен көтепханә эшчесе китапның аерым урыннарын укый, рәсемнәрен күрсәтә. Мәсәлән, А. Юговның „К. А. Тимирязев“ исемле китабын тәкъдим иткәндә, Тимирязевнең атаклы рус галиме-революционер булганлыгын кыскача гына әйтеп бирергә һәм әсәрнең „Страшное пророчество“ дигән бүлегенең башын укып чыгып, А. Югов китабының бик җанлы итеп язылганлыгын күрсәтергә мөмкин.

### § 5. УКУЧЫДАН КИТАПЛАРНЫ КАБУЛ ИТЕП АЛУ. КИТАПЛАРНЫ КАЙТАРЫП АЛГАНДА КӨТЕПХАНӘ ЭШЧЕСЕНЕҢ УКУЧЫ БЕЛӘН БЕСЕДАСЫ

Укылган китапны кайтарып тапшырганда кайбер укучылар китаптан алган тәэсир турында көтепханә эшчесе белән үзләре үк уртаклаша торган булалар. Укучының китап турындагы фикерләре көтепханә эшчесенә укучыны өйрәнүдә дә, шулай ук китапны өйрәнүдә дә ярдәм итә. Ләкин укучыларның барысы да укыган китапка карашларын әйтеп бирмиләр, кайберәүләр үзләренең китап турындагы фикерләрен әйтеп бирергә кыенсыналар яки оялалар. Мондый укучылар белән көтепханә эшчесе үзе китап турында сөйләшергә, укучының китапны аңлаганлыгын, китапның аңа ошаганлыгын белеп алырга тырыша. Укучы өчен киләчәктә нинди әдәбият сайлау эше шушы сорауларны хәл итүгә бәйләнгән була.

Әгәр дә китап укучыга ошаса, үзенең тематикасы белән аны кызыктырса, ул чагында аңа шундый тематикадан берничә китап тәкъдим итәргә була. Мәсәлән, укучыга Фурмановның „Чапаев“ дигән әсәре ошаган, укучыны гражданнар сугышы героикасы кызыксындырган. Мондый укучыга Н. Островскийның „Корыч ничек чыныкты“сын, А. Н. Толстойның „Икмәк“ дигән әсәрен, Фадеевның „Тар-мар“ын, Серафимовичның „Тимер ташкын“ын, Первенцевның „Кочубей“ен, Вс. Ивановның „Пархоменко“сын тәкъдим итәргә мөмкин.

Әгәр дә укучы гражданнар сугышы чоры белән тагын да тирәнрәк танышырга теләсә, аңа „ВКП(б) тарихы. Кыскача курс“ның VIII бүлеген, Ленин һәм Сталинның гражданнар сугышы һәм чит илләр интервенциясе чорына караган әсәрләрен, „Гражданнар сугышы тарихы“н тәкъдим итәргә мөмкин.

Укучыга китап ошамаган хәлләрдә аңа китапның ошамавының сәбәпләрен белергә тырышырга кирәк: ихтимал, укучыга китапның тематикасы кызыктырырлык түгелдер, ул башка мәсьәләләр буенча китаплар укырга тели торгандыр; ихтимал, мәсьәлә үзе укучыны кызыктырып та аңа аңлаешлы түгелдер яки мәсьәләнең бу китаптагы язылышы кызыклы түгелдер. Мәсәлән, укучы А. Г. Лорхның „Бәрәңгедән югары һәм ныклы уңыш алу юллары“ дигән китабын кайтара һәм бу китапның аңа аз нәрсә биргәнлеген әйтә. Статистик таблицалар һәм диаграммалар белән тулган бу китап укучы өчен авыр, артык теоретик китап икән. Укучыга гадирәк, практик ярдәмлек кирәк икән. Моны белеп алгач, көтепханә эшчесе укучыга академик Т. Д. Лысенконың „Индивидуаль һәм коллектив бакчаларда уңышны күтәрергә“ дигән брошюрасын (М. Тимер юл транспорты издательствосы. 1943) яки „Бәрәңгедән ничек итеп югары уңыш алырга“ (төзүчесе А. И. Тамман. М. Авыл хуҗ. изд. 1942) дигән брошюраны бирә.

Укучы китапның эчтәлеген гомумән үзләштереп тә, аның кайбер урыннары аңлашылмый калган булса, көтепханә эшчесе, белешмәләрдән, сүзлекләрдән һәм бүтән төрле ярдәмлекләрдән файдаланып, аларны укучыга аңлатып бирергә тырыша. Әгәр дә укучы аңламаган нәрсәне көтепханә эшчесе үзе аңлатып бирә алмаса, укучыны белгеч консультантка—агрономга, укытучыга һ. б. мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итәргә кирәк.

Кайбер укучылар, көтепханә эшчесенең үтенүе буенча, китаплар турында үзләренең фикерләрен язып бирәләр. Укучыларның шундый фикерләрен җыеп, көтепханә эшчеҫе аларны альбом яки плакат төсендә формалаштыра. Шундый альбом һәм плакатлар китапларны көтепханәнең укучылар арасында пропагандалавының иң ышанычлы средствосы булып хезмәт итәләр. Китаплар турында укучылар биргән фикерләрнең бик кызыклыларын издательстволарга яки авторларга җибәрергә була.

## § 6. АБОНЕМЕНТТА ЭШЛӘҮ ТЕХНИКАСЫ

Абонементта эшләү техникасы түбәндәгечә:

1) Укучыга бирелгән китапларны язу;

2) укучы һәм китап формулярларын тезеп кую;

3) бирелгән китапларны санап йомгак ясау һәм бу йомгакларны көтепханәнең статистик көндәлегенә язып кую.

Укучыга китаплар бирүне формалаштыра торган төп документ—укучы формуляры. Формулярның беренче битенә укучы турындагы мәгълүматлар языла, аннан соңгы битләрендә—укучыга бирелгән китаплар языла (95 нче битне кара.)

Формулярга укучының тәртип номеры куела. Бу номер яңадан (ел саен 1 нче январьдан башлана торган) теркәүгә кадәр укучы номеры булып исәпләнә.

Әгәр дә укучы көтепханәдән китсә, аның номеры чираттагы яңадан теркәүгә кадәр беркемгә дә бирелми.

Укучыга өйгә бирелгән китаплар формулярның 2, 3, 4 нче битләренә язылалар, шуның белән бергә анда кайтару срогы, инвентарь номеры, бүлек, автор һәм китапның исеме күрсәтелә.

Укучы һәр китапны алганлыкка кул куя. Китапны кайтарып алганда көтепханә эшчесе дә укучыдан китапны алганлыкка кул куя. Укучы онытырлык булмасын өчен, китапны кайтару срогы „сроклар кәгазе“нә язып бирелә. Әгәр дә укучыларның формулярлары аларның номерлары тәртибендә тезелеп куела икән, ул чагында „сроклар кәгазе“нә укучының номеры да язып куела.

Китапны биргәндә аның формуляры китап кесәсеннән алынып, укучы формуляры эченә салып куела. Китап формулярлары укучы формулярыннан төшеп ка-

## Көтепханә көндәлеге (зурлар өчен)

### а) укучыларны һәм аларның йөрүләрен исәпкә алу

| | Число һәм ай | Барлык укучылар | Шул исәптән | | | | | | | | | | | | | | | | Бер көндә күпме кеше килде |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Мәктәптә укучылар | | | Яшьләре буенча | | | Җенес буенча | | Милләтләр буенча | | | | | |
| | | | Эшчеләр | Колхозчылар | Хезмәткәрләр | Югары мәктәптә | Урта мәктәптә | Башкалар | 16 га кадәр | 16—23 яшь | 23 тән югары | Ирләр | Хатын-кызлар | Руслар | Татарлар | Башкалар | | | |
| Ай башына күпме кеше иде . . . . . . . | 1 | 828 | 256 | 44 | 321 | 88 | 40 | 79 | 18 | 411 | 399 | 327 | 501 | 686 | 137 | 5 | — | — | — |
| Язылдылар . . . . . | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Ял көннәре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | 2 | 14 | 4 | — | 3 | 3 | 2 | 2 | — | 9 | 5 | 8 | 6 | 13 | 1 | — | — | — | 16 |
| | 3 | 16 | 6 | — | 6 | 2 | 1 | 1 | 1 | 7 | 8 | 7 | 9 | 16 | — | — | — | — | 132 |
| | 4 | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | 5 | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 31 нче числога кадәр | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы бер ай эчендә язылды . . . . . . | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бер айда киттеләр . . | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Ай ахырына булды . | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Искәрмә: „Милләтләре буенча бүленеше“ дигән графада бу өлкәдә күпчелек тәшкил иткән милләтләр исәпкә алына.

### Көтепханә көндәлеге (зурлар өчен)

б) бирелгән китапларны, брошюра һәм журналларны исәпкә алу

| Ай числосы | Бирелгән китап, брошюра һәм журналларның саны (барлык данәсе) | Бирелгән китап, брошюра һәм журналларның эчтәлекләре буенча бүленеше: Иҗтимагый-политик. әдәб. (1, 2, 3 һәм 9): Барлыгы | Иҗтимагый-политик. әдәб.: Шул исәптән Маркс, Энгельс, Лен н, Сталин китаплары | Иҗтимагый-политик. әдәб.: Шул исәптән хәрби әдәбият (355—359) | Табигать гыйлеме һәм математика (5) | Техника (6 бүлек, 61 һәм 63 тән башка) | Авыл хуҗалыгы (63) | Матур әдәбият | Балалар әдәбияты | Башка әдәбият (0, 4, 61, 7, 8, 91 һәм 92) | Шул исәптән бирелгән: Сталин Бөек Ватан сугышы турында | Шул исәптән бирелгән: Рус телендә | Шул исәптән бирелгән: Татар телендә | Шул исәптән бирелгән: Башка телләрдә | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | Ял көне |
| 2 | | | | | | | | | | | | | | | Ял көне |
| 3 | 180 | 36 | 18 | 4 | 18 | 7 | 6 | 90 | 14 | 9 | 12 | — | — | 4 | |
| 4 | 212 | 48 | 20 | 9 | 20 | 12 | 4 | 105 | 11 | 12 | 10 | — | — | — | |
| 5 | 240 | 39 | 14 | 6 | 12 | 16 | 16 | 124 | 18 | 16 | 18 | — | — | 2 | |
| 7 | | | | | | | | | | | | | | | |
| 31 нче числога кадәр | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы бер айда | | | | | | | | | | | | | | | |

лырлык булмасын өчен, бу формулярга кесә ябыштыралар.

Китап формулярына китапны кайтару срогы һәм укучының номеры языла. Укучының вакытын алмас өчен, китап формулярларына языла торган язуларны китапларны биргәннән соң язалар.

Укучы формулярлары үзләренең эченә салынган китап формулярлары белән бергә китапларны кайтару сроклары буенча тезеп куелалар, ә һәрбер срок эчендә—укучылар фамилияләренең алфавиты тәртибендә яки аларның номерлары тәртибендә тезелеп куелалар.

Китап бирү беткәч һәм аларны язып формалаштыргач, көтепханә эшчесе абонементның көнлек эшенә йомгак ясый һәм ул йомгакны „көтепханә көндәлеге"нә язып куя.

Яңадан язылган укучылар саны көн саен исәпләнә бара. Көтепханәдән киткән укучылар саны айга бер тапкыр исәпләнә. Көтепханәдән файдалануларын туктату турында белдергән укучылар һәм бер квартал буена көтепханәдә бер генә тапкыр да булмаган һәм китап алыштырмаган укучылар көтепханәдән киткән булып исәпләнәләр. Көтепханәдән бер кат китеп, берникадәр вакыттан соң яңадан аңардан файдалана башлаган кешеләр, яңа килгән кешеләр булып исәпкә алыналар.

Декабрь аеның йомгак саннары яңа елның 1 нче январена укучыларның санын һәм составын күрсәтә һәм көтепханәнең еллык отчетына күчерелә. 1 нче январьдан алып укучыларны яңадан теркәү башлана.

Укучының көтепханәгә китап алыштыру яки китап уку өчен (уку залына) һәрбер килүе „Бер көн эчендә килүчеләр саны" графасына языла.

## § 7. БИРЕЛГӘН КИТАП, БРОШЮРА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРНЫ ИСӘПКӘ АЛУ

Көтепханәнең ничаклы тырышып эшләве һәм аның фонды ни дәрәҗәдә файдаланылу турында укучыларга бирелгән китаплар санына карап хөкем итәргә мөмкин.

Китаплар бирү көн саен исәпкә алып барыла, нәтиҗәләр көтепханә көндәлегенең икенче битенә языла (102—103 нче битләрне кара).

Ай азагында китап, журнал һәм брошюралар бирүгә йомгак ясала. Йомгаклар битнең соңгы юлына языла.

Брошюраларны теркәү дәфтәрләренә язылган брошюралар инвентарь кенәгәсенә кергән әсәрләр белән бер дәрәҗәдә барлык графалар буенча исәпкә алыналар.

Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча алынган һәм бирелгән китап һәм журналларның санын „искәрмә“ графасында күрсәтергә мөмкин, шуның белән бергә бу китапларны алуны һәм бирүне аерым-аерым язарга кирәк.

Бирелгән китапларның бүлекләр буенча бүленеше көтепханә эшенең эчтәлеген характерлый. Әгәр дә көтепханәдә агитация-масса эше яхшы куелган булса, бу иҗтимагый-политик әдәбиятның күп санда бирелүендә күренә. Киресенчә, әгәр дә көтепханә тарафыннан иҗтимагый-политик әдәбият аз бирелгән булса, бу көтепханәдә агитация-масса эшләренең яисә бөтенләй алып барылмавын, яисә абонементта эшләү белән бәйләнмәгән булуын күрсәтә. Әгәр дә бирелгән китапларның зур күпчелеге беллетристикага туры килсә, ул чагында, ихтыярсыз рәвештә, көтепханә фәнни әдәбиятны пропагандалау белән шөгыльләнми икән дигән нәтиҗәне чыгарырга туры килә.

Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен бирү турындагы мәгълүматлар бик мөһим. Бу мәгълүматларга карап көтепханәнең марксизм-ленинизм әдәбияты белән эшләве турында хөкем йөртергә мөмкин. Фәнни-агарту пропагандасы бурычлары уңае белән табигать фәне әдәбиятының бирелүен күрсәткән саннар аеруча әһәмият ала.

Бирелгән китапларны исәпкә алу нәтиҗәләре көтепханә мөдире тарафыннан өйрәнелергә, көтепханә эшчеләренең укучылар белән берлектә үткәрелгән производство киңәшмәләрендә тикшерелергә һәм эш планын төзегәндә игътибарга алынырга тиешләр.

## § 8. АБОНЕМЕНТНЫ ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ҖИҺАЗЛАУ

Абонемент—өйгә әдәбият бирү урыны гына түгел, бәлки китапларны массовый төстә пропагандалау урыны да.

Абонемент бинасын чиста һәм тәртипле тоту турында, аңа культуралы төс бирү турында, абонементны тиешле рәвештә формалаштыру һәм җиһазлау турында кайгыртырга кирәк.

Абонемент бинасын партия һәм хөкүмәт житәкчеләренең, бөек язучыларның һәм галимнәрнең портретлары белән, политик лозунглар белән, хәрби-оборона һәм авыл хуҗалыгы плакатлары белән матурларга кирәк. Аннары, абонемент бинасында махсус көтепханә лозунглары—уку турында, китапларның әһәмияте һ. б. ш. лар турында лозунглар, тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре, көтепханә плакатлары, китаплардан файдалану кагыйдәләре, якындагы массовый чаралар турында көтепханәнең белдерүләре элена.

Әгәр дә көтепханәнең уку залы булмаса, ул вакытта абонемент бинасында белешмәләр тактасы элена, көтепханәнең стена газетасы яки укучыларның китаплар турындагы фикерләре бюллетене элена, данлыклы даталар календаре һәм һәр датага карата әдәбият исемлекләре, географик карталар, „яңа китаплар" витринасы элена.

Абонемент бинасында китап күргәзмәләре оештырыла. Моның өчен махсус урын булмаганда китап бирү өстәленә якын торган стеллажларның ян-як стеналары файдаланыла. Аерым өстәлгә көтепханәнең каталоглары куела. Китап бирү өстәле өстендә көтепханә эшчесенең кул астында тематик картотекалар һәм бигрәк тә тәкъдим ителә торган әдәбият белән ярдәмче ящиклар урнаштырыла.

Аерым өстәлгә газета һәм журналларның соңгы номерлары тезеп куела.

Абонемент үзенең тышкы күренеше белән китапларны пропагандалауга хезмәт итәрлек булсын өчен, гомумән аны формалаштыру эшенә бик зур игътибар бирергә кирәк.

### § 9. УКУЧЫЛАРГА УКУ ЗАЛЫНДА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Уку залы укучыларга көтепханәнең үзендә китаплар, газеталар һәм журналлар белән хезмәт күрсәтү өчен билгеләнә, анда өйгә алып китү өчен китаплар бирелми.

Уку залында китап өстендә тыныч һәм нәтиҗәле итеп эшләү өчен бөтен шартлар тудырылган булырга тиеш. Көндез дә һәм кичен дә яктылыкның җитәрлек булуы турында кайгыртырга кирәк.

Бүлмәнең уртасына озынча яки дүрт почмаклы зур өстәл куела. Бу өстәл тирәсенә утырып яңа газеталар һәм журналлар укыйлар. Стеналар буйлап һәрберсе бер-ике кешелек берничә вак өстәл куярга кирәк. Аларның өстендә лампасы һәм кара савыты да булсын. Уку залына озак вакытка китап өстендә эшләү өчен килгән кешеләргә мондый вак өстәлләр бик уңайлы була.

Өстәлләрне тәрәзәгә перпендикуляр итеп куярга кирәк, яктылык сул яктан төшәрлек булсын.

Уку залын җилләтүне тәэмин итәргә кирәк, анда тәмәке тартуны бик нык тыярга кирәк. Уку залында тынычлык сакланырга тиеш, укучылар арасында сөйләшүләргә рөхсәт ителми, көтепханә эшчесе укучы белән кычкырмый гына сөйләшә. Йөргәндә аяк тавышы ишетелерлек булмасын өчен өстәл араларына идәнгә җәймәләр җәелә.

Уку залын чиста һәм тәртипле тотарга, көн саен тузаннарын сөртергә һәм идәнне юарга, кирәксез әйберләр тотмаска кирәк. Стеллажлардан тыш уку залында стенага эшләнгән китап киштәләре һәм шкафлары булырга мөмкин.

Уку залының китап фонды аз файдаланыла торган яки артык китаплар булмаслык итеп туплана һәм анда кирәкле әдәбиятның бөтенесе кул астында булырга тиеш. Беренче чиратта уку залында түбәндәге басмалар булырга тиеш:

1) марксизм-ленинизм классикларының әсәрләре, әсәрләр җыентыклары, сайланма әсәрләр, тематик җыентыклар һәм аерым әсәрләр;

2) агымдагы агитация-масса әдәбияты;

3) барлык белем тармаклары—тарих, география, табигать белеме, авыл хуҗалыгы, техника буенча төп хезмәтләр;

4) агымдагы фәнни һәм матур әдәбият яңалыклары;

5) классик әдәбиятның (бөтен дөнья һәм СССР халыклары әдәбиятының), хәзерге матур әдәбиятның (советлар иле һәм чит илләр әдәбиятының) иң яхшы әсәрләре;

6) дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләре;

7) белешмә әдәбият (энциклопедияләр, сүзлекләр һ. б.);

8) вакытлы матбугат (журналлар һәм газеталар).

Көтепханәгә алына торган агымдагы вакытлы матбугат иң элек уку залына керә. Абонементта журналларның икенче данәләре генә кала. Үткән елгы вакытлы матбугат көтепхананың төп фондына тапшырыла.

Булган һәм яңа алынган дәреслекләр һәм белешмәләр беренче чиратта уку залына бирелә, абонемент фондында икенче данәләре генә кала.

Уку залы вакытлы матбугат, дәреслекләр, белешмәләр белән эш алып барыла торган төп урын санала.

Уку залына өйгә бирелми торган басмалар җыела: СССР тарихы, ВКП(б) тарихы буенча күргәзмә ярдәмлек альбомнары, географик атласлар, сәнгать тарихы, классикларның академик басмалары кебек кыйммәтле басмалар туплана.

Икенче яктан, масса тарафыннан күп сорала торган, бик күп укыла торган китаплар да, хәтта бер генә данәдә булсалар да, беренче вакытта уку залына биреләләр. Шул юл белән китапларның күп әйләнүенә, китап фондыннан күбрәк файдалануга ирешелә.

Уку залында журналларның соңгы номерлары өстәлгә тезелә яки „Яңа журналлар“ дип язылган витринага куела; укучы күп кенә журналларны карап шулар арасыннан үзенә кирәген сайлап ала.

Массовый брошюралар ярдәмче ящикларда торалар һәм шулай ук карау өчен укучыларга биреләләр.

Белешмәләр шкафка яки аерым киштәгә, яки стеллажга куелалар, газеталарның айлык подшивкалары киштәләргә тезелә яки газеталар саклана торган махсус стеллажларга куелалар, белешмә әсәрләрне һәм газета подшивкаларын укучыларның үзләренә карарга рөхсәт ителә.

Аерым өстәлгә уку залы каталоглары, газета-журнал мәкаләләренең тематик картотекалары, библиографик күрсәткечләр, рецензия альбомнары, укучыларның китаплар турында фикерләрен күрсәткән язмалар куела.

Уку залы китапларны күргәзмә пропагандалау урыны булып тора. Биредә көтепханә плакатлары эленә, күп кенә китап күргәзмәләре, әлбәттә—яңа китаплар күргәзмәсе оештырыла.

Уку залы вакытлы матбугат белән эшләү урыны булып тора. Үзәктә чыга торган газеталарның берсе („Правда“, „Известия“, „Комсомольская правда“), өлкә

һәм район газеталары биредә эленә. Биредә „Соңгы яңалыклар“ витринасы оештырыла, бик әһәмиятле хәбәрләрне радио буенча коллектив рәвештә тыңлаулар оештырыла, географик карта эленә. Газетадан кисеп алган мәкаләләрнең альбомнары һәм папкалары биредә урнаштырыла, тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре эленә.

Уку залында, абонементтагы кебек үк, укучы белән аерым эш алып барыла, укучыларның үзлекләреннән белем алуларына булышлык күрсәтелә. Уку залы шартларында көтепханә эшчесе укучы белән китаплар биргәндә һәм алганда беседа үткәрү белән генә чикләнми, бәлки укучыга аның китап өстендә эшләвенә дә ярдәм итә: китаптагы аңлаешсыз урыннарны укучыга төшендерә, каталог белән һәм библиографик материаллар белән эшләү алымнарын күрсәтә.

Уку залында китап бирү техникасы абонементтагыңар караганда гадирәк.

Уку залында һәрвакыт китаплардан файдаланучы укучыларга гадәттәге формулярлар тутырыла. Журнал һәм газеталардан гына файдаланучы укучыларга формулярлар тутырылмый. Китапны биргәндә аның кесәсеннән китап формуляры алына да, укучы формуляры эченә салып куела. Укучыдан расписка таләп ителми, чөнки китап укучы формулярына язылмый. Шулай да китап формулярына китапны бирү датасы һәм укучының номеры язып куела. Шушы мәгълүматларга карап уку залында эшләүче работник теге яки бу китапны күпме кеше укыганлыгын, укучылардан кемнәр шушы китапны алганлыгын белә ала. Ләкин китап бирүләрне шундый система белән яза барганда һәр укучының уку картинасы ачылмый кала. Укучы китапны тапшырган вакытта аның формуляры укучы формулярыннан алынып китапның кесәсенә салып куела. Шул рәвешчә укучы формулярында аңа бирелгән китаплар турында бернинди мәгълүмат булмый. Көтепханә техникасы минимумы буенча уку залыннан китаплар бирү менә шулай формалаштырыла. Ләкин, әгәр дә мөмкинлек булса, бирелгән китапларны укучы формулярына язу да зыян итми. Болай эшләгәндә көтепханә эшчесе бу укучының нинди китаплар алганын күрә һәм киләчәктә уку өчен әдәбиятны яхшырак тәкъдим итә ала.

Уку залына куелган журналларны һәм газеталарны укучылар үзләре алалар, аларның формулярларына язып тормыйлар.

Уку залы работнигы яки дежур торучы укучы-активист газета-журналлар бирүне гомуми саны белән генә язып куя: эш көне эчендә фәлән кадәр кеше фәлән кадәр газета һәм журнал алды дип яза.

Уку залының эш йомгаклары (яңа гына язылган укучыларның саны, килүчеләр саны, бирелгән китаплар саны) „Көтепханә көндәлеге“нә языла. Көн саен бирелгән журналлар һәм газеталар саны да көндәлеккә „искәрмә“ графасына языла.

## *VIII БҮЛЕК*

# МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ БЕЛЕШМӘ-БИБЛИОГРАФИЯ ЭШЕ

## § 1. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ БЕЛЕШМӘ-БИБЛИОГРАФИЯ ЭШЕНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ

Укучылар көтепханәгә бик күп төрле сораулар белән мөрәҗәгать итәләр: теге яки бу мәсьәлә буенча нәрсәләр укырга, теге яки бу илләрдә нинди вакыйгалар бар, авыл хуҗалыгы культураларының уңышын ничек күтәрергә, яшелчәләрне ничек сакларга һ. б. ш.

Көтепханәнең белешмә эше җирле халык тормышы белән бәйләнгән булырга, политик эчтәлек белән сугарылырга, илне саклау интересларына, аның экономик һәм культура үсеше бурычларына буйсындырылган булырга тиеш.

Гомумән массовый көтепханәнең белешмә-библиография эшенең түбәндәге бурычларын күрсәтергә мөмкин:

1. Укучыларга агымдагы политика мәсьәләләрен, халыкара хәл мәсьәләләрен аңлату.

2. Укучыларга партия һәм хөкүмәт карарларын аңлату.

3. Укучыларга хәрби эш буенча, авыл хуҗалыгы, төрле фән һәм техника тармаклары буенча, әдәбият һәм сәнгать буенча кирәкле белем алуда ярдәм итү.

4. Җирле предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга аларның эшендә, бигрәк тә яңа производстволарны үзләштерүдә, җирле ресурслардан файдалануда ярдәм итү.

5. Халыкка юридик мәсьәләләрне һәм көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә, гаризалар, хатлар язуда һәм башка шундый мәсьәләләрдә булышлык күрсәтү.

Башка учреждениеләрдән һәм оешмалардан үзгә буларак, көтепханә үзенең белешмә эшен китап, журнал һәм газеталарны пропагандалау белән бергә сәйләп алып бара, белешмә биргәндә әдәбият тәкъдим итә, бу эшкә библиографик характер бирә.

## § 2. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕН БЕЛЕШМӘ-БИБЛИОГРАФИЯ ЭШЕН ОЕШТЫРУ

Көтепханәгә укучыларның төрле сораулар белән күп мөрәҗәгать итүләренә ирешү өчен аның белешмә эше турында җирле халыкка киң рәвештә белдерергә кирәк. Көтепханәдә белешмә, киңәш һәм консультация алырга мөмкин икәнен һәрбер хезмәт иясе белергә тиеш.

Мәсәлән, Киров өлкәсенең Герцен исемендәге көтепханәсе мондый белдерү элгән:

„Белешмә алу өчен Герцен исемендәге өлкә көтепханәсенең белешмә-библиография бүлегенә мөрәҗәгать итегез (Киров шәһәре, Герцен урамы, йорт 50, тел. 88—18).

Герцен исемендәге көтепханәнең белешмә-библиография бүлеге укучыларга, оешмаларга, учреждениеләргә, өлкәдәге һәм шәһәрдәге көтепханәләргә кирәкле әдәбиятны сайлауда, сайлап алынган китапка яки авторга бәя бирүдә булышлык күрсәтә, укучыларга китаплар уку турында белешмәләр һәм киңәшләр бирә, уку өчен китаплар исемлеген төзи, көтепханә каталоглары буенча белешмәләр бирә.

Бүлек каршында бик күп санда энциклопедияләр, сүзлекләр тупланган, „Совет халкының Бөек Ватан сугышы“ дигән картотека һәм бүтән төрле тематик картотекалар бар. Укучыларның һәм оешмаларның алдан бирелгән сораулары язма рәвештә һәм телефон аша кабул ителә һәм 2—3 көннән үтәлә.

Белешмә-библиография бүлеге көн саен иртәнге 10 сәгатьтән кичке 10 сәгатькә кадәр эшли“.

Шул ук белдерү, кечкенә генә листовка төсендә (чакыру билеты шикелле итеп) бастырылып, көтепханә тарафыннан Киров шәһәрендәге учреждениеләргә, предприятиеләргә һәм оешмаларга, барлык район газеталарына һәм заводлардагы күп тиражлы газета редакцияләренә, Киров өлкәсенең барлык шәһәр, район һәм авыл көтепханәләренә җибәрелгән.

Шуның өстенә газета редакцияләренә көтепханә тарафыннан языла торган китап күзәтүләрен („китап киштәләрен“) урнаштыру тәкъдиме белән хатлар, учреждениеләргә һәм предприятиеләргә — аларның сораулары буенча яңа китапларның тематик бюллетеньнәрен төзү тәкъдиме белән хатлар җибәргән.

Ниһаять, көтепханә аерым кешеләргә түбәндәге формада информацион хатлар җибәргән:

**Яңа китаплар турында белдерү**

*Иптәш* ______________________________

*Герцен исемендәге көтепханә күп кенә яңа, бик кызыклы һәм файдалы китаплар алды. Шул исәптән түбәндәге китаплар алынуын белдерәбез:*

| Тәр. №№ | Автор | Китапның исеме | Бит саны |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Район һәм авыл көтепханәләре дә шулай ук үзләре алып бара торган белешмә-библиография эшен пропагандаларга: көтепханә, авыл советы, колхоз идарәләре биналарында ук эш турында белдерүләр эләргә, аерым укучыларга информацион хатлар җибәрергә тиешләр. Билгеле, район һәм авыл көтепханәләре белешмә-библиография эшен өлкә көтепханәсе алып барган күләмдә алып бара алмыйлар, ләкин алар өлкә көтепханәсенең белешмә-библиография бүлеге тарафыннан эшләнгән материаллардан — әдәбият тәкъдим иткән исемлекләрдән, яки махсус сорау буенча җибәрелгән кечкенә генә библиографик белешмәдән файдалана алалар. Укучылар биргән сорауларның үзләре җавап бирә алырлык булмаганнарын район һәм авыл көтепханәләре, әдәбият күрсәтүне генә түгел, бәлки көтепханәләр арасындагы абонемент тәртибендә китаплар җибәрүне дә үтенеп, өлкә көтепханәсенә җибәрә алалар. Өлкә көтепханәсе өлкәдәге көтепханәләр өчен

белешмә-библиография эшенең үзәге булып хезмәт итә һәм аларны тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре белән һәм бик кызыклы белешмәләр белән тәэмин итәргә тиеш.

Ләкин, хәтта өлкә көтепханәсе ярдәмендә дә район көтепханәсе работниклары өчен, бигрәк тә авыл көтепханәсе эшчесе өчен, укучыларның барлык сорауларына җавап бирү кыен була. Мондый хәлләрдә көтепханәгә җирле оешмаларның, урыннардагы белгечләрнең, район яки авыл активының ярдәме аеруча кирәк була.

Мәсәлән, Вожгор авыл көтепханәсе (Архангельск өлкәсе, Лешукон районы) агрономны, медицина работникларын һәм укытучыларны тартып, алар ярдәмендә белешмә өстәле оештырган, анда билгеле көннәрдә һәм сәгатьләрдә колхозчыларга белешмәләр бирелә. Көтепханәгә ярдәмгә чакырылган белгечләр һәм активистлар белешмә өстәле янында дежур торалар, сорау-җавап кичәләре оештыруда көтепханәгә ярдәм итәләр.

Ниһаять, күп кенә белешмәләрне төрле ярдәмлекләр һәм директив, белешмә, библиографик материаллар ярдәмендә көтепханә эшчеләре үзләре дә бирәләр.

## § 3. БЕЛЕШМӘ, БИБЛИОГРАФИЯ ҺӘМ БҮТӘН ЯРДӘМЧЕ МАТЕРИАЛЛАРНЫ САЙЛАУ ҺӘМ ФАЙДАЛАНУ

Белешмә ярдәмлекләрнең иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр:

1. Энциклопедияләр. „Зур Совет энциклопедиясе" (БСЭ), „Кечкенә Совет энциклопедиясе" (МСЭ).

2. Сүзлекләр. „Политик сүзлек". Г. Александров һ. б. редакциясендә. М. Госполитиздат. 1940.

„Кыскача философик сүзлек". М. Розенталь һәм П. Юдин редакциясендә. Тулыландырылган 2 нче басмасы. М. Политиздат. 1940.

„Чит сүзләр сүзлеге". Ф. Петров редакциясендә. 2 нче басмасы. М. Чит сүзләр һәм милли сүзлекләр дәүләт издательствосы. 1942 (беренче басмасыннан да файдаланырга мөмкин).

Проф. Д. Н. Ушаков һәм доц. С. Е. Крючков. Орфографик сүзлек. Башлангыч, җиде еллык һәм урта мәктәпләр өчен. Төзәтелгән һәм тулыландырылган 6 нчы басмасы. М. Учпедгиз. 1944.

„Русча-татарча сүзлек". Проф. М. Корбангалиев һәм М. Гимадиев редакциясендә. 2 нче басмасы. Казан. Татгосиздат. 1940.

Саналган сүзлекләрнең бөтенесе һәр массовый көтепханәдә булу кирәк.

Район көтепханәләрендә шулар өстенә чит телләр сүзлекләре: инглизчә-русча һәм русча-инглизчә, французча-русча һәм русча-французча, немецчә-русча һәм русча-немецчә сүзлекләр булу кирәк.

3. Календарьлар. Мәсәлән: „Календарь-белешмә". М. Госполитиздат. 1944.

„1945 һәм 1946 елларга колхозчының өстәл календаре". М. Сельхозгиз.

4. Работникларның төрле группалары өчен белешмә (спутниклар, истәлекләр), мәсәлән:

„Колхоз председателе белешмәсе". М. Сельхозгиз. 1941.

„Колхоз бригадиры белешмәсе". М. Сельхозгиз. 1941.

„Башлангыч мәктәп укытучысы өчен белешмә китабы". М. А. Мельниковның гомуми редакциясендә. РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан укытучыларга ярдәмлек сыйфатында расланган. М. Учпедгиз. 1941.

5. Аерым фән, техника, авыл хуҗалыгы тармаклары буенча белешмәләр, мәсәлән:

„Элементарь математика, механика һәм физика буенча белешмә". 3 нче басмасы. Гостехиздат. 1943.

„Терлекчелек буенча сүзлек-белешмә". Акад. Е. Ф. Лискун һ. б. редакциясендә. Яңадан эшләнгән 2 нче басмасы. М. Сельхозгиз. 1939.

6. Экономик һәм географик характердагы белешмәләр, географик атласлар, мәсәлән:

„Дөньядагы илләр". Кыскача белешмә. П. Ф. Юдин һәм Ф. Н. Петров редакциясендә. М. ОГИЗ. Совет энциклопедиясе. Дәүләт Институты. 1942.

7. Директив материаллар җыентыклары, партия һәм хөкүмәтнең аерым карарлары, мәсәлән: „Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе съездлар, конференцияләр һәм Үзәк Комитет пленумнары резолюцияләрендә һәм карарларында (1899—1939)". Тулыландырылган 6 нчы басмасы. I—II кисәк. М. Госполитиздат. 1940. 2 том. ВКП(б) ҮК каршындагы Маркс—Энгельс—Ленин институты.

„Авыл хуҗалыгы буенча 1938—1941 елларда чыккан бик әһәмиятле карарлар". М. Сельхозгиз. 1942.

„СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгы буенча 1942—1944 елларда чыккан бик әһәмиятле карарлары". М. Сельхозгиз. 1944.

СССР Совнаркомында һәм ВКП(б) Үзәк Комитетында. Немец оккупациясеннән азат ителгән районнарда хуҗалыкны торгызу буенча ашыгыч чаралар турында. М. Госполитиздат. 1943 һәм соңгы еллардагы бүтән карарлар.

8. Законнар җыентыклары. Кодекслар. „Совет Социалистик Республикалар Союзы Конституциясе (Төп Законы)".

„Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Конституциясе (Төп Законы)". М. РСФСР Верховный Советы.

Татарстан АССР Конституциясе. Татгосиздат. 1946 ел.

Е. Астрахан, С. Бартусь, А. Рускол. Хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның семьяларына льготалар, пособияләр һәм пенсияләр. М. Юриздат. 1942.

„Сугыш вакытындагы хезмәт законнары". Җыентык. М. Профиздат. 1942.

„Гражданнар өчен процессуаль кодекс". 1940 елның 15 ноябрена булган үзгәрешләр белән. М. Юриздат. 1941.

„Җинаять кодексы". 1944 елның 1 августына булган үзгәрешләр белән. М. Юриздат. 1941.

Үткән елларда чыккан белешмәләрдән һәм сүзлекләрдән файдаланганда, аларда басылган материалларның искерүләре мөмкинлеген исәпкә алып, тәнкыйть күзлегеннән карап файдаланырга кирәк. Кайбер хәлләрдә белешмәләр алу өчен үзләре белешмә китаплары булмыйча, бәлки укыту яки үзлегеннән белем алу өчен билгеләнгән китаплардан да файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, төрле тарихи вакыйгалар турында, хронологик даталар турында белешмәлар алу өчен урта мәктәпләр өчен тарих буенча дәреслекләрдән файдаланырга мөмкин.

Марксизм-ленинизм өлкәсендә төп белемнәр энциклопедиясе булган „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" белешмә эшендә зур урын тота. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"ннан һәм аңа карашлы журнал һәм газета материалларын (консультацияләрне, сорауларга җавапларны һ. б.) көтепханә киң файдаланырга тиеш.

Язучылар, бигрәк тә классиклар турында белешмә алу өчен әдәбият дәреслекләреннән файдаланырга мөмкин, мәсәлән: Н. Поспелов һәм П. Шаблиовский. Рус әдәбияты. Урта мәктәпнең 8 нче классы өчен дәреслек. 3 нче басмасы. М. Учпедгиз. 1941.

А. А. Зерчанинов, Д. Л. Райхин һәм Д. И. Строганов. Рус әдәбияты. Урта мәктәпнең 9 нчы классы өчен дәреслек. М. Учпедгиз. 1940.

Чит илләр турында белешмәләр алу өчен, махсус белешмә китаплары булмаганда, география дәреслекләренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Икенче бөтен дөнья сугышы вакыйгаларын һәм фактларын аңлау өчен географияне тирәнтен белү таләп итеп; Бирма, Малакка, Голландия Һиндстаны, Мадагаскар, Яңа Зеландия, Яңа Гвинея, Латин Америкасы илләре һ. б. турында белешмәләр эзләргә туры килә. Бу мәсьәләләр буенча „Спутник агитатора" журналында „Агитатор белешмәсе" дигән бүлектә күп материал бирелгән (мәсәлән „Спутник агитатора" журналының 1944 елда чыккан 17 нче номерында, 41—47 битләрдә Болгария һәм Бельгия турында мәкаләләр бар).

Шул ук журналның шул ук бүлегендә белешмә характерындагы бүтән материаллар да басылган, мәсәлән, 1943 елда чыккан 10 нчы номерында без „1943 елның маенда газеталарда игълан ителгән бик әһәмиятле документлар исемлеген“ табабыз, 1943 елгы 9 нчы номерында „Атлантик хартия“ дигән белешмәне табабыз (47 бит) һ. б. Бу журналның күп кенә мәкаләләре хәзерге заманның актуаль мәсьәләләре буенча консультацияләр яки җаваплар бирәләр.

Агымдагы политика буенча сорауларга җавап бирү өчен „Большевик“, „Пропагандист“ журналларыннан, „Правда“, „Известия“, „Комсомольская правда“ газеталарыннан һ. б. мәкаләләрне файдаланырга кирәк.

Укучыларның сораулары буенча әдәбият исемлекләре төзегәндә, беренче чиратта, укучы сораган темага карый торган урыннарын күрсәтеп, марксизмленинизм классиклары әсәрләрен тәкъдим итәргә кирәк. Аерым төшенчәләрне, чит сүзләрне аңлатканда да шулай ук марксизм-ленинизм классикларының бу турыда әйткәннәреннән чыгып эш итәргә кирәк.

Б Яковлевның „Кирәкмәгәндә чит ил сүзләре кулланмаска“ дигән мәкаләсендә („Спутник агитатора“, 1943, № 10, 35—36 бит) чит ил сүзләре җыелмасы В. И. Ленинның аңлатмалары белән бирелгән, мәсәлән:

Авангард — алдынгы отряд (XVII. 49).
Автономияле—мөстәкыйль (X. 259).
Авторитет — ихтирам (XXIV. 365).
Анализ — тикшерү (XXIV. 285) һ. б.

Бу мәкаләдә китерелгән исемлек һәр көтепханә аны „В. И. Ленин аңлатмасында чит ил сүзләре“ дигән плакат төсендә язып куярга лаеклы бер материал.

„Спутник агитатора“ журналының күп номерларында (мәсәлән, 1944 ел, № 17 дә, 47—43 бит) „Агитатор сүзлеге“ дигән бүлек бар. Бу бүлектә матбугатта очрый торган аерым сүзләргә һәм төшенчәләргә аңлатма бирелә. Бу сүзлекне, аның һәр анлатмасын аерым карточкага яки аерым кәгазь кисәгенә күчереп алып һәм ул карточкаларны яки кәгазь кисәкләрен аңлатыла торган сүзләрнең алфавиты тәртибендә тезеп куеп, картотека яки папка төсендә формалаштырырга мөмкин.

„Политпросветработа“ журналында „Белешмә өстәле работнигына ярдәмгә“ дигән бүлек бар. Мәсәлән, аның 1943 елда чыккан 4—5 номерында хәрби хезмәт-

кәрләр семьяларына белешмәләр белән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле материаллар күрсәткече бирелгән.

Шулай итеп вакытлы матбугат басмаларында көтепханәнең белешмә эшендә файдаланырга мөмкин булган күп кенә материаллар була.

Бу материалларны махсус белешмә картотекасы ярдәмендә яки, мәсәлән, „Верховный Баш Командующий приказлары", „Партия һәм Хөкүмәт карарлары", „Халыкара хәл" кебек тематик картотекалар ярдәмендә исәпкә алырга кирәк.

Әгәр дә көтепханә үзәк газеталарын икешәр данә һәм аннан күбрәк алса, бер данәсен көтепханәгә белешмә эшендә кирәкле материалларны кисеп алу өчен файдаланырга мөмкин.

Газетадан кисеп алынган материаллар аерым папкага тегеп барылалар һәм бу папка белешмә киштәсендә саклана. Урындагы тормышны яктырта торган материаллар (җирле совет һәм партия органнарының карарлары, киңәшмәләр, конференцияләр материаллары һ. б.) тупланган папка булдыру белешмә эше өчен бик әһәмиятле. Ниһаять, дәүләт заемнары тиражларының таблицаларын системалы рәвештә аерым папкага җыя барырга һәм сакларга кирәк.

Көтепханә белешмәләрендә гадәттә укучы биргән сорау буенча әдәбият күрсәтелә, кайвакытларда барлык белешмә китапларны һәм газета-журнал мәкаләләрен санап күрсәтүгә кайтып кала. Шуңа күрә библиографик ярдәмлекләр көтепханәнең белешмә эшендә кирәкле ярдәмче материал булып тора.

Иң элек марксизм-ленинизм классиклары әсәрләренә карата библиографик күрсәткечләр тупларга кирәк.

1940 елда ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Маркс—Энгельс—Ленин институты тарафыннан хәзерләнгән „К. Маркс һәм Ф. Энгельс Әсәрләренә карата алфавитлы күрсәткеч" басылып чыкты (М. Госполитиздат. 1940. 111 бит). Бу ярдәмлек ике кисәктән тора:

1. Әсәрләрнең алфавитлы күрсәткече.

2. Маркс һәм Энгельсның өченче кешеләргә язган хатларының алфавитлы күрсәткече.[1]

---

[1] „К. Маркс һәм Ф. Энгельс Әсәрләренә карата алфавитлы күрсәткеч"нең әһәмияте һәм аны файдалану турында „Большевик" журналында И. Дальский мәкаләсен кара. 1940 ел, № 14, 84—89 битләр.

В. И. Ленин әсәрләренә карата төп библиографик ярдәмлек булып „В. И. Ленин Әсәрләренең II һәм III басмаларына карата белешмә“ китабы хезмәт итә. Бу белешмәдә түбәндәге күрсәткечләр бар:

1) В. И. Ленин „Әсәрләре“нең II һәм III басмаларына кергән хезмәтләрнең алфавитлы күрсәткече.

2) Ялгышлык белән В. И. Ленинныкы дип саналган һәм „Әсәрләр“нең II һәм III басмаларына кертелгән мәкаләләрнең исемлеге.

3) „Әсәрләр“нең II һәм III басмаларына предметлы күрсәткеч.

4) „Әсәрләр“нең II һәм III басмаларына карата исемнәр күрсәткече.

5) В. И. Ленинның, К. Маркснең һәм Ф. Энгельсның Ленин тарафыннан файдаланылган һәм искә алынган хезмәтләренең алфавитлы күрсәткече.

Алфавитлы күрсәткеч, әсәрнең исеме яки формасы (речь, доклад, рецензия һ. б.) безгә билгеле булганда, теге яки бу әсәрнең кайсы томда басылганлыгын белергә мөмкинлек бирә.

Предметлы күрсәткеч Ленинның төрле мәсьәләләр һәм темалар буенча, мәсәлән, сугыш, демократия, социалистик ярыш, хезмәт җитештерүчәнлеге һ. б. буенча күп кенә әсәрләрен яки әйткән фикерләрен эзләп табарга мөмкинлек бирә.

Исемнәр күрсәткече Ленинның аерым кешеләр— политик деятельләр, язучылар, галимнәр һ. б. турындагы сүзләрен эзләп табарга ярдәм итә. Ленин турында әдәбият сайлау өчен **„Ленин турында нәрсәләр укырга“** дигән кыскача әдәбият күрсәткечен файдаланырга кирәк. Л. А. Левин редакциясендә. М. 1944. 28 бит (СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт китапханәсе. Дәүләтнең публичный тарихи китапханәсе).

Иптәш Сталин әсәрләреннән „Ленинизм мәсьәләләре“нең 10 нчы басмасы предметлы һәм исемнәр күрсәткечләре белән тәэмин ителгән (614—652 битләрне кара). Иптәш Сталин әсәрләренең һәм иптәш Сталин турындагы әдәбиятның төп күрсәткече булып „Сталин һәм Сталин турында“ дигән күрсәткеч хезмәт итә. (Л. Ленпартиздат. 1940. 276 бит. М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге Хезмәт Кызыл Байрак орденлы Дәүләт публичный китапханәсе).

Шуның өстенә И. В. Сталинга алтмыш яшь тулуга карата чыгарылган „Сталин турында“ дигән әдәбият

күрсәткече кирәк (М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1940. 120 бит).

В. И. Ленинның һәм И. В. Сталинның коммунистлар партиясе һәм совет дәүләте тарихының төрле чорларына караган мәкаләләрен эзләп табу өчен „ВКП(б) тарихының кыскача курсын“ өйрәнүчеләргә ярдәмгә төп беренче чыганаклар күрсәткече бик файдалы (тулыландырылган 2 нче басмасы. М. ВКП(б) ҮК каршындагы Политиздат. 1940. 192 бит).

Һәрбер массовый көтепханә Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбият библиографиясе белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Бөек Ватан сугышы турында гомуми әдәбият күрсәткечләре түбәндәгеләр:

**Совет халкының Бөек Ватан сугышы.** Мәктәпкә ярдәмгә әдәбият күрсәткече. Төзүчесе В. Н. Недзвецкая. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1943. 112 бит.

**Совет халкының Бөек Ватан сугышы.** Сугышның бер елы эчендә чыккан әдәбиятның аннотацияле күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә библиография издательствосы. 1942. 108 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1942 елның июль—сентябрь айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1943. 80 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1942 елның октябрь—декабрь айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1943. 76 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1943 елның январь—март айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1943. 76 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1943 елның апрель—июнь айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1943. 101 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1943 елның июль—сентябрь айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1943. 108 бит.

**Бөек Ватан сугышы.** 1943 елның октябрь—декабрь айларында чыккан әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1944. 136 бит.

**Балаларга Бөек Ватан сугышы турында.** Аннотацияле әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 48 бит.

**Фашизм — кешелекнең иң явыз дошманы.** Аннотацияле әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 48 бит (СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе).

Сугыш елларында хәрби әдәбият библиографиясе киң үсүгә иреште.

Массовый көтепханәгә хәрби әдәбиятның түбәндәге күрсәткечләре бик кирәк:

**Бөек Ватан сугышының өч елы эчендә хәрби әдәбият.** Массовый көтепханәләр өчен төп әдәбият күрсәткече. Төзүчесе интендантлык хезмәте майоры П. И. Карклин. Майор Г. С. Красовский редакциясендә. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1944. 88 бит.

**Ватан сугышында хәрби әдәбият.** Массовый көтепханәләр өчен әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепхანә-библиография издательствосы. 1942. 88 бит.

**Всевобуч командирына һәм сугышчысына ярдәмгә.** Аннотацияле әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 56 бит.

**Гомуми хәрби өйрәтү.** Әдәбият күрсәткече. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1942. 88 бит.

Укучыларның киң массасы рус халкының героик тарихы белән бик кызыксына. Көтепханәне беренче чиратта түбәндәге тарихи әдәбият күрсәткечләре белән тәэмин итәргә кирәк:

**Ватан өчен көрәш.** Рус халкының героик тарихыннан. Массовый көтепханәләр өчен төп әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 52 бит.

**Иң борынгы заманнардан алып XIX гасыр азагына кадәр СССР тарихы.** Тәкъдим ителә торган әдәбият һәм төп ярдәмлекләр исемлеге. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1941. 112 бит.

**Безнең бөек бабаларыбыз.** Әдәбият күрсәткече. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1942. 80 бит.

**Рус халкының бөек культурасы вәкилләре турындагы әдәбиятның кыскача күрсәткече.** М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 48 бит.

Табигать фәне әдәбияты күрсәткечләреннән массовый көтепханә өчен түбәндәгеләр файдалы:

**Астрономия.** Үзлегеңнән белем алу белән шөгыльләнүчеләр өчен уку программасы. Проф. К. Л. Баев төзегән. Проф. П. П. Пареный редакциясендә. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940. 32 бит.

**Ю. И. Миленушкин.** Биология. Фәнни популяр әдәбият күзәтүе. М. Көтепханә белеме һәм библиография буенча фәнни тикшерену институты. 1938. 72 бит.

**Табигать белеме.** Беседа һәм лекция темаларына карата кыскача әдәбият күрсәткече. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1944. 36 бит.

**Фән яктылыгында табигать могҗизалары һәм табышмаклары.** Аннотацияле әдәбият күрсәткече. М. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1944. 28 бит.

Югарыда саналган тематик күрсәткечләрдән тыш бөек галимнәр — табигатьне өйрәнүчеләр (Галилей, Дарвин, Ломоносов, К. А. Тимирязев, Менделеев, И. П. Павлов һ. б.) турында күп кенә персональ әдәбият күрсәткечләре чыгарылды.

Авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча библиографик белешмәләр бирү өчен түбәндәге күрсәткечләр кирәк:

**Авыл хуҗалыгы.** Әдәбият күрсәткече. П. В. Якушкин редакциясендә. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941. 96 бит.

**Авыл хуҗалыгы буенча төп белешмә әдәбият.** Аннотацияле күрсәткеч. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 24 бит.

**Колхоз председателе өчен уку даирәсе.** Н. И. Анисимовның гомуми редакциясендә. СССР ның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт көтепханәсе. 1944. 48 бит.

Техник әдәбият библиографиясе бик киң һәм күбесенчә специаль характерда. Массовый көтепханәләр өчен кечкенә генә әдәбият исемлекләре сериясе тәкъдим ителә. Мәсәлән: СССР Наркомуголенең Дәүләт фәнни көтепханәсе тарафыннан бастырып чыгарылган: „Эшчегә үз производствосы турында нәрсә укырга“ дигән серия һәм Дәүләт политехника көтепханәсенең: „Техника турында нәрсәләр укырга“ дигән сериясе, Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы тарафыннан чыгарылган: „Техника нәрсә ул һәм кешенең тормышында аның әһәмияте“, „Машиналар һәм аларны җитештерү“, „Энергетика“, „Электр элемтәсе (телеграф, телефон, радио, телевидение)“ буенча нәрсәләр укырга, „Шәһәр транспорты“ серияләре.

Матур әдәбият буенча библиографик материалларны мөмкин кадәр тулырак җыярга кирәк. Гомуми ярдәмлекләрдән беренче чиратта түбәндәгеләр кирәк:

**Рус классик әдәбияты.** Аннотацияле каталог. Проф. И. Нусинов редакциясендә. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941.

**Совет матур әдәбияты.** Аннотацияле каталог. Проф. Л. И. Тимофеевның гомуми редакциясендә. М. Дәүләт көтепханә-библиографиясе издательствосы. 1941.

**Художестволы-тарихи әдәбият.** Әдәбият күрсәткече. Төзүчесе И. С. Ежов. Редакторы проф. Н. М. Коробков. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1943.

**Англия һәм Америка әдәбиятының иң яхшы вәкилләре** Тәрҗемәләрнең һәм рус телендә чыккан тәнкыйть әдәбиятының библиографик күрсәткече. Чит илләр әдәбиятының Дәүләт Үзәк көтепханәсе тарафыннан төзелгән. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 42 бит.

**Чит илләрнең фашизмга каршы булган матур әдәбияты.** Аннотацияле әдәбият күрсәткече. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1943. 104 бит (чит илләр әдәбиятының Дәүләт Үзәк көтепханәсе).

**Славян халыкларының русчага тәрҗемә ителгән матур әдәбияты.** Әдәбият күрсәткече. Төзүчеләре: Н. И. Пожарский, А. М. Паевская, М. С. Морщинер. Редакторы М. И. Рудомино. М. Бөтенсоюз китап палатасы. 1943.

Бик күп күрсәткечләр чит ил әдәбиятының һәм СССР халыклары әдәбиятының аерым вәкилләренә багышланган. Мөмкин булганда көтепханә Пушкин, Гоголь, Лермонтов, Некрасов, Салтыков-Щедрин, Л. Толстой, Чехов, Горький, Маяковский турында күрсәткечләр булдырырга тиеш.

Ниһаять, әгәр көтепханә балалар әдәбияты белән эш алып бара икән, балалар әдәбияты күрсәткечләре кирәк.

**Нәни балалар өчен китаплар.** Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм 1—2 классларда укучы балалар өчен китаплар күрсәткече. М.—Л. Детиздат. 1943. 48 бит.

**Балаларга нәрсәләр укырга.** 3 һәм 4 классларда укучылар өчен китаплар күрсәткече. М. — Л. Детиздат. 1940. 56 бит.

**Нәрсәләр укырга.** V—VII классларда укучылар өчен матур әдәбият күрсәткече. М. — Л. Детиздат. 1940. 64 бит.

**VIII—X классларда укучылар өчен матур әдәбият күрсәткече.** М. — Л. Детиздат. 1940. 124 бит.

**Старцев, И. П. Балалар әдәбияты.** Библиография. 1932—1939 еллар. М.—Л. Детиздат. 1941. 375 бит.

Библиографик күрсәткечләрдән тыш журнал һәм газеталарда чыккан библиографиядән — рецензияләрдән, китап күзәтүләреннән, яңа китаплар исемлекләреннән, тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләреннән файдаланырга кирәк.

„Правда“, „Известия“, „Комсомольская правда“, „Литературная газета“, „Труд“, „Учительская газета“ кебек газеталарда басылган рецензияләрне һәм әдәбият исемлекләрен кисеп алып папкаларга җыя барырга кирәк.

Ниһаять, өлкә (край, республика) көтепханәсе тарафыннан төзелеп, массовый көтепханәләргә җибәрелә торган барлык библиографик материалларны аерым папкага җыя барырга кирәк.

## § 4. КӨТЕПХАНӘНЕҢ БЕЛЕШМӘ ЭШЕНЕҢ ФОРМАЛАРЫ ҺӘМ МЕТОДЛАРЫ

Абонементта китап алыштырганда укучы белән сөйләшкәндә, көтепханә эшчесе укучыга уку мәсьәләләре буенча телдән белешмәләр бирә. Шул уңайда көтепханә эшчесе укучыны китап турында белешмә алырга мөмкинлек бирә торган материаллар белән таныштыра, бу материаллардан ничек файдаланырга икәнлеген күрсәтеп бирә.

Әгәр дә укучы үзенә кирәкле китапны каталоглар буенча эзләп табуда авырсынса, көтепханә эшчесе аңа бу китапларны каталогтан табуда ярдәм итә.

Әгәр дә уку залына килгән кеше көтепханә эшчесеннән нинди дә булса бер аңлашылмаган сүзне яки китапта очраган аңлашылмый торган урынны аңлатып бирүен сорый икән, көтепханә эшчесе белешмә китапларына мөрәҗәгать итә һәм белешмә бирә, бер уңайдан укучыга белешмә китапларыннан, сүзлекләрдән, энциклопедияләрдән ничек файдаланырга кирәклеген күрсәтеп бирә.

Телдән белешмә бирү эшенең иң гади формалары менә шулар.

Б и б л и о г р а ф и к к ү з ә т ү л ә р, ягъни китаплар турында укучылар белән беседалар үткәрү эшенең катлаулырак формасы булып саналалар. Библиографик күзәтүләр уку залында, уку өендә, кыр станнарында, тулай тораклардa, госпитальләрдә, предприятиеләрдә үткәрелә.

Библиографик күзәтү өчен бик күп тәкъдим ителә торган һәм бер темага берләштерелгән берничә китап сайлап алына. Күзәтү чама белән түбәндәгечә төзелә: башта күзәтү темасына характеристика бирелә, бу тема буенча әдәбиятны өйрәнүнең нинди әһәмияте барлыгы күрсәтелә, аннары тикшерелә торган тема буенча тулаем әдәбиятка кыскача характеристика бирелә һәм, ниһаять, аерым китапларга характеристика бирелә. Көтепханә эшчесе укучыларны китапларның эчтәлеге белән таныштыра, аларның кайсы яктан кызыклы булу-

ларын күрсәтеп бирергә тырыша, китапларның үзләрен күрсәтә, бик ачык һәм кызыклы өземтәләрен укый. Библиографик күзәтү гадәттә укучыларга китаплар бирү белән һәм моңа кадәр көтепханәдә укучы булып тормаган кешеләрне көтепханәгә язу белән тәмамлана. Библиографик күзәтүләрнең тематикасы чама белән түбәндәгечә булырга мөмкин: „Иптәш Сталинның „Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында“гы китабын өйрәнүгә ярдәмче әдәбият“, „Бөек Ватан сугышында Кызыл Армиянең сугышчан батырлыклары“, „Ватан өчен сугышта яшьләр“, „ПВХО һәм ГСО буенча әдәбият“, „Язгы чәчүгә карата әдәбият“, „Галәмнең төзелеше турында нәрсәләр укырга“, „Җирдә тереклек килеп чыгу турында нәрсәләр укырга“, „Кешенең барлыкка килүе турында популяр әдәбият“ һ. б.

Нинди дә булса берәр теманы хәзерләгәч, көтепханә эшчесе укучыларга хезмәт күрсәтелә торган төрле пунктларда шул тема буенча әдәбият күзәтүләре үткәрә.

Производство характерындагы әдәбият күзәтүләре үткәрү өчен көтепханә инженерларны, техникларны, мастерларны, агрономнарны, бригадирларны тарта.

Әгәр дә укучының соравы практик характерда булса, документларны, гаризаларны һ. б. ш. ларны рәсмиләштерүгә караса, укучының көнкүреш ихтыяҗларына бәйле булса, ул чакта көтепханә эшчесе укучыны белешмә өстәленә җибәрә. Белешмә өстәле расписание буенча, билгеле көннәрдә һәм сәгатьләрдә эшләргә тиеш. Белешмә өстәле янында юристларның, врачларның, укытучыларның, агрономнарның, балалар учреждениеләре работникларының дежурствосы оештырыла.

Авыл хуҗалыгы эшләре чорында хезмәт ияләренә белешмәләр бирү эшен кырда, бригадаларда оештырырга кирәк.

Көтепханә алып бара торган белешмә эшенең иң массовый формасы—сорау һәм җаваплар кичәләре.

Укучыларның интересларын исәпкә алу нигезендә тема билгеләгәч (мәсәлән, „Яшелчәләрдән ничек итеп югары уңыш алуга ирешергә“, „Үзлегеңнән ничек белем алырга“ һ. б.), кичәгә бер-ике атна кала көтепханә укучылардан сораулар җыя, бу сорауларны кичәдә катнашуга тартылган белгечләргә (агрономга, укытучыга һ. б.) тапшыра.

Сорауларны абонементта көтепханә эшчесе, уку залында дежурный, күчмә көтепханә работниклары, китапларны укучыга илтеп бирүчеләр кабул итәргә тиешләр.

Булачак кичә турында халыкка афишалар һәм белдерүләр аша хәбәр ителә.

Кичә көтепханә мөдиренең кичәнең бурычлары һәм аны үткәрү тәртибе турындагы кыска гына кереш сүзе белән ачыла. Аннары мөмкин кадәр тулы итеп, аңлатулар белән, практик киңәшләр белән җаваплар бирелә.

Көтепханә сораулар һәм җаваплар кичәсен әдәбият турында пропаганда алып бару өчен файдалана: китап күргәзмәсе оештыра, кичәнең төп темалары буенча библиографик күзәтү үткәрә. Сорау һәм җавап кичәләре гадәттә бик җанлы үтә торган булалар.

Көтепханәләрдә телдән белешмәләр бирүдән тыш язма белешмәләр дә бирелә.

Язма белешмә ике кисәктән торырга мөмкин: 1) мәсьәләнең аслы буенча аңлатулардан һәм 2) библиографик күрсәтмәләрдән. Аңлатмалар дөрес һәм кыска булырга тиешләр, тагын да киңрәк аңлатма алу өчен укучыларга шул мәсьәлә буенча әдәбият күрсәтелә яки белешмә өстәле консультантларына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим ителә.

Белешмәнең библиографик өлеше—гадәттә китапларның һәм газета журнал мәкаләләренең кечкенә генә исемлегеннән гыйбарәт була.

Әдәбият укучының хәзерлегенә карап күрсәтелә.

Укучыларның сорауларын яза бару өчен көтепханәдә чама белән түбәндәге үрнәктә махсус листоклар булдырырга киңәш бирелә:

---

**Сорау листогы**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ____________
2. Белеме: башлангыч, җидееллык, урта, югары (астына сызарга). ____________
3. Сорау ____________

4. Сорауның максаты: беседага, докладка хәзерләнү, укыту заданиесен үтәү; үзлегеңнән белем алу; производство заданиесен үтәү (астына сызарга).
5. Сорау датасы.

---

Авыл көтепханәләрендә һәм күчмә көтепханәләрдә укучыларның сорауларын язу өчен түбәндәгечә сызылган дәфтәр кулланыла:

| Тәртип №№ | Сорау датасы (ае, числосы) | Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Сорау | Җавап | Җавап датасы (ае, числосы) |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | |
| | | | | | |

Район һәм шәһәр көтепханәләрендә укучылар биргән барлык сораулар түбәндәге формадагы аерым дәфтәргә теркәләләр:

| Тәртип №№ | Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Сорау темасы | Сорау кайчан бирелде | Белешмә кайчан бирелде | Белешмәне кем язды |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | |

Белешмә кулдан языла яки машинкада басыла. Белешмәнең тышкы күренеше ачык һәм төшенерлек булырга тиеш. Белешмәләр: „Укучыларга җаваплар“, яки „Көтепханә җавап бирә“ дигән заголовоклар астындагы тактага элеп куелалар.

Ике-өч атна үткәч белешмәләр алына, ләкин юкка чыгарылмыйлар, бәлки картотекада яки бирелгән белешмәләр папкасында саклананалар. Шуның белән бергә белешмәләр темалар буенча сайлап җыелалар: 1. Иж-

тимагый-политик сораулар. 2. Хәрби эш. 3. Тарих. 4. Табигать белеме. 5. Авыл хуҗалыгы. 6. Техника. 7. Әдәбият һәм сәнгать. 8. Белем алу һәм үзлегеңнән белем алу мәсьәләләре. 9. Башкалар.

Отчет чорының азагында көтепханәнең белешмә-библиография эшенә „Бирелгән белешмәләрнең учет ведомосте“нда чама белән түбәндәге формада йомгаклар ясала:

| Ел һәм ай | Белешмәләр бирелде | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Иҗтимагый-политик | Хәрби эш буенча | Тарих буенча | Табигать белеме буенча | Авыл хуҗалыгы буенча | Техника буенча | Әдәбият һәм сәнгать буенча | Белем алу һәм үзлегеңнән белем алу буенча | Башкалар |
| 1944 январь | 50 | 25 | 5 | 5 | 5 | 5 | — | 5 | — | — |

Ведомость бирелгән белешмәләрнең санын һәм тематикасын күрсәтә һәм белешмә-библиография эшен планлаштыруга ярдәм итә.

Белешмә-библиография эше абонементта эшләү белән бәйләнгән булырга тиеш. Белешмәләр бирүне сорап мөраҗәгать иткән укучыларны көтепханә эшчесе исәпкә ала, аларның укуларын җентекләп күзәтә бара, аларга үзләрен кызыксындырган мәсьәләне системалы рәвештә өйрәнүгә күчәргә ярдәм итә.

## IX БУЛЕК

## КӨТЕПХАНӘНЕҢ МАССОВЫЙ ЭШЕ

### § 1. КӨТЕПХАНӘНЕҢ МАССОВЫЙ ЭШ БУРЫЧЛАРЫ

Абонементта һәм уку залында укучылар белән алып барган индивидуаль эш өстенә көтепханәләр массовый эш алып баралар.

Көтепханәнең массовый эше большевистик агитация һәм пропаганданың гомуми бурычлары белән билгеләнә. Көтепханәләр агымдагы вакыйгалар турында, совет кешеләренең сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыклары турында халык арасында системалы рәвештә политик информация үткәрергә, партия һәм хөкүмәт карарларын аңлатырга, марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен, рус халкының героик тарихы турындагы китапларны пропагандаларга, табигать фәне буенча белемнәр алуда халыкка ярдәм итәргә, яңа кадрларга профессияләрне үзләштерүдә булышлык күрсәтергә тиешләр.

Районда үткәрелә торган һәрбер хуҗалык-политик кампания,—язгы чәчү, урып-җыю һәм дәүләткә ашлык тапшыру, заемга язылу, хәрби хезмәткәрләр семьяларына ярдәм оештыру һ. б.—чорында көтепханә массовый эш үткәрергә тиеш, ягъни тиешле әдәбиятны пропагандалау белән бу кампаниянең уңышлы башкарылуын тәэмин итүдә катнашырга тиеш. Көтепханәнең массовый эшенең үзгәлеге аның матбугат әсәрләрен—китапларны, газеталарны, журналларны, брошюраларны пропагандалау белән багланган булуында. Көтепхана алып барган массовый эшнең иң беренче нәтиҗәсе—тәкъдим ителә торган әдәбиятның укылуында булырга тиеш. Ләкин моның белән генә бетми әле,

көтепханә укучының үзенә тәкъдим ителгән китапны, газетаны яки журналны укуы белән генә канәгатьләнеп калмый, көтепханә тагын да конкретрак нәтиҗәләргә ирешергә тырыша.

Сугыш шартларында күп көтепханәләр ПВХО түгәрәкләре оештырдылар, фронт белән языштылар, илне саклау фондына акчалар җыйдылар, кыскасы укучыларны фронтка практик ярдәм күрсәтүгә оештырдылар.

Китапларны пропагандалау максаты белән көтепханә бик күп төрле чаралар—докладлар, лекцияләр, концертлар үткәрә ала, ләкин, көтепханә алып бара торган массовый эшнең бик күп таралган төп формалары булып газета витриналары, китап күргәзмәләре, көтепханә плакатлары, кычкырып укулар-беседалар үткәрү һәм әдәби кичәләр санала.

### § 2. ГАЗЕТА ВИТРИНАЛАРЫ

Газеталарда иптәш Сталинның тарихи чыгышлары, партия һәм хөкүмәт карарлары игълан ителә. Боларны һәрбер хезмәт иясе укырга тиеш.

Газеталар һәр көнне халыкка агымдагы вакыйгалар турында, халыкара хәл турында, совет кешеләренең хезмәт батырлыклары турында, фән, техника, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге соңгы яңалыклар турында хәбәр итеп, белдереп торалар.

Һәрбер массовый көтепханә газеталар белән эшләүне оештырырга тиеш.

Газеталар белән эшләүнең иң гади формасы—аларны бөтен халык танышып барсын өчен витриналарга ябыштырып яки элеп куюдан гыйбарәт.

„Газета витриналары—политик эшнең бик әһәмиятле бер чарасы. Безнең илебез хезмәт ияләре массасының политик активлыгы чагыштыргысыз югары. Халык патриотларны яңадан-яңа батырлыкларга коралландыра торган большевистик матбугатның дөрес һәм бик ачык сүзләрен белүгә омтыла. Матбугатның тулысынча һәм һәммә җирдә бөтен кешегә җиткерелүенә ирешү—җитди һәм мөһим бурыч“ („Правда“, 1943 ел, 10 апрель, „Газета витринасы“ исемле баш мәкалә).

Газета витриналары көтепханә бинасының эчендә генә түгел, бәлки тышында да: көтепханә бинасы алдында, аңа килеп керә торган урында, күчмә пунктларда да булырга тиеш.

Газета витринасы көн саен яңартыла торырга тиеш. Газеталарның яңа номерларын алу белән үк көтепханә үзе оештырган витриналардагы газеталарның иске номерларын яңалары белән алыштыра. Газета витринасының газетасыз торуына яки анда иске, саргаеп беткән газета кисәкләренең эленеп торуына һич тә юл куелырга тиеш түгел.

Газеталарны ябыштыру беренче караштта бик гади эш булып күренсә дә, ул кайбер техник кагыйдәләрне үтәүне таләп итә.

Партия Үзәк Комитетының агитация әдәбиятын тарату турында 1921 ел 22 апрель хатында менә мондый практик киңәшләр бирелгән:

„Ябыштырганда түбәндә күрсәтелгәннәрне куллануның зур әһәмияте бар: 1) халык иң күп була торган теге яки бу урынны сайлау, 2) яңгырдан һәм бозылудан сакларлык булу, 3) нормаль яктылык (кояш ягына ябыштырмау, ләкин яктылык начар төшә торган урынга ябыштырырга ярамый), 4) ябыштыруның биеклеге, 5) җилем кубарлык булмасын, 6) витриналарны пыялалау һәм магазин тәрәзәләреннән файдалану. Биредә укучыларга уңайлылык тудыру мәсьәләсенә мөмкин кадәр күбрәк игътибар бирергә кирәк“[1].

Газеталарны гадәттәгечә ябыштырганда яки элеп куйганда һәр витрина өчен ике данә кирәк. Рязань өлкәсендә агитаторлар газетаны ике яктан да укырлык итеп пыялага ябыштыра башладылар. Бу—газета витриналарының санын икеләтә арттырырга мөмкинлек бирде. Газеталарны элү өчен шулай ук газетаны ике яктан укырга мөмкинлек бирә торган ике яклы тимер чыбык рәшәткәләр дә кулланалар.

Шулай итеп, көтепханәнең беренче бурычы—газета витриналары ярдәмендә газетаны киң халык катлауларына җиткерү. Газета белән янәшә көтепханәдә географик карта яки берничә карта (СССР ның Европа өлеше картасы, Көнбатыш Европа картасы һ. б.) эләргә кирәк.

Газета мәкаләләрендә еш кына массовый укучы өчен аңлашылмый торган чит ил сүзләре очрый (мәсәлән, сателлит, тоталь, изоляционизм, дискриминация һ. б.). Газетадагы хәбәрләрнең укучыга аңлашылуын

---

[1] „Матбугат турында партия карарлары“ дигән җыентыкны кара. М. ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Политиздат. 1941. 26 бит.

җиңелэйтү өчен, газета белән беррәттән газетаның шушы номерында очрый торган чит ил сүзләре исемлеге—сүзлек эленә.

Газеталарны укыганда хезмәт ияләрендә чит илләрнең географиясенә һәм тарихына, СССР ның үткәндәге тарихына, үткән заманнардагы һәм хәзерге политик деятельләргә һ. б. ларга караган бик күп төрле сораулар туа. Газета укучыларга ярдәмгә кайбер китепханәләр газета витриналары янына тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләре, кайвакытларда белешмә характерындагы кечкенә генә плакатлар эләләр.

Гомумән, газета белән эшләү бурычларыннан берсе—өстәмә әдәбият: китаплар, газета һәм журнал мәкаләләре күрсәтүдән гыйбарәт.

Газета витриналарыннан тыш тагын газеталардан кисеп алынган материаллар элү өчен такта яки „Соңгы яңалыклар“ витринасы ясарга кирәк.

Витринаның яки газета материаллары тактасының түбәндәге даими бүлекләре булырга мөмкин: „Партия һәм хөкүмәт карарлары“, „Халыкара хәл“, „Агымдагы политика һәм халык хуҗалыгы мәсьәләләре“, „Фән һәм техника“, „Әдәбият һәм сәнгать“, „Безнең өлкәбездә“, яки „Районыбызда“ дигән җирле бүлек әлбәттә булырга тиеш. Газеталардан кисеп алынган мәкаләләр һәм хәбәрләр газета һәм журналлардан алынган рәсемнәр, карикатуралар һәм башка төрле иллюстрация материаллары белән яки шуларның зурайтып яңадан төшерелгән рәсемнәре белән тулыландырылалар.

Газеталардан кисеп алынган материаллар тактасының бер генә темага, мәсәлән: „Ватан сугышы геройлары“ яки „Табигать белеме мәсьәләләре“ яки „Чәчү кампаниясе“ кебек темаларга багышлануы мөмкин.

Мондый агитвитриналарны урындагы материаллар—шушы районда яки авылда яшәүчеләрнең хезмәт батырлыклары турындагы материаллар белән, эшчеләр һәм колхозчыларның социалистик йөкләмәләре һәм аның үтәлеше турындагы материаллар белән тулыландыру яхшы була.

Тематик витриналарга урнаштырылган материаллар—яңа мәкаләләр, хәбәрләр чыккан саен яңартыла баралар.

Газеталардан кисеп алынган материалларга өстәмә рәвештә витриналарга брошюралар, журналлар, тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре куярга киңәш би-

релә. Шулай итеп газеталардан кисеп алынган материаллар витринасы китап күргәзмәсенә якыная һәм укучыларны теге яки бу мәсьәлә белән беренче башлап таныштыру өчен генә түгел, бәлки әдәбиятны пропагандалау өчен дә хезмәт итә.

Тематик агитвитриналарны күчмә итеп ясарга һәм кыр станнарына, бригадаларга, кызыл почмакларга, колхоз клубларына күчерергә була.

Газетадан кисеп алынган материалларның яңалары белән алыштыру өчен витриналардан алынганнары юк ителмиләр, бәлки тематик папкаларга яки альбомнарга җыела баралар.

Мондый папкаларны һәм альбомнарны укучылар бик яратып карыйлар һәм алар агитаторларга, пропагандистларга һәм беседа үткәрүчеләргә зур ярдәм игәләр.

Папкаларның һәм альбомнарның тематикасы чама белән агитвитриналар тематикасы белән бертөсле булырга тиешләр.

Вологда өлкәсенең Кубеноозеры район көтепханәсе Совет Информбюросы белдерүләрен системалы рәвештә җыя барган һәм шулардан яхшы итеп формалаштырылган күп кенә альбомнар ясаган. Шул альбомнарны карап Бөек Ватан сугышының көннән-көн ничек барганын бик яхшы өйрәнергә мөмкин.

Газета витриналарына куелган материалларны укыганда укучылар үзара фикер алышалар, беседа ясарга керешәләр. Мондый хәлләрдә агитаторның, беседа үткәрүченең катнашуы, укучыларга укыган материалларын яхшырак төшенүдә ярдәм итүе бик урынлы була. Моның өчен витриналар янында агитаторларның һәм беседа үткәрүчеләрнең дежурствосы оештырыла.

Газета материалларын күргәзмә рәвештә пропагандалау, агитаторның җанлы беседасы белән кушып алып барылганда, бик нәтиҗәле була, массовый политик эшнең тагын да көчлерәк коралы булып әверелә.

## § 3. КИТАП КҮРГӘЗМӘСЕ

**Китаплар турында укучыларга каталоглар һәм тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләре ярдәмендә информация биреп тору гына җитми, китапларны күрсәтергә дә кирәк.**

Китапларны күргәзмә рәвештә пропагандалау өчен, аларның үзләрен укучыларга күрсәтү өчен көтепханәләр китап күргәзмәләре оештыралар.

Күргәзмә укучының игътибарын әдәбиятка тарта, укучыга китапларны карарга мөмкинлек бирә, аларның эчтәлеге белән тиз генә танышып алырга, кирәкле китапны күрмичә түгел, бәлки үз күзләре белән күреп, танышып сайларга мөмкинлек бирә. Китап күргәзмәсе укучыларга көтепханә аеруча тәкъдим итә торган әдәбиятны күрергә мөмкинлек бирә.

Һәр көтепханәдә яңа китапларның даими күргәзмәсе булырга тиеш.

Күргәзмә оештыру өчен витринадан файдаланыла; ул булмаганда—аркылы планкалар кагылган тактадан (фанерадан) файдаланалар.

Яңа китаплар күргәзмәдә билгеле тәртиптә, бүлекләр буенча тезеп урнаштырылалар: иҗтимагый-политик әдәбият, хәрби-оборона, производство-техника, авыл хуҗалыгы, табигать фәне, матур әдәбият, балалар әдәбияты.

Журналларны аз ала торган авыл көтепханәләрендә яңа китаплар күргәзмәсендә яңа журналлар өчен аерым бер урын бирергә мөмкин. Район һәм шәһәр көтепханәләрендә яңа журналларның даими күргәзмәсен оештырырга кирәк. Күргәзмәдә журналлар системалы тәртиптә урнаштырылалар: иҗтимагый-политик, әдәби-художестволы журналлар һ. б.

Яңа китаплар һәм журналлар күргәзмәсеннән башка, көтепханәдә тематик күргәзмәләр оештырыла.

Көтепханәнең китап күргәзмәләре совет җәмәгатьчелегенең игътибарын тарта торган яки шушы өлкә өчен, шушы район яки колхоз өчен аеруча әһәмияте булган темаларны чагылдырырга тиешләр. Хуҗалык-политик кампанияләргә карата күргәзмәләр оештырырга кирәк. Һәрбер авыл көтепханәсендә авыл хуҗалыгы әдәбияты күргәзмәсе булырга һәм бу күргәзмә авыл хуҗалыгы эшләренең барышына карап яңартыла торырга тиеш. Алдынгы көтепханәләр һәрбер данлыклы датаны, совет халкы тормышындагы һәрбер күренекле вакыйганы китап күргәзмәләре белән билгеләп үтәләр. Мәсәлән, ССР Союзының яңа Дәүләт гимнын игълан итү яңа гимнның төп идеяләрен популярлаштыручы әдәбият күргәзмәсе өчен бик шәп тема бирде.

ВКП(б) Үзәк Комитетының фәнни-агарту пропагандасы турындагы карары уңае белән, көтепханәләрдә табигать фәне әдәбияты белән эшләү җанланды, бу исә китап күргәзмәләре тематикасында да чагылды. Мәсәлән, Краснобаково район көтепханәсе 1944—45 елларда: „Җирдә тереклекнең килеп чыгуы“, „Дөньяның башланышы булганмы һәм ахыры булырмы“, „Кояш—җирдәге тереклекнең чыганагы“, „Планеталарда тереклек бармы“, „Кешенең барлыкка килүе“ дигән һ. б. темаларга китап күргәзмәләре оештырды.

Тематик китап күргәзмәсен ничек оештырырга соң?

Күргәзмәнең темасын билгеләгәч, аның кыскача планын, ягъни бүлекчәләрнең яки подтемаларның исемлеген төзергә кирәк.

Мисалга: „Фашизм—кешелекнең иң явыз дошманы“ дигән теманы алыйк.

Авыл көтепханәсендә бу темага күргәзмәне түбәндәге план буенча корырга мөмкин:

1. Фашистлар кемнәр алар?
2. Европаның оккупацияләнгән илләрендә фашистларның „яңа тәртибе“.
3. Совет халкына фашизм нәрсә белән куркыныч салган иде.
4. Фашист бандитларның ерткычлыклары.
5. Фашистлар—культураны җимерүчеләр.

Библиографик күрсәткечләр һәм тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре ярдәмендә, билгеләнгән план буенча әдәбият сайлыйбыз. Китаплар өстенә күргәзмә өчен журналлардан, газеталардан файдаланабыз.

Әдәбият сайлаганда, һәрвакыт яңа китаплар һәм мәкаләләр чыгып торганын, аларның библиографик күрсәткечкә керми калулары мөмкин булуын, шуның өчен көтепханә каталогын да һәм киштәләрдәге китапларны да карарга кирәк икәнлеген исәпкә алырга кирәк.

Китаплар, журнал һәм газета мәкаләләрен сайлау, сайлап алынган материалларны темалар буенча бүлү— китап күргәзмәсе оештырганда төп эш, ләкин моның белән генә бетми әле: теманы ачу һәм күргәзмәне формалаштыру турында да кайгыртырга кирәк.

Теманы ачу өчен күргәзмәдә лозунглар һәм цитаталар бирелә. Мәсәлән, „Фашизм—кешелекнең иң явыз дошманы“ дигән темага күргәзмә„... Дошманны бөтен җан көчең белән дошман күрергә өйрәнмичә, дошманны

җиңәргә мөмкин түгел“ (Сталин) дигән лозунг астында оештырыла.

Күргәз мәнең, исемнәре сорау төсендә язылган, бүлекчәләрендә шул сорауларга җавап бирә торган цитаталар урнаштырыла. Мәсәлән, күргәзмәнең: „Фашистлар кемнәр алар“ дигән исем астындагы беренче бүлегендә иптәш Сталинның „Бөек Октябрь социалистик революциясенең 24 еллыгы турында“гы докладыннан түбәндәге өземтәләр китерелә:

„Гитлерчылар партиясе—империалистлар партиясе ул, шуның белән бергә дөньядагы барлык империалистлар арасында иң ерткыч һәм иң юлбасар империалистлар партиясе ул“.

„Гитлерчылар партиясе — демократик ирекләрнең дошманнары партиясе, урта гасыр реакциясе партиясе һәм кара груһ погромнар партиясе“.

Китапларны һәм текстлы материалларны җыйнап бетергәч, күргәзмәне формалаштырырга керешәләр. Озынча итеп киселгән катыргы яки каты кәгазь полоскаларына ачык итеп күргәзмәнең темасын, аның бүлекләренең заголовокларын, лозунгларны язалар, аннары бу язуларны китаплар тезелгән тактага беркетәләр.

Зуррак текстлы материаллар—цитаталар, өземтәләр—уртача форматтагы китап яки брошюра зурлыгындагы аерым кәгазь кисәкләренә язылалар.

Күргәзмә матур булсын өчен китаплардан югары яки китаплар арасына портретлар, фоторәсемнәр, карикатуралар, кечкенә плакатлар һәм бүтән төрле иллюстратив материаллар урнаштыралар. Кайбер хәлләрдә китаплар янына кечкенә географик карталар, диаграммалар һ. б. куеп күргәзмәне тулыландыру урынлы була.

Бу материалларның бөтенесе күргәзмәгә зур ачыклык һәм эчтәлеклелек бирәләр, аның темасын тулы итеп күрсәтеп бирәләр.

Кайбер хәлләрдә күргәзмәне формалаштыру өчен бүтән төрле экспонатлар да кулланыла. Мәсәлән: „Дару үсемлекләрен җыегыз“ дигән күргәзмәдә җыярга тәкъдим ителә торган үсемлекләрне куярга мөмкин.

Гомумән китап күргәзмәсен һәртөрле юллар белән җанландырырга тырышырга кирәк. Ләкин аны текстлы һәм иллюстратив материаллар белән артык тутырырга ярамый, аларны чама белән генә файдаланырга кирәк,

күргәзмәдә төп урынны китаплар, брошюралар, журналлар алырлык булсын.

Көтепханә күргәзмәгә куелган китапларны, аларның эчтәлеген, нинди укучылар өчен билгеләнгәнлеген төшенеп алуда укучыга ярдәм итәргә тиеш.

Моның өчен кыскача аннотацияләр төзелә, бу аннотацияләр каталог карточкаларына язылалар һәм китапларның өстенә яки астына куелалар.

Күргәзмәдә басма аннотация карточкаларыннан файдалану бик урынлы була. Кайбер көтепханәләрдә яңа китапларның бары тик басма аннотация карточкаларыннан гына торган бюллетеньнәре эленә.

Китаплар белән янәшә яки китаплар эченә газеталардан кисеп алынган рецензияләрне һәм тәнкыйтьле мәкаләләрне, шулай ук укучыларның язып биргән фикерләрен урнаштырырга мөмкин.

Күргәзмәләрне регуляр рәвештә яңарта торырга — яңа материаллар өстәргә, искергәннәреннән арындырырга кирәк. Үзләренең әһәмиятләрен югалткан күргәзмәләрне яңалары белән, тагын да әһәмиятлерәк темалар буенча оештырылганнары белән алыштырырга кирәк.

Китап күргәзмәләренә игътибарны тарту өчен, көтепханәләр күргәзмә турында белдерүләр, газета хәбәрләре, абонементта беседалар үткәрү ярдәмендә укучыларга һәм халыкка хәбәр итәләр.

Китап күргәзмәсе тирәсендә китапларны телдән пропагандалау эшен җәелдерергә киңәш бирелә. Күргәзмә тирәсенә укучылар группасы җыелганны күреп, көтепханә эшчесе алар белән сөйләшә башлый, китапларны күрсәтә, аларның эчтәлеген кыскача гына әйтеп бирә, бер сүз белән әйткәндә, күргәзмә темасы буенча әдәбиятка кыскача библиографик күзәтү үткәрә. Күргәзмәләр янында укучы-активистларның дежурствосы оештырыла, китаплар турында беседалар үткәрү һәм аларның саклануын күзәтү аларга тапшырыла.

Күргәзмәнең максаты — китапларны пропагандалау, димәк, аның нәтиҗәсе шушы темага китаплар бирүнең артуына китерергә тиеш. Укучыларның күргәзмәгә ничек карауларын, аның белән кызыксынуларын яки кызыксынмауларын, күргәзмә темасына китапларны алуларын көн саен күзәтә барырга кирәк.

## § 4. КӨТЕПХАНӘ ПЛАКАТЫ

Яхшы китапларны укыту өчен күргәзмә агитация алып бару максаты белән көтепханәләрдә плакатлар кулланыла. Көтепханә плакаты бүтән төрле плакатлардан билгеле мәсьәлә буенча әдәбиятны күрсәтүе, тәкъдим итүе, пропагандалавы белән аерыла.

Көтепханәләр плакатларны Бөек Ватан сугышы темаларына, тарихи темаларга, мәсәлән,— Ватаныбызның героик тарихы турында (Боз өстендәге сугыш, Куликово сугышы, Полтава сугышы һ. б.), авыл хуҗалыгы темаларына („Кырчылык буенча нәрсәләр укырга", „Тутәл бакчачылыгы буенча нәрсәләр укырга", „Терлекчелек буенча нәрсәләр укырга" һ. б.), производство-техника темаларына („Слесарьга нәрсәләр укырга", „Токарьга нәрсәләр укырга", „Фрезеровщикка нәрсәләр укырга" һ. б.), хәрби-оборона темаларына („Винтовка белән эш итәргә өйрән", „ПВХО га хәзер бул", „Дошманның танкларына каршы ничек көрәшергә" һ. б.), табигать фәне темаларына („Астрономия иҗатчылары", „Табигатьнең зур һәм дәһшәтле күренешләре", „Йокы һәм төш күрү", „Һава турында алдан белдерү" һ. б.) язалар.

Плакатның темасын сайлагач, аның схемасын төзергә керешәбез. Плакатның төп бүлекләрен билгелибез, аларны исемлибез, лозунглар, цитаталар, газеталардан кисеп алынган материаллар сайлыйбыз, кирәкле күчермәләрне эшлибез, плакат схемасында аларның урыннарын билгелибез. Шул ук вакытта плакатны укучыларның нинди группасына карата чыгарылуын исәпкә алабыз. Хәзерлекләре азрак булган укучыларны ни чаклы күздә тотсак, текстлы материал шул кадәр азрак булырга, бу материал ансат һәм гади иттереп бирелергә тиеш. Киресенчә, хәзерлекле укучыларга исәп тотып төзелгән плакатта текстлы материал күләме ягыннан шактый зур булырга мөмкин.

Аннары, плакатның темасы буенча әдәбият сайлыйбыз, бу вакытта тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләреннән, күрсәткечләрдән һәм бүтән төрле библиографик ярдәмлекләрдән файдаланабыз, киштәләрдәге китапларны карыйбыз.

Әдәбият исемлеген төзегәч, без аны плакатта нинди төстә бирү мәсьәләсен хәл итәбез.

Әгәр дә без китап тышлыкларыннан файдаланырга булсак, плакат схемасында аларны урнаштыруны билгелибез.

Әгәр дә плакатта китап тышлыкларының үзләрен бирергә мөмкин булмаса, аларның рәсемен төшерергә мөмкин. Китап тышлыкларының рәсемен төшерергә мөмкинлек булмаса, плакатка аларның исемнәрен язалар, шул исемнәр астына аларның кыскача аннотацияләрен язып куялар.

Хәзерлекләре азрак булган укучыларга исәп тотылган плакатларда китапларның тышлыкларын үзләрен яки рәсемнәрен бирү яхшырак; хәзерлекләре күбрәк булган укучыларга исәп тотылган плакатларда блокнот формасында әдәбият исемлеге бирергә мөмкин.

Плакат өчен иллюстратив материаллар кирәк. Көтепханә эшчесе газеталардан, журналлардан, басма агитацион плакатлардан кисеп алынган рәсемнәр һәм фотоиллюстрацияләр ярдәмендә плакатның иллюстратив өлешен оештыра.

Материалны „Огонёк", „Крокодил", „Крестьянка", „Смена", „Пионер", „Красноармеец", „За оборону", „Техника молодежи" журналларының иске номерларыннан алырга мөмкин (ләкин моның өчен журнал бер генә данә түгел, бәлки берничә данә булуы шарт).

Мәсәлән, безнең бөек бабаларыбыз турындагы плакатлар өчен материалны „Огонёк" журналының 1942 елгы 1 нче номерыннан алырга мөмкин. Монда Александр Невский, Дмитрий Донской, Минин һәм Пожарский, Суворов, Кутузов рәсемнәре бирелгән. Рәсемнәр астында бөек рус полководецларының ватанны саклау һәм чит җирләрдән килгән илбасарларны рәхимсез рәвештә кырып бетерү турындагы сүзләре китерелгән.

Көтепханә плакатының нигезе итеп кечкенә генә басма плакатны алырга мөмкин.

Мәсәлән: „Явыз дошманга — ут!" дигән плакатны алыйк. Шуңа ату эшләре буенча чыккан китапларның тышлыкларын һәм әдәбият исемлеген өстәсәң, к ө т е п х а н ә плакаты килеп чыгар.

Һәр плакатны, шул исәптән көтепханә плакатын да, формалаштыру эше матурлыкны аера белүне, аерым элементларны оста урнаштыра белүне таләп итә.

Әгәр дә көтепханә эшчесенең үзенең художниклык сәләтләре юк икән, ул үзенә ярдәмгә укучыларны, мәсәлән, рәсем төшерү укытучысын, рәсем төшерүчеләр

түгәрәге членнарын, чертежникларны тартырга тиеш. Әгәр дә көтепханә эшчесе басма эре хәрефләр белән яза белмәсә, ул искергән басма плакатлардан хәрефләр кисеп алып, аларны көтепханә плакатына ябыштыра ала.

Плакатларны көтепханәнең күчмә эшендә — китапларны күчмә көтепханәләрдә, кызыл почмакларда, кыр станнарында пропагандалау өчен киң кулланырга мөмкин.

Абонементта һәм уку залында плакатлар булдыру кирәк, ләкин плакатларны күп тутырудан сак булырга кирәк, бөтен стеналарны плакатлар белән тутырып бетерергә ярамый. Күп кенә бертөслерәк плакатларны сайлап алып, алар ярдәмендә, мәсәлән, хәрби почмак, агротехника почмагы оештырырга була. Искергән плакатларны вакытында кубарып алырга һәм яңалары белән алыштырырга кирәк.

## § 5. КЫЧКЫРЫП УКУЛАР-БЕСЕДАЛАР

Кычкырып укулар барыннан да бигрәк хәзерлекләре азрак булган укучыларга хезмәт күрсәтү өчен кулланыла, ул аларда укуга мәхәббәт тудыра. Уку, кагыйдә буларак, беседа белән бергә алып барыла. Бу беседа тыңлаучыларга укылган материалны төшенүдә, мәкаләнең яки хикәянең эчтәлеген совет гражданнарының агымдагы бурычлары белән бәйли барырга ярдәм итә. Күп кенә хәлләрдә җитәрлек дәрәҗәдә хәзерлекле укучылар өчен дә кычкырып уку оештыру урынлы була. Мәсәлән, матур әдәбияттан зур гына яңа бер әсәр чыкты, ди. Көтепханә аны коллектив рәвештә укуны оештыра. Нинди дә булса ерактагы бер районга күп укучыларны кызыктыра торган үзәк газеталар һәм журналларның яңа номерлары килде, ди. Көтепханә укучыларның интересларын тизрәк канәгатьләндерү өчен аларга кычкырып уку оештыра. **Кычкырып укуларның-беседаларның тематикасы:** иң элек иптәш Сталинның чыгышларын, газеталардагы баш мәкаләләрне, партия һәм хөкүмәт карарларын, халыкара күзәтүләрне, очеркларны һәм газеталарда басылган башка материалларны системалы рәвештә укуны оештырырга кирәк.

Газета материалларын системалы рәвештә уку нәтиҗәсендә, укучыларда теге яки бу мәсьәлә белән киңрәк танышу теләге туа.

Укучыларның төрле мәсьәләләр белән кызыксынуларын канәгатьләндерү өчен, кечкенә брошюраларны һәм журнал мәкаләләрен укулар оештырыла.

Авыл хуҗалыгы эшләре уңае белән көтепханәләр агротехника һәм зоотехника китапларын кычкырып укуларын оештыралар. Уку өчен материал „Правда“, „Известия“, „Социалистическое земледелие“ газеталарыннан, „Колхозное производство“ журналыннан һәм „Колхозчыларга агротехника киңәшләре“ дигән плакатлардан алына. Рус халкының героик тарихы, аның бөек полководецлары турындагы әдәбиятны кычкырып укуларга тыңлаучылар бик кызыксынып карыйлар. Бу темага зур һәм бик күп төрле материаллар бар, беренче чиратта түбәндәге җыентыклардан файдаланырга мөмкин: „Родина“ („Ватан“). Рус язучыларының Ватан турында язган әсәрләренең җыентыгы. М. Госполитиздат. 1942. „Бабайлар байрагы“. Театрлар, эстрадалар һәм үзешчәнлек түгәрәкләре өчен әдәби-художестволы әсәр җыентыклары.

Фашизмга каршы агитация алып бару өчен классик әдәбияттан файдаланырга мөмкин: рус әдәбиятыннан (пруссаклар һәм пруссаклык турында Салтыков-Щедринның әйткәннәрен) һәм чит илләр әдәбиятыннан (мәсәлән, Мопассанның „Франция—Пруссия сугышы турындагы хикәяләрен“), хәзерге совет һәм чит илләр әдәбиятыннан файдаланырга мөмкин[1].

Матур әдәбиятның укучыларга көчле йогынты ясавын исәпкә алып, көтепханә эшчеләре укучыларны совет патриотизмы рухында тәрбияли торган әдәбиятны һәм фашизмга карата, гомумән, чит илбасарларга карата, империалистик сугыш уты кабызучыларга карата нәфрәт хисен уята торган әсәрләрне киң пропагандалау эшен оештыралар.

Бөек Ватан сугышы турында кычкырып укулар өчен түбәндәге җыентыкларда күп материал бар:

Бөек Ватан сугышы. Әдәби-художестволы җыентык. М. Госполитиздат. 1942. 580 бит. (Кызыл Армиянең Баш Политик Управлениесе).

---

[1] Михаил Беккерның „Фашизмга каршы агитациядә матур әдәбият“ дигән китабын кара. Казан. Татгосиздат. 1942.

Бөек Ватан сугышы турында хикәяләр һәм очерклар. Көтепханәләрдә һәм уку өйләрендә кычкырып укулар һәм беседалар өчен. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1942. 96 бит.

Ватан өчен сугышларда флот. Әдәби-художестволы җыентык. 1. М. Военмориздат. 1943. 168 бит (Хәрби Диңгез Флоты Халык Комиссариатының Баш Политик Управлениесе).

Кычкырып укулар өчен аерым язучыларның хикәя җыентыкларын файдаланырга мөмкин, мәсәлән: Алексей Толстой, Иван Сударев хикәяләре. М. Военмориздат. 1942. 56 бит („Краснофлотецның фронт көтепханәсе").

Тихонов Н. С. „Совет кешесенең сыйфатлары" (Ленинград хикәяләре). М. „Правда". 1942. 46 бит.

Соболев Леонид. Диңгез җаны. Хикәяләр. М. Гослитиздат. 1943. 416 бит.

Әдәби укулар өчен „Фронт тормышыннан" дигән сериядән „Правда" издательствосы һәм Воениздат басып чыгарган китаплар аеруча кыйммәтле материал бирәләр.

Бу сериягә Бөек Ватан сугышы турында совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре кертелгән: Шолохов, М. „Нәфрәт фәне", Толстой, А. Н. „Батыр йөрәкләр", Панферов, Ф. „Үз күзләрем белән", Симонов, К. „Рус йөрәге", „Фронт шигырьләре", Катаев, В. „Флаг", Сергеев-Ценский, С. „Хәйләкәр кыз", Курганов, О. „Ана", Горбатов, Б. „Алексей Куликов, сугышчы", „Тормыш һәм үлем турында", Гроссман, В. „Тормыш", Кожевников, В. „Март-апрель", Кривицкий, А. „Һәлак булган 28 герой турында", Лидов, П. „Таня", Шишков, В. „Горур фамилия" һ. б.

Кычкырып укулар-беседалар оештыру. Кычкырып укуларны көтепханәдә генә түгел, бәлки предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, тулай тораклар-да, агитпунктларда, уку өйләрендә, кызыл почмакларда да үткәрергә кирәк.

Кычкырып укулар (беседа белән бергә) 15 минуттан алып 45 минутка кадәр төрлечә дәвам итәләр.

Көтепханәнең массовый эше урындагы партоешма җитәкчелегендә үтәргә тиеш. Кычкырып уку-беседа үткәрүләрнең тематикасын, кычкырып укучылар билгеләүне партия оешмасы белән сөйләшеп эшләргә кирәк.

Көтепханә кычкырып укучыларга уку өчен әдәбият сайлауда, беседага хәзерләнү өчен материал эзләп табуга ярдәм итә, район парткабинеты ярдәмендә укучыларга инструктаж һәм аларның эш тәҗрибәләрен урталашуны оештыра. Кычкырып укуның уңышлы чыгуы беренче чиратта укучының хәзерлегенә бәйләнгән. Кычкырып укучы политик белемле кеше булырга, хәрби-оборона мәсьәләләрен, халыкара вакыйгаларны яхшы төшенә белергә тиеш. Моның өчен иптәш Сталинның „Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында"гы китабын тирәнтен өйрәнергә кирәк.

Кычкырып укуны хәзерләү һәм үткәрү. Һәрбер укуга-беседага җентекләп хәзерләнергә кирәк.

Иң элек укучы тыңлаучылар белән, аларның составы белән, аларның тормыш һәм эш шартлары белән танышырга тиеш: аларның укучы формулярларын карап чыгарга, укучы үзе беркетелгән бригаданың җыелышларында һәм производство киңәшмәләрендә булырга, социалистик ярыш материалларын (стена газетасын, „сугышчан листоклар"ны, социалистик ярыш тактасын) карап чыгарга тиеш.

Бер үк темага кычкырып укуны оештыру өчен (мәсәлән, совет партизаннарының немец-фашист илбасарларга каршы көрәше турында) төрле материалдан: газета хәбәрләреннән, агитацион-массовый брошюралардан, аерым хикәяләрдән, зур-зур матур әдәбият әсәрләренең (мәсәлән, Павленконың „Рус повесте", В. Василевскаяның „Салават күпере" һ. б.) өземтәләреннән файдаланырга мөмкин.

Колхозчы хатын-кызлар өчен В. Василевскаяның „В хате" дигән әсәре, О. Кургановның „Ана" исемле, яшьләр өчен—П. Лидовның „Таня"сы, Б. Горбатовның „Буйсынмас кешеләр" дигән әсәреннән (II кисәк, 8 бүлек) Настя белән Павликның очрашып сөйләшүләре аеруча әһәмиятле.

Шушы аудитория өчен яраклы хикәяне сайлагач, кычкырып укыганда төртелмичә, шома һәм матур итеп укырлык булсын өчен аны башта үзеңә ике-өч тапкыр укып чыгарга кирәк.

Укыр алдыннан тыңлаучыларга укыла торган әсәрнең төп идеясен һәм темасын аңлатырга, әгәр дә уку беренче тапкыр булмаса, элек укылган материал белән

бәйләп үтәргә киңәш бирелә. Шушы кыска гына кереш беседага да укучы алдан ук хәзерләнә. Кереш беседа күп дигәндә 3—5 минут дәвам итә, бу беседада кагылган бик әһәмиятле мәсьәләләргә укучы йомгаклау беседасында тагын тукталып үтә.

Гомумән уку өчен бирелгән вакытны исәпкә алырга кирәк, һәм хикәяне күләме ягыннан шуңа карап сайларга кирәк. Хикәяне үз-үзенә кычкырып укып, укучы шушы билгеләнгән материалны уку өчен күпме вакыт кирәк булачагын чамалап куярга тиеш.

Кайбер хикәяләрне, мәсәлән, Б. Горбатовның „Алексей Куликов, сугышчы" дигән хикәясен кычкырып бер алымда укып чыгу кыен була, шуның өчен хикәяне чама белән түбәндәгечә өч кисәккә бүләргә кирәк:

1 нче уку. 1—2 бүлекләр (2—22 бит).
2 нче уку. 3—4 бүлекләр (23—44 бит).
3 нче уку. 5—6 бүлекләр (45—56 бит).

Беседага вакыт калсын өчен, өченче укуга текст ике тапкыр кимрәк алынган.

Колхозларда кышкы кичләрдә уку өчен күләме ягыннан тагын да зуррак әсәрләрне файдаланырга мөмкин.

Чираттагы укуга билгеләнгән өземтәне ике-өч тапкыр укып чыкканнан соң, текст өстендә эшләүгә керешәләр. Текстта кыен укыла торган чит ил сүзләре, җирле әйтемнәр, тарихи кешеләрнең исемнәре, билгеле булмаган илләрнең, шәһәрләрнең, утрауларның исемнәре, тарихи вакыйгаларны искә алулар очравы мөмкин.

Соңыннан сүзлектән яки энциклопедиядән карап алу өчен һәм тыңлаучыларга мәгънәле итеп аңлата алырлык булу өчен, укучы боларның барысын да язып ала.

Күбрәк вакыт таләп итә торган аңлатуларны уку алдыннан эшләргә мөмкин; вак-төяк аңлатуларны, мәсәлән, чит ил сүзләренең һәм әйтемнәренең тәрҗемәләрен укыганда аңлата барырга була.

Сайланган материалны өйрәнгәннән соң укылган материал буенча тыңлаучыларда нинди сораулар туу мөмкинлеген уйлап куярга һәм шул сораулар буенча беседалар үткәрергә хәзерләнергә кирәк.

Беседаның бурычы—тыңлаучыларга укылган материалны төшенергә, аның төп эчтәлеген, аның җитәкче

идеясен аңларга, әгәр дә укылган әсәр матур әдәбият әсәре булса, аның художество өстенлекләренә бәя бирергә ярдәм итәргә тиеш, укылган материалны агымдагы вакыйгалар, урындагы бурычлар белән бәйләргә ярдәм итәргә тиеш.

Беседаның планын сызгач, укучы материал сайлый— өйрәнү өчен һәм тыңлаучыларга тәкъдим итү өчен газета хәбәрләрен, урындагы тормыш фактларын, беседа темасы буенча әдәбият хәзерли.

Тыңлаучыларга укылган хикәянең төп идеясен аңлаткач, аны урындагы тормыш фактлары белән ныгыткач, беседа үткәрүче укылган материалның эчтәлеген тыңлаучыларның агымдагы бурычлары, көндәлек эшләре белән бәйләргә тырыша.

Беседа үткәрүче тыңлаучыларга, стахановча эшләүнең әһәмияте турында сөйли, иң яхшы стахановчыларның исемнәрен әйтә. Матур хикәяне яки газета хәбәрләрен уку нәтиҗәсендә көрәшкә һәм эшкә карата тыңлаучыларда туган дәртне кыенлыкларны җиңеп үтүгә юнәлдерергә, хезмәт энтузиазмына әйләндерергә кирәк.

Укуга-беседага хәзерләнүнең йомгагында тыңлаучыларга өләшү өчен әдәбият сайларга кирәк.

Беседа уку беткәч үк башлана. Укучы укылган материал буенча тыңлаучыларда нинди дә булса сорау юкмы икәнлеген сорый, тыңлаучылар биргән һәр сорау буенча бик мәгънәле, аңлаешлы аңлатма бирергә кирәк. Әгәр дә берәр сорау укучы өчен кӧтелмәгән һәм җавап бирү өчен кыен булып чыкса, укучы бу турыда ачык итеп әйтергә тиеш һәм ул сорауга җавапны хәзерләнгәннән соң тыңлаучылар белән икенче очрашу вакытында бирергә тиеш. Моның өчен ул баштa парткабинетка килеп консультация алырга һәм тиешле әдәбиятны укып чыгарга тиеш булыр.

Тыңлаучылар бернинди сорау бирмәгән һәм укылган материал турында үз фикерләрен әйтеп бирергә батырчылык итә алмаган чаклар да булгалый. Андый хәлләрдә укучы үзе сораулар бирә: тыңлаучылар укылган материалны аңлаганнармы? Нәрсәләр аңлашылмый калган? Тыңлаучыларның көндәлек эшенә укылган материалның бәйләнеше бармы? Акрынлап, күп кенә „юнәлдергеч“ сораулар биреп, укучы тыңлаучыларны укылган материалны тикшерүгә тарта. Уку нәтиҗәсендә тыңлаучыларның укылган темага бәйләнгән мәсьәлә-

ләр белән кызыксынулары мөмкин. Бу мәсьәләләрне өйрәнү өчен укучы өстәмә әдәбият тәкъдим итә.

Кычкырып уку үткәрелә торган бинада китап күргәзмәсе оештыру яхшы була. Уку вакытында тыңлаучылар алган белемнәрне ныгыту һәм тирәнәйтү өчен докладлар куярга яки лекцияләр үткәрергә мөмкин.

## § 6. ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР ҺӘМ УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

Китапларны пропагандалау буенча иң массовый чаралар—әдәби кичәләр һәм укучылар конференцияләре. Алар бер үк вакытта уннарча һәм йөзләрчә укучыларга хезмәт күрсәтергә мөмкинлек бирәләр. Әдәби кичәләр һәм укучылар конференцияләре шуның белән бергә көтепханә алып бара торган массовый эшнең иң җанлы, эчтәлекле, нәтиҗәле формасы булып торалар, укучыларны язучының иҗаты белән яки аерым әдәби әсәрләр белән тирәнтен һәм һәрьяклап таныштырырга мөмкинлек бирәләр.

Әдәби кичәләр. Эчтәлекләре буенча әдәби кичәләр бик төрле булалар:

1. Бер язучының (мәсәлән, Пушкинның, Гогольнең, Лермонтовның, Горькийның, Маяковскийның һ. б.) иҗатына багышланган кичәләр.

2. Бер әсәргә багышланган кичәләр (мәсәлән, Л. Толстойның—„Сугыш һәм солых“ы, М. Горькийның—„Ана“, Н. Островскийның—„Корыч ничек чыныкты“, Б. Горбатовның „Буйсынмас кешеләр“, М. Шолоховның „Алар Ватан өчен сугыштылар“ дигән әсәрләре һ. б.).

3. Тематикалары ягыннан бер-берсенә якын булган күп кенә әсәрләргә багышланган кичәләр (тематик әдәби кичәләр), мәсәлән: „Рус классик әдәбиятында патриотизм идеясе“, „СССР халыклары поэзиясендә Ленин һәм Сталин“, „Бөек Ватан сугышының матур әдәбиятта сурәтләнүе“, „Матур әдәбият рус халкының героик тарихы турында“.

Һәрбер әдәби кичәнең нигезе—доклад. Кичәне җанландыру өчен һәм язучының иҗатын яхшырак күрсәтү өчен доклад художестволы уку белән һәм музыкаль номерлар белән тулыландырыла.

Бөек рус композиторларының иҗатында: Глинканың, Даргомыжскийның, Чайковскийның, Римский-Корсаковның, Мусоргскийның һәм башкаларның операларында һәм романсларында чагылган рус классик әдәбияты әдәби-музыкаль кичәләр өчен кызыклы һәм бик бай материал бирә.

Хәзерге заман темаларына үткәрелә торган әдәби кичәләр программасына совет шагыйрьләренең (Лебедев-Кумачның, Исаковскийның, Сурковның, Алымовның һ. б.) композиторлардан Дунаевский, Александров, Захаров, Хачатурян һәм башкалар тарафыннан музыкага салынган җырларны, совет операларыннан—мәсәлән, Держинскийның „Тын Дон“ыннан арияләрне, Шостакович, Прокофьев, Шапорин, Мясковский һ. б. әсәрләреннән өзекләр кертергә мөмкин.

Шулай итеп, әдәби кичәнең программасы ике төп өлештән төзелә: 1) доклад һәм 2) художество бүлеге. Әдәби кичәне оештыру аның программасын эшләүдән башлана; хәзерлек эшенең планы программага карап билгеләнә.

Көтепханә кичәдә катнашуга тартырга мөмкин булган оешмалар белән сөйләшә, докладчы чакыра һәм художестволы бүлеген башкаручыларны чакыра, әгәр дә үзенең яраклы бинасы булмаса, бина эзли, булачак кичә турында халыкка белдерә (кичә турында белдерүләр элә, чакыру билетлары җибәрә яки өләшә), кичәнең темасы буенча өстәмә рәвештә әдәбият сатып ала, көтепханәләр арасындагы абонемент буенча әдәбият соратып ала.

Район һәм авыл көтепханәләре профессиональ музыкантларны, җырчыларны, артистларны чакыруга исәп тота алмыйлар; мондый көтепханә шартларында урындагы көчләрдән—драма, музыка, хор түгәрәкләрендә катнашучылардан файдаланырга кирәк, һәм гомумән кичәнең художество бүлеген көтепханә укучыларының үзешчәнлеге нигезендә оештырырга кирәк. Докладчы булып әдәбият укытучысы чыгыш ясарга мөмкин. Кичәне хәзерләүне абонемент эше белән, көтепханәнең барлык массовый эше белән бәйләргә кирәк, укучыларның игътибарын кичәнең темасына тартырга, аларны кичәне үткәрүдә актив катнашуга хәзерләргә кирәк.

Абонементта, уку залында, күчмә көтепханәләрдә китаплар биргәндә кичәнең темасы буенча әдәбият

тәкъдим итү һәм укучыларның фикерләрен туплау үткәрелә. Әдәбиятны күргәзмә рәвештә пропагандалауның бөтен формаларыннан—китап күргәзмәләреннән, көтепханә плакатларыннан файдаланыла. Кичә нинди авторга багышланса шул авторның әсәрләрен яки кичәнең темасына бәйле булган әсәрләрнең өзекләрен киң күләмдә кычкырып укулар үткәрелә. Урындагы радиоузел белән сөйләшеп, әдәби кичә турында информация белән һәм кичәнең темасына карата художестволы укулар белән радиотапшырулар оештырыла.

Әдәби кичә үткәрелә торган бинада кичәнең темасына карата китап күргәзмәсе оештырыла.

Кичәне яхшы итеп хәзерләү укучылар массасы арасында аның белән кызыксыну тудырачак, укучыларның күп булып килүләрен һәм кичәдә аларның актив катнашуын тәэмин итәчәк.

Кичә гадәттә аның әһәмияте һәм бурычлары турында көтепханә эшчесенең кыскача гына кереш сүзе белән башлана.

Аннары сүз докладчыга бирелә. Докладка 25—30 минут чамасы вакыт бирелә. Доклад нинди язучының иҗатына багышланса доклад барышында аны бүлеп торып, шул язучының әсәрләреннән аерым өзекләрне матур итеп уку үткәрелү мөмкин. Доклатан соң тыңлаучыларның сораулар бирүләре мөмкин. Докладчы ул сорауларга җаваплар, өстәмә аңлатмалар бирә. Аннары, тәнәфестән соң, художество бүлеге башлана.

Художество бүлеге беткәннән соң көтепханә эшчесенә сүз бирелә. Ул—көтепханәгә язылырга теләүчеләргә шунда ук язылырга мөмкинлеге һәм кичәнең темасы буенча үзләрен кызыктырган китапларны алырга мөмкин икәнлеге турында белдерә.

Укучылар конференцияләре. Китапларны тикшерүгә багышланган кичәләр, укучыларның әдәбитәнкыйть конференцияләре дип атала һәм әдәби кичәләрнең аерым төрен тәшкил итәләр.

Бу кичәләрдә кереш докладтан соң сүз укучыларга бирелә. Тикшерелә торган китап буенча укучыларның чыгышлары конференциянең төп эчтәлеген тәшкил итәдә. Тикшерү өчен әле күптән түгел генә чыккан, художество ягыннан һәм политик яктан зур әһәмияте булган яңа әсәрләрне алу яхшырак.

Әдәби-тәнкыйть конференциясенең бурычы—укучыларның игътибарын актуаль художестволы әсәрләргә

тарту, укучыларда китап өстендә үзлекләреннән эшләү күнекмәләрен үстерүгә булышлык итү.

Укучылар конференциясенә хәзерләнгәндә кичәдә сөйләячәк укучылар белән эшләүгә, укучыларның чыгышларын хәзерләүгә аеруча игътибар бирелергә тиеш.

Иң элек, укучы формулярлары буенча матур әдәбият белән кемнәрнең бигрәк тә кызыксынуын белеп алырга, аларның һәрберсе белән сөйләшергә һәм конференциядә чыгыш ясарга тәкъдим итәргә кирәк. Укучы чыгыш ясарга ризалык бирсә, аны кирәкле әдәбият белән һәм консультация ярдәме белән тәэмин итәргә кирәк.

Әдәби-художестволы кичәдән үзгә буларак, бу конференциядә протокол язып, укучыларның сөйләгән сүзләре җентекләп язып алына. Укучыларның чыгышларыннан соң художество бүлеге бирергә мөмкин.

Укучылар конференциясенең матур әдәбият әсәрләренә генә түгел, бәлки фәнни китапларга да—иҗтимагый-политик, авыл хуҗалыгы һ. б. китапларга да багышлануы мөмкин. Авыл хуҗалыгы әдәбиятына багышланган укучылар конференцияләрен Киров өлкәсенең Белохолуниц район көтепханәсе бик кызыклы итеп үткәргән. Башта көтепханә район җир бүлеге белән сөйләшкән, ул көтепханәгә ярдәмгә участок агрономнарын биргән. Бер колхозда конференция Ладыгинның „Бөртекле культуралардан югары уңыш алу агротехникасы“ дигән китабына, ә икенчесендә—Мелешкевич һ. б. ның „Житен игүче стахановчыларның агротехникасы“ дигән китабына багышланган, һәм барлык колхозларда—аларның производство характерына ятышлы рәвештә эш алып барылган.

Агрономнар китапларга карата сораулар язганнар. Район көтепханәсе мөдире һәм агроном һәрбер колхозга барганнар. Алар башта колхоз правлениесе членнарын конференциянең бурычлары белән таныштырганнар һәм аны үткәрү планын төзегәннәр. Аннары правление конференцияне үткәрү буенча комиссия билгеләгән һәм аңа хәзерләнү мәсьәләсе колхозчыларның гомуми җыелышына куелган. Колхоз күп санда китап белән тәэмин ителгән. Укучылардан докладчылар сайлап алынган, һәркемгә күренә торган урыннарга сорауларның исемлеге эленгән.

Шуның өстенә һәр бригадада китапны кычкырып укучылар билгеләнгән һәм конференциядә чыгыш ясарга хәзерләнүче укучылар өчен агрономның консультация бирү көннәре билгеләнгән. Шулай җитди хәзерләнү нәтиҗәсендә колхозлардагы конференцияләр бик уңышлы үткәннәр һәм производство өчен яхшы нәтиҗә биргәннәр.

## § 7. КӨТЕПХАНӘНЕҢ ҮЗЕН ПРОПАГАНДАЛАУ ҺӘМ ЯҢА УКУЧЫЛАР ТАРТУ

Һәрбер массовый көтепханә мөмкин кадәр күбрәк укучылар тартырга тиеш. Көтепханә фонды ничаклы яхшырак тупланган булса, укучыларның сораулары ничаклы тулырак канәгатьләндерелсә, көтепханәгә хезмәт итүләре шул чаклы күбрәк язылалар. Ләкин, укучыларга хезмәт күрсәтүне яхшы итеп оештыру өстенә тагын аларны көтепханәгә тарту өчен көтепханәнең үзен пропагандалау буенча күп кенә өстәмә чаралар күрү кирәк.

Иң элек көтепханә бинасының вывескасы булырга тиеш, көтепханәгә килеп керә торган урында—аның эшләү көннәре һәм сәгатьләре турында белдерү элеп куелырга тиеш, шулай ук көтепханә китапларыннан файдалану кагыйдәләре элеп куелса тагын да яхшырак. Көтепханә турында халыкка киң белдерү өчен, төрле җәмәгать урыннарында—район башкарма комитетында яки авыл советында, колхоз правлениесендә, район культура йортында, колхоз клубында, уку өендә—чама белән түбәндәге эчтәлекле белдерүләр яки плакатлар эленә:

*Көтепханәгә язылыгыз!*

Көтепханә . . . . . . . . . . . . . дә урнашкан.

Көтепханә . . . . . . . . . . . . . башка һәр көнне сәгать . . . нан сәгать . . . га кадәр ачык.

Көтепханә китапларыннан файдалану түләүсез.

Көтепханә төрле яңа журналлар һәм газеталар ала.

Көтепханә зурларга да, балаларга да хезмәт күрсәтә.

Яңа китаплар турында, массовый чаралар турында халыкка белдерү өчен, көтепханә район газетасында, предприятиеләрнең һәм совхозларның күп тиражлы газеталарында, авыл советы һәм колхозларның стена газеталарында, бригадаларның „сугышчан листоклар“ ында хәбәрләр урнаштыра. Кайбер көтепханәләр районның җитәкче работникларына, эшчеләргә, колхозчыларга, урындагы интеллигенциягә көтепханәгә язылырга һәм аның эшендә ярдәм итәргә чакырып хатлар җибәрәләр. Көтепханә эшчеләре эшчеләрнең яки колхозчыларның гомуми җыелышларында көтепханә турында, ул алган яңа китаплар турында, аның массовый чаралары турында белдерүләр белән чыгышлар ясыйлар.

Көтепханәнең иң яхшы пропагандистлары — аңа йөрүче актив укучылар. Укыган китаплары турында сөйләп, алар тыңлаучыларда көтепханәгә язылып бу китаплар белән үзләре танышу теләген тудыралар.

Көтепханәнең массовый чаралары — докладлар, лекцияләр, әдәби кичәләр, кычкырып укулар һәм беседалар — көтепханә тарафыннан яңа укучылар тарту өчен файдаланыла алалар һәм файдаланылырга тиешләр. Шушы чараларны үткәргәннән соң гадәттә көтепханәләр яңа укучыларны тарталар. Кайвакытларда шунда ук аларга доклад, әдәби кичә темасы буенча әдәбият та бирәләр.

Күчмә көтепханәләр китапларны укучыларга илтеп бирүне оештыру һәм укучылар тартуда бик яхшы чара булып исәпләнә. Көтепханә хезмәт иярәренең үзләре көтепханәгә килеп укучы булып язылганнарын көтеп кенә тормый, ул алар алдына үзе барырга, эшләгән җирләрендә яки өйләрендә аларны китаплар белән тәэмин итү эшен оештырырга тиеш. Күчмә көтепханәләр һәм китапларны илтеп бирү ярдәмендә укучылар санын шактый арттырырга була. Әгәр дә китапларны укучыларга илтеп бирү эше кычкырып китап уку һәм беседа үткәрү чаралары белән бәйләп алып барылса бигрәк тә яхшы нәтиҗә бирә.

Гомумән көтепханә тарафыннан алып барыла торган китап пропагандасы бер үк вакытта көтепханәнең үзен пропагандалау да инде ул. Көтепханә китаплар турында телдән һәм күргәзмә рәвештә пропаганданы ничаклы киң җәелдерсә — халык арасында көтепханәнең авторитеты да шул чаклы зур, аның укучылары да шул чаклы күп була.

Барлык массовый эшләрне көтепханә исәпкә алып барырга тиеш, моның өчен чама белән түбәндәге формадагы көндәлек дәфтәрдән файдаланырга мөмкин:

**Зурлар өчен көтепханәнең көндәлек дәфтәре**

в) Массовый эшләрне исәпкә алу

| 3. Массовый эшне исәпкә алу (кычкырып укулар, докладлар, әдәби кичәләр, китап күргәзмәләре, тәкъдим ителгән әдәбият исемлекләре һ. б. ш.). | | | |
|---|---|---|---|
| Дата | Үткәрелгән эшләрнең темасы һәм исеме | Хезмәт күрсәтелгән кешеләр саны | Үткәрелгән эш турында көтепханә эшчесенең билгесе (кем үткәргән, кайда, катнашучыларның активлыгы, бәя, һ. б. ш.) |
| 23/IV— | „Беренче май“ — китап күргәзмәсе | | 18 китап куелды. Активист В. Осипчук формалаштырды |
| 5/IV— | Ленин исемендәге колхозда кычкырып уку. Толстой А. „Рус характеры“ | 28 кеше | Н. Архипова үткәрде, беседада 10 кеше катнашты |
| 28/IV— | Беренче майга багышланган әдәби кичә. | 29 кеше | Лектор А. Костин. Шигырьләрне к-нә активистлары (6 кеше) һәм драма театры артисткасы Б. В. Нагорская укыдылар. Кичә уңышлы үтте. |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

## *X БУЛЕК*

## КӨТЕПХАНӘНЕҢ КҮЧМӘ ЭШЕ ҺӘМ КИТАПЛАРНЫ УКУЧЫЛАРГА ИЛТЕП БИРҮ

### § 1. КӨТЕПХАНӘНЕҢ КҮЧМӘ ЭШЕН ОЕШТЫРУ

Күчмә эш үткәргәндә иң элек төп көтепханәдән күчмә көтепханәләргә бирелә торган китапларның саклануын тәэмин итәргә кирәк. Моның өчен төп көтепханә күчмә көтепханә ала торган оешма белән договор төзи. Договор буенча көтепханә билгеле сандагы китаплар белән күчмә көтепханә бирүне, укылган китапларны системалы рәвештә алыштырып торуны һәм күчмә көтепханәдә эшләүчегә системалы рәвештә инструктаж бирүне үз өстенә ала.

Күчмә көтепханә алучы оешма китапларның саклануы һәм бөтенлеге өчен җаваплылыкны, китаплар югалса яки бозылса төп көтепханәгә шундый ук китапларны кайтарып бирүне, ә кайтарып бирү мөмкин булмаган хәлләрдә — алар урынына яңа китап сатып алырлык итеп бәясен түләүне үз өстенә ала. Күчмә көтепханә алучы оешма шулай ук күчмә көтепханәнең эше өчен нормаль шартлар тәэмин итүне: 1) күчмә көтепханәгә бина һәм җиһазлар бирүне (китаплар саклау өчен шкаф, өстәл, китап күргәзмәләре өчен витрина, берничә урындык яки скамейка һ. б.); 2) күчмә көтепханәдә эшләү өчем җәмәгать йөкләмәсе тәртибендә бер кеше бирүне, аңа китапларны регуляр рәвештә алмашып торуны һәм, чама белән, аена бер тапкыр инструктив киңәшмәләрдә катнашуны тәэмин итүне өстенә ала; 3) күчмә көтепханәдә эшләүченең эшен тикшерүне, аның отчетларын тыңлауны, аның төп көтепханәгә отчетлар бирүен күзәтүне; 4) күчмә көтепханә эшчесенә массовый эшләр үткәрүдә ярдәм итүне; 5) күчмә көтепханә эшчесе алышынса — китапларның тапшырылуын һәм кабул итеп алынуын акт белән формалаштыруны, күчмә көтепханәгә яңа эшче билгеләнү турында төп көтепханәгә белдерүне һәм күчмә көтепханәнең икенче кешегә тапшырылуы турындагы актның күчермәсен тапшыруны өстенә ала.

Күчмә көтепханә договор төзелгәннән соң гына, шулай ук бина барлыгын һәм китапларны саклау өчен махсус җиһазлар барлыгын тикшергәннән соң гына бирелә. Күчмә көтепханәдә җәмәгать йөкләве буенча эшләүче кеше китапларның саклануын һәм аларның укучылар тарафыннан вакытында кайтарылуын күзәтергә, эшнең учетын алып барырга, төп көтепханәгә эш турында мәгълүматлар бирергә, төп көтепханәдә китапларны регуляр рәвештә алыштырып торырга, инструктив киңәшмәләрдә катнашырга һәм көтепханә эше буенча үзенең квалификациясен күтәрергә тиеш.

Төп көтепханә күчмә көтепханә эшчеләренең еш алыштырылмавына һәм күчмә көтепханә эшчесе итеп җитәрлек дәрәҗәдә хәзерлеге булган, китапны ярата торган, көтепханә эше белән кызыксына торган кешенең билгеләнүенә ирешүгә тырышырга тиеш.

Төп көтепханә күчмә көтепханә эшчеләренә инструктаж бирүне оештыра, аларның һәрберсен эш техникасы белән, көтепханәдән алына торган китапларның учетын алу тәртибе белән, укучыларга бирелә торган китапларны язу кагыйдәләре белән һәм отчет эшен алып бару белән таныштыра. Һәрбер күчмә көтепханәне аның эше турында кыскача инструкция белән тәэмин итәргә кирәк, учет һәм отчет формалары белән, методик материаллар белән, тәкъдим ителә торган китапларның исемлекләре белән тәэмин итәргә кирәк. Күчмә көтепханә эшчесе төп көтепханәгә килгән чакларда аның белән эшләренең барышы турында, укучыларның нинди китапларны сораулары турында, күчмә көтепханәгә бирелә торган китаплар турында, укучыларга хезмәт күрсәтү методлары турында, якын арада үткәрү өчен массовый чаралар турында сөйләшергә кирәк. Күчмә көтепханә эшчесе белән бергәләп, күчмә көтепханәнең бер-ике айлык эш планын төзергә киңәш бирелә.

Күчмә көтепханә эшчеләренең квалификациясен күтәрү өчен, чама белән аена бер тапкыр инструктив-методик киңәшмәләр үткәрергә кирәк, ул киңәшмәләрдә күчмә көтепханә эшчеләренең эше турында аларның отчетларын тыңларга, агымдагы хуҗалык-политик бурычлар (язгы чәчү, игеннәрне урып-җыю, дәүләткә ашлык тапшыру, һ. б.) уңае белән массовый эшләр алып бару турында аларга күрсәтмәләр бирергә, әдәбиятка библиографик күзәтүләр үткәрергә, көтепханә методикасы темаларына докладлар куярга кирәк. Район

көтепханәсе күчмә көтепханәләрдә эшләүчеләрнең ике-өч көнлек семинарын оештыра ала. Бу семинарларда чама белән ике занятие иҗтимагый-политик мәсьәләләргә, ике-өч занятие — әдәбиятның төп төрләрен (иҗтимагый-политик, табигать фәне, матур әдәбият һ. б ) өйрәнүгә һәм ике-өч занятие көтепханә эшен оештыру, аның техникасы һәм методикасы мәсьәләләренә багышлана.

Киңәшмәләрдә һәм занятиеләрдә җыелган кешеләрне яңа китаплар белән, күчмә көтепханәдә яхшы эшләүчеләрнең тәҗрибәсе белән таныштырырга кирәк, күчмә көтепханәләрдә эшләүчеләрне социалистик ярышка тартырга, күчмә көтепханә эшчеләренең социалистик йөкләмәләрен формалаштырырга кирәк. Һәртөрле юллар белән күчмә көтепханә эшчеләрендә китаплар белән, көтепханә эше белән, массовый эш белән кызыксынуны уятырга, китапларны массаларга җиткерү эшендә көтепханәнең иң якын ярдәмчеләре булган күчмә көтепханәдә җәмәгать йөкләмәсе буенча эшләүчеләрнең азмы-күпме даими кадрларын булдырырга кирәк.

Төп көтепханә работниклары күчмә көтепханә эшчеләренә мөмкин кадәр аларның эшли торган урыннарында инструктаж бирәләр, күчмә көтепханәләрнең торышын тикшерәләр, күчмә көтепханә эшчеләренә организацион мәсьәләләрне хәл итүдә, учет һәм отчет эшен тәртипкә салуда, массовый эшләр үткәрүдә, абонементта укучыларга аерым хезмәт күрсәтүдә ярдәм итәләр.

Төп көтепханәдә „күчмә көтепханәче почмагы“ оештырырга киңәш бирелә. Бу почмакта методик һәм библиографик материаллар җыйнала, үрнәк китап күргәзмәләре оештырыла, махсус тактага күчмә көтепханәчеләрнең социалистик йөкләмәләре, шулай ук көтепханә плакатлары, лозунглар, тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләре эленә. Аерым киштәгә яки витринага көтепханә ярдәмлекләре, күчмә көтепханәчеләргә уку өчен һәм укучылар арасында пропагандалау өчен тәкъдим ителгән төп агымдагы әдәбият җыйнап куела.

## § 2. КӨТЕПХАНӘНЕҢ КҮЧМӘ ЭШ ТЕХНИКАСЫ ҺӘМ АНЫ УЧЕТКА АЛУ

Төп көтепханә күчмә көтепханәләргә бирелгән китапларның учетын алып бара һәм күчмә көтепханәләрнең эше турындагы мәгълүматларны җыя һәм гомумиләштерә.

Күчмә көтепханә турындагы һәм төп көтепханәдән аңа бирелгән китаплар турындагы мәгълүматларны яза бару өчен **күчмә көтепханә формуляры** була.

Формуляр ике данәдә языла, аларның берсе төп көтепханәдә кала, икенчесе күчмә көтепханәгә бирелә.

Формулярның беренче битенә күчмә көтепханә турында кыскача мәгълүматлар языла, соңгы битенә — аның квартал эчендә эшләгән эшләре турында (күчмә көтепханәче тапшырган квартал отчетлары нигезендә) кыскача мәгълүматлар языла. Формулярның бүтән битләре күчмә көтепханәгә бирелгән, күчмә көтепханә тарафыннан кайтарылган һәм анда калган китапларның саны турындагы мәгълүматлар белән тутырылалар. Китапларны һәр алыштырганнан соң формулярның төп көтепханәдә кала торган данәсенә күчмә көтепханәче кул куя, ә формулярның күчмә көтепханәгә бирелә торган данәсенә төп көтепханә работнигы кул куя. Күчмә көтепханәләрнең формулярлары күчмә көтепханәләрнең номерлары тәртибендә тезелеп куелалар һәм бикле шкафта саклананалар.

Күчмә көтепханәгә бирелә торган һәр китапның эченнән аның формуляры алынып, аңа китапларны бирү датасы (вакыты) һәм күчмә көтепханәнең номеры язып куела. Бирелгән китапларның формулярлары системага салынган алфавит тәртибендә аерым ящикка салып куелалар һәм аларның өстенә күчмә көтепханәнең исеме һәм номеры язылган кәгазь салына. Бирелгән китапларның формулярлары салынган ящик бикле шкафта саклана.

Күчмә көтепханәләргә бирелгән китапларның тулаем һәм аерым учеты төп көтепханәдә менә шулай алып барыла.

Алынган китапларны күчмә көтепханәче „**күчмә көтепханә китапларын учетка алу дәфтәре**"нә язып бара.

**Күчмә көтепханә китапларын учетка алу дәфтәре**

| Ай һәм число | Инвентарь № | Автор һәм китапның исеме | Китапның кайтарылуы турында төп көтепханә билгесе |
|---|---|---|---|
| | | | |

**Күчмә көтепханәнең укучылар дәфтәре**

(в) 1 нче бит

№ 6

Фамилия: Гурина

Исеме һәм атасының исеме: Клавдия Семеновна

Занятиесе: сыер савучы

Астына сызарга:

Яше: (16 га кадәр; 16—23 яшьтә; 23 тән югары

Социаль хәле: эшче, колхозчы, хезмәткәр, укучы, башкалар

Белеме: башлангыч; тул. булм. урта һәм урта, югары

Өй адресы: Ивановская, йорт № 7

Көтепханә кагыйдәләрен үтәүне өстемә алам:

(Имза) К. Гурина

26 март, 1945 ел.

| Бирү вакыты | Бүлек | Автор һәм бирелгән китапның исеме | Китап алу турында укучының имзасы |
|---|---|---|---|
| 26/III | 3 | Сталин. Бөек Ватан сугышы турында | К. Гурина |
| 26/III | | Островский. Корыч ничек чыныкты | К. Гурина |
| 26/III | 63 | Аликаев В. Дуңгыз балалары үстерү | К. Гурина |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

## Күчмә китапханәнең көндәлек эш дәфтәре

2 нче номерлы күчмә китапханәнең көндәлек эше
1945 елның май ае өчен

| Китапханә эшләгән ай һәм число | Барлык бирелгән китаплар | Шул исәптән: Иҗтимагый-политик әдәбият (1, 2, 3 һәм 9 бүлек) | Табигать белеме һәм математика (5) | Производ.-техн. әдәбияты (63 бүлектән башка) | Авыл хуҗалыгы әдәбияты (63) | Матур әдәбият | Балалар әдәбияты | Башка төрле әдәбият | Массовый эшнең учеты: Числосы | Кычкырып укулар, докладлар, беседалар, күргәзмәләр— темасы күрсәтеп языла | Хезмәт күрсәтелгән кешеләрнең саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.IV | 13 | 3 | — | — | 2 | 6 | 2 | — | 3 | Сөт фермасында кычкырып газета уку | 6 |
| 5.V | 9 | 1 | 1 | — | 1 | 5 | 1 | — | — | | |
| 8.V | 16 | 4 | — | — | 2 | 7 | — | 3 | 5 | Китап илтүче Короткова 6 укучыда булды, 2 укучы яңадан язылды. | |
| | | | | | | | | | 6 | Укытучы Мухановның „Берлинны алу турында“гы докладstatus. | 48 |
| | | | | | | | | | 7 | Сыер фермасында кычкырып уку | 10 |
| Барлыгы бер айда | | | | | | | | | | | |

Бер ай эчендә барлыгы ______ укучы язылды. Бер ай эчендә барлыгы ______ укучы китте.

Ай азагына ______ укучы исәпләнә.

Укучыларның саны 50 кешедән артмаган кечкенә күчмә көтепханәләрдә „Күчмә көтепханәнең укучылар дәфтәре" кулланыла. Һәр укучыга дәфтәрдән ике бит бирелә. Беренче битнең башына укучы турындагы төп мәгълүматлар языла, калган урыннары бирелгән китапларны учетка алу өчен калдырыла.

Укучыларга китаплар бирүне тәгәлләгәч, күчмә көтепханәче „күчмә көтепханә эшенең көндәлек дәфтәре"н тутыра, анда бирелгән китапларның гомуми санын язып куя һәм аларның белем тармаклары буенча бүленешен яза. Күчмә көтепханәнең массовый эшләрен учетка алу да шушы ук дәфтәрдә алып барыла.

Күчмә көтепханәче ай саен яки квартал саен төп көтепханәгә көндәлек дәфтәрләрен китерә.

Күчмә көтепханәнең эш йомгакларын төп көтепханә работнигы күчмә көтепханә формулярының 4 нче битенә язып куя. Күчмә көтепханәнең көндәлек дәфтәре формасыннан файдаланып, төп көтепханә күчмә көтепханәләрнең эше турында сводка яза. Бу вакытта көндәлек дәфтәренең беренче графасы (ай һәм число) күчмә көтепханәләрнең номерларын язар өчен хезмәт итә, ә соңгы графа (искәрмә)—укучылар санын язар өчен хезмәт итә.

Төп көтепханәгә килгәндә күчмә көтепханәче үзе белән күчмә көтепханәнең формуляры күчермәсен, күчмә көтепханәнең китапларын язу дәфтәрен, күчмә көтепханә эшенең көндәлек дәфтәрен, укучылар соравын язу дәфтәрен алып килергә тиеш. Күчмә көтепханәчеләр алышынганда китапларны тикшерү үткәрелә һәм күчмә көтепханәне тапшыру турында түбәндәге форма буенча акт языла:

## АКТ

————————(колхоз, совхоз, предприятие һ. б.) каршындагы күчмә көтепханәне тапшыру турында 194___елның ———аеның ———числосында төзелде.

Без, түбәндә кул куючылар (фамилияләрне язарга), бу актны күчмә көтепханәнең китап байлыгын тикшерү һәм аны ——————— иптәшкә тапшыру турында төзедек. Исемлек буенча тикшергәндә ——— китап көтепханәдә, ————— китап укучылар кулында, ——— сумлык ——— китап җитми булып чыкты. Җитмәүнең сәбәпләре ————————————

Җитмәгән китаплар исемлеге кушымта итеп бирелә.

Китаплардан тыш тагын ——————————әйберләр бар.

Шушы акт буенча күчмә көтепханәнең китапларын һәм башка мөлкәтен тапшырдым. (Имза.)

Кабул итеп алдым һәм күчмә көтепханәченең вазифалары белән таныштым. (Имза.)

Укучыларга тагын да киңрәк хезмәт күрсәтү өчен көтепханәләр китапларны илтеп бирүне (книгоношество) оештыралар. Колхозчылардан яки эшчеләрдән берәүгә үз колхозының (бригадасының, цехының) членнарын уку өчен китаплар белән тәэмин итү эше тапшырыла. Китап илтүче гадәттә көтепханәгә атнага бер тапкыр килә, 10—20 китап ала һәм эштән соң тулай торакта, эш урынында һ. б. аларны укучыларга өләшә.

Бер үк вакытта китап илтүче укылган китапларны җыя һәм икенче барганда аларны көтепханәгә тапшыра.

Китап илтүчегә бирелгән китапларны учетка алу эше укучыларга китап биргәндәге кебек үк эшләнә. Китап илтүче турындагы мәгълүматларны язу өчен гадәттәге укучы формулярлары файдаланыла. Бирелгән китапларның формулярлары китап илтүченең формулярлары эченә салына. Китап илтүче укучыларга бирелгән китапларны „күчмә көтепханә укучыларын язу дәфтәре“нә яза. Укучылар һәм бирелгән китаплар турындагы мәгълүматларны көтепханә работнигы китап илтүчедән ала һәм үзе күчмә көтепханә эшенең көндәлек дәфтәренә яза. Айна яки кварталга бер тапкыр бу мәгълүматларның гомуми саны исәпләнә һәм китап илтүче һәр кешенең, ә аннары барысының да эше турында статистик отчет языла.

## *XI БҮЛЕК*

## МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ ЭШ ПЛАНЫ, СМЕТАСЫ ҺӘМ ОТЧЕТЫ

### § 1. ЭШ ПЛАНЫН ТӨЗЕГӘНДӘ НӘРСӘДӘН ЧЫГЫП ЭШ ИТӘРГӘ

Үзенең эшендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен көтепханә план буенча эшләргә тиеш. План төзегәндә көтепханә иң якын чорда илебез алдында торган политик тәрбия бурычларыннан, үз районының яки авылының бурычларыннан, укучыларының сорауларыннан һәм, ниһаять, көтепханәнең үткәндәге эш тәҗрибәсеннән, үз кулында булган мөмкинлекләрдән чыгып эш итә.

Газеталар укып, җәмәгать тормышында актив катнашып, партия һәм совет оешмаларының җитәкчеләре белән сөйләшеп, көтепханә эшчесе якын вакыт өчен политик-агарту бурычларын дөрес билгели ала.

Район һәм стена газеталарының материаллары буенча, район һәм авыл учреждениеләренең, оешмаларының карарларыннан көтепханә эшчесе якындагы вакытка шушы район яки авыл алдында торган бурычларда ориентировка ала.

Укучыларның сорауларын көтепханәче иң яхшысы алар белән тыгыз бәйләнештә булу нәтиҗәсендә, китаплар биргәндә һәм массовый чаралар үткәргәндә алар белән сөйләшүләр вакытында белеп ала.

Үткәндәге эш тәҗрибәсен көтепханә эшчесе көтепханәнең үткәндәге эше турындагы материалларга анализ ясау юлы белән үзләштерә. Аерым алганда, көтепханәнең расланган форма буенча төзелгән еллык отчетын игътибар белән уйлап чыгарга кирәк (3 нче номерлы кушымтаны кара). Отчет үткән ел белән чагыштырганда укучыларның саны күпмегә үзгәргәнлеген

күбәйгәнен яки кимегәнен) белергә мөмкинлек биреп кенә калмый, бәлки шуның белән бергә аларның составы ничек үзгәргәнлекне, халыкның нинди группалары көтепханәгә йөри башлаганлыкны, китап фондының составы ничек үзгәргәнлекне, ничаклы китапның тузып фондтан чыкканлыгын, көтепханәнең күчмә эшенең киңәюен һ. б. ларны да күрсәтә.

Шулай ук көтепханәнең үткәндәге эшенең эчтәлеген, массовый чараларның тематикасын һ. б. ларны да белергә кирәк.

Китапларның әйләнеше һәм укылышы көтепханә эшенең бик әһәмиятле күрсәткече булып исәпләнәләр. Көтепханәнең үз фондын ни дәрәҗәдә файдалануын без билгеле вакыт эчендә укучыларга бирелгән китаплар санын көтепханәдә булган китаплар санына чагыштырганда гына әйтә алабыз.

Әйтик, 5 000 китабы булган бер көтепханә 10 000 китап биргән, ә 2 000 китабы булган икенче көтепханә шул ук вакыт эчендә 8 000 китап биргән. Беренче көтепханә икенчесенә караганда күбрәк китап биргән булса да, шулай да икенче көтепханәнең үз фондын беренче көтепханәгә караганда ике тапкыр яхшырак файдаланганлыгын, китапларның ике тапкыр күбрәк әйләнүенә ирешүен икърар итәргә кирәк. Китапларның күпме әйләнешен без ел буена бирелгән китапларның санын көтепханәдә булган китапларның гомуми санына бүлеп таба алабыз. Китапларның әйләнеше беренче көтепханәдә икегә, ә икенчесендә—дүрткә тигез була. Чираттагы эш планын төзегәндә китапларның әйләнешен арттыра алырлык чаралар билгеләргә кирәк. Китапларның әйләнешен арттыруның шарты—көтепханәдә яхшы әдәбият булдырудан гыйбарәт.

План өстендә эшләгәндә, көтепханәче китапларның укылышы кебек бик мөһим күрсәткечне дә, ягъни бирелгән китапларның бер укучыга туры килә торган уртача санын да исәпкә алырга тиеш. Укылышны билгеләү өчен ел буена бирелгән китаплар санын укучыларның гомуми санына бүләбез. Мәсәлән, әгәр 2 000 укучысы булган көтепханә ел буена 40 000 китап биргән икән, бу көтепханәдә укылыш 20 була.

Бу күрсәткеч нәрсә турында сөйли? Бу көтепханәдә һәр укучы ел буена уртача 20 китап алган. Менә шуңа карап, бу көтепханәдә укучыларның күбесе уртача хәзерлекле кешеләр икән дигән фикергә килергә була.

Әгәр дә укылыш ел әйләнәсенә 8—10 китап икән, бу инде көтепханәдә хәзерлекләре азрак булган укучыларның күпчелек тәшкил иткәнен күрсәтә, һәм, киресенчә, әгәр дә укылыш елына 30 китапка җитсә, ул чагында укучылар арасында хәзерлекләре яхшы булганнар күбрәк икән дип уйларга була.

Ләкин көтепханәдә укучыларның составы җитәрлек дәрәҗәдә хәзерлекле булып та, укылыш түбән (8—10—12) булган хәлләр дә булгалый. Бу—көтепханә фондында яхшы китаплар аз булуын яисә китапларны пропагандалау эшенең начар куелганлыгын күрсәтә. Укылыш һәм әйләнеш күрсәткечләре нигезендә киләсе елга көтепханәгә кирәкле китапларның гомуми саны билгеләнә һәм сан ягыннан комплектлау планы төзелә.

Шулай итеп тәҗрибәне исәпкә алу планлаштыруның бик әһәмиятле нигезе булып тора. Планны төзегәндә без көтепханә ирешкән нәтиҗәләрдән һәм учет материалларында чагылган нәтиҗәләрдән чыгып эш итәбез. Китап фондының күләме, укучылар саны, ел әйләнәсенә бирелгән китаплар саны, укылыш һәм әйләнеш күрсәткечләре, күчмә эш һәм книгоношлык, көтепханәнең массовый эше һәм белешмә-библиография эше—менә шулар барысы да өйрәнелергә һәм көтепханәнең киләчәк өчен эш планын төзегәндә игътибарга алынырга тиешләр.

## § 2. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ ЭШ ПЛАНЫ

Авыл көтепханәсенең еллык эш планы ничек төзелүне карап үтик. Планның төп булекләре түбәндәгеләр:

I. Планлаштырыла торган чор өчен авыл көтепханәсе эшенең бурычлары һәм эчтәлеге.

II. Контроль күрсәткечләр.

III. Көтепханәне комплектлау, китап фондын оештыру һәм саклау.

IV. Укучыларга хезмәт күрсәтү (абонементта эшләү, белешмә-библиография эше һәм массовый эш, укучыларның үзлекләреннән белем алуларына ярдәм күрсәтү).

V. Күчмә эш, көтепханәләр арасындагы абонементтан файдалану.

VI. Көтепханәнең эше турында отчет һәм информация бирү, укучылар активы белән эшләү.

VII. Көтепханә эшчесенең квалификациясен күтәрү.

VIII. Оештыру-хуҗалык мәсьәләләре.

Планның һәр бүлеге буенча төп чаралар, башкаручылар һәм үтәү сроклары билгеләнә.

Планның беренче бүлегендә күрсәтелә:

1) көтепханәнең гомуми политик-тәрбия бурычлары (марксизм-ленинизм пропагандасы, политик информация, укучыларны совет патриотизмы рухында тәрбияләү, табигать фәне белемнәрен пропагандалау, агрозоопропаганда, укучыларның үзлекләреннән белем алуларына ярдәм итү, матур әдәбиятны пропагандалау һ. б.);

2) җирле бурычларны хәл итүдә көтепханә булышлык күрсәтергә тиешле мәсьәләләр;

3) көтепханәнең эшен тагын да киңәйтү һәм яхшырту бурычлары (укучылар санын арттыру, көтепханәгә халыкның фәлән группаларын тарту, көтепханә фондын файдалануны көчәйтү, күчмә кәтепханәләр челтәрен һәм китап илтеп бирү эшләрен киңәйтү һ. б.).

„Контроль күрсәткечләр“ дигән бүлек буенча үзенә бер төсле эшләү таләп ителә. Контроль күрсәткечләргә түбәндәгеләр керә:

1. Укучыларның саны һәм составы.
2. Укылыш.
3. Бирелгән китаплар саны.
4. Әйләнеш.
5. Китап фонды.

Барлык контроль күрсәткечләр үткән ел нәтиҗәләре нигезендә билгеләнәләр. Мәсәлән, укучыларның саны һәм составы дигән күрсәткечне алып карыйк.

Көтепханә эшчесе укучылар составын халык составы белән чагыштыра, нинди группаларның әле көтепханәгә җитәрлек тартылмаганлыгын билгели, шушы группалар исәбенә укучылар санын арттыруны планга кертә. Бу вакытта бер уңайдан көтепханә эшчесе көтепханәнең мөмкинлекләрен исәпкә ала, укучылар санының үсешен китап фондының үсеше белән үлчи һ. б.

Әйтик, көтепханә укучылар санын башлыча балаларны тарту исәбенә арттырырга уйлый, ди. Көтепханә зурларны балаларга караганда күбрәк тартылган дип саный булса кирәк. Ләкин күбрәк хәлләрдә нәкъ моның киресенчә булгалый. Андый вакытларда көтепханә үзенең бөтен тырышлыгын зур яшьтәге укучыларны күбрәк тартуга юнәлдерергә тиеш.

Көтепханәгә яшьләрне, бигрәк тә яшүсмер эшчеләрне һәм колхозчы яшьләрне тартуга зур игътибар бирергә кирәк.

Чама белән укучыларның киләчәктәге санын билгеләп һәм аны планлаштырыла торган укылыш күрсәткеченә кабатлап, без киләсе елга китап бирүләрнең гомуми санын билгелибез. Мәсәлән, укучылар саны—800, укылыш—20, димәк, китаплар бирү саны—16 000. Китап бирүләр санын планлаштырыла торган әйләнешкә (мәсәлән, 4 кә) бүлсәк, планны үтәү өчен көтепханәгә кирәк булган фондның гомуми күләме килеп чыгар, әлеге мисалда—16 000 : 4 = 4 000 (китап) булыр.

Китап фондының контроль саны тагын да эшләүне һәм нигезләүне таләп итә.

Расчет үрнәген китереп үтик:

**Китап фонды**

| Бүлекләр | 1944 елда булган | 1945 елда булырга тиеш |
|---|---|---|
| 1. Иҗтимагый-политик әдәбият (1, 2. 3 һәм 9) | 1100 | 1 300 |
| Шул исәптән: | | |
| а) Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин әсәрләре . . . . . . . . . | 285 | 350 |
| б) Хәрби әдәбият (355) . . . . . . | 121 | 200 |
| 2. Табигать белеме һәм математика (5) | 95 | 150 |
| 3. Техник әдәбият (61 белән 63 тән башка 6) | 125 | 200 |
| 4. Авыл хуҗалыгы әдәбияты (63) | 194 | 250 |
| 5. Матур әдәбият | 1 022 | 1 250 |
| 6. Балалар әдәбияты | 590 | 700 |
| 7. Башка әдәбият | 108 | 150 |
| Барлыгы. . . | 3 234 | 4 000 |

Планның өченче бүлегендә коллектордан күпме китап, магазиннан күпме китап, башка чыганаклардан күпме китап алырга уйлаганны күрсәтергә кирәк.

Планның шушы ук бүлегендә китап фондын оештыру һәм саклау буенча алда торган эш тә күрсәтелә: фәлән кадәр китапны эшкәртү, фәлән кадәр каталог карточкасы язу, фәлән кадәр китапка ремонт ясау, китап фондына тикшерү үткәрү һ. б.

Планның дүртенче бүлеге укучыларга хезмәт күрсәтү чараларын эченә ала: абонементның эшен яхшырту (мәсәлән, актуаль әдәбият өчен ярдәмче ящиклар оештыру), белешмә-библиография эшен үстерү (библиографик күрсәткечләр алу, тематик картотекалар төзү, белешмә өстәле оештыру һ. б.), китапларны пропагандалау буенча массовый эш алып бару.

**Массовый эш**

| Массовый эшләрнең төп темалары | Чаралар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Кычкырып укулар | Китап күргәзмәләре | Плакатлар | Укучылар конференцияләре | Әдәби кичәләр | Әдәбият кузәтүләр | Лекцияләр, докладлар |
| 1. Совет халкының Бөек Ватан сугышы | | | | | | | |
| 2. Агрозоотехпропаганда. . . . . . . | | | | | | | |
| 3. Фән, сәнгать һәм әдәбият буенча бөек рус эшлеклеләре . . | | | | | | | |
| 4. Табигать фәне белемнәрен пропагандалау . . . . . . | | | | | | | |
| 5. . . . . . . . . . | | | | | | | |
| Барлыгы . . . | | | | | | | |
| Күпме халык тартырга . . . | | | | | | | |

Массовый эшне планлаштырганда китерелгән таблицадан файдаланырга һәм анда мисал өчен китерелгән темаларга шушы көтепханә укучыларын кызыктыра торган күп кенә бүтән темалар өстәргә була. Массовый эшләр тематикасы абонементта эшләү тематикасы белән бәйләнгән булырга тиеш.

Бишенче бүлектә көтепханәнең күчмә эше күрсәтелә (фәлән пунктларда фәлән кадәр күчмә көтепханә

оештырырга, күчмә көтепханәләргә фәлән кадәр китап бирергә, күчмә көтепханәләргә фәлән тапкыр барып килергә, күчмә көтепханәчеләр белән фәлән кадәр методик киңәшмә үткәрергә).

Шушы ук бүлектә көтепханәләр арасындагы абонементны пропагандалау (фәлән кадәр белдерү язу һ. б.) буенча һәм укучыларны аннан файдалануга тарту буенча чаралар билгеләнә.

Планның алтынчы бүлегендә көтепханәне пропагандалау, аның отчет-информация эшләре буенча чаралар күрсәтелә (авыл советының башкарма комитеты утырышында, урындагы партоешма җыелышында отчет белән чыгыш ясау; көтепханәнең эше турында район газетасында фәлән кадәр хәбәр урнаштыру һ. б.). Планның шул ук бүлегендә укучылар активын эшкә тарту саннары китерелә (группалар буенча: кычкырып укучылар, китап илтүчеләр, күчмә көтепханәчеләр һ. б.) һәм укучылар активы белән алып барырга уйланган эш күрсәтелә (активист укучыларның фәлән кадәр киңәшмәсен үткәрү, алар өчен фәлән темага доклад оештыру һ. б.)

Планның җиденче бүлегендә көтепханәченең квалификациясен күтәрү чаралары билгеләнә (көтепханә эше буенча фәлән төрле ярдәмлекләр укырга, район һәм өлкә көтепханәсе тарафыннан оештырыла торган занятиеләргә һәм семинарларга йөрергә, район көтепханәсендә кыска сроклы практика үтәргә).

Планның соңгы бүлеге оештыру-хуҗалык чараларын эченә ала (көтепханә бинасына ремонт ясау, җиһазлар сатып алу, ягулык хәзерләү һ. б ).

Авыл көтепханәсенең эш планы укучылар активы җыелышында тикшерелергә, авыл советы һәм культура-агарту эшләренең район бүлеге тарафыннан расланырга тиеш. Авыл көтепханәсенең еллык эш планының күчермәсе район көтепханәсенә җибәрелә.

Район көтепханәсенең эш планы шул ук авыл көтепханәсенең эш планына кергән бүлекләрне эченә ала һәм шуның өстенә — „Авыл көтепханәчеләренә һәм күчмә көтепханәчеләргә методик ярдәм“ дигән бүлек өстәлә. Бу бүлектә авыл һәм күчмә көтепханәләргә баруларның саны, авыл көтепханәчеләре һәм күчмә көтепханәчеләр өчен үткәреләчәк методик киңәшмәләрнең һәм семинарларның саны һәм тематикасы, аерым консультацияләр саны һ. б. күрсәтелә.

Район көтепханәсенең эш планында укучылар санының һәм китап бирүләр санының контроль цифрлары гомуми сан белән генә түгел, бәлки кварталлап билгеләнәләр. Бу — еллык планның үтәлешен квартал отчетлары буенча тикшереп барырга мөмкинлек бирә.

Район көтепханәсенең эш планы үз сотрудникларының укучылар активы белән берлектә үткәрелгән производство киңәшмәсендә тикшерелергә, ВКП(б) район комитетының пропаганда һәм агигация бүлеге белән килештерелергә һәм культура-агарту эшләренең район бүлеге тарафыннан расланырга тиеш.

Планның күчермәсе культура-агарту эшләренең өлкә (край) бүлегенә, өлкә (край) көтепханәсенең методик кабинетына җибәрелә.

Көтепханәнең эшен планлаштыру методикасы кыскача гына әйткәндә менә шундый. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, планда иң әһәмиятлесе — эшнең эчтәлеге. Һәртөрле расчетлар артында көтепханәнең планлаштырыла торган чор эчендә нинди эшләр алып барачагын һәм укучыларның нинди группасы белән алып барачагын онытырга ярамый.

Эшнең бурычларыннан һәм эчтәлегеннән чыгып, без массовый чараларның тематикасын һәм төрләрен, көтепханәгә алырга кирәкле әдәбият тематикасын, белешмә-библиография хезмәте күрсәтүнең характерын, күчмә көтепханәләр челтәрен, укучыларның үзлекләреннән белем алуына ярдәм күрсәтү чараларын билгелибез. Көтепханә тарафыннан билгеләнгән эшләрнең эчтәлеге — бик әһәмиятле темалар төсендәге эчтәлеге — укучыларга абонементта һәм уку залында аерым хезмәт күрсәтүдә, көтепханәченең китаплар алыштырган вакытта укучылар белән алып барган беседаларында чагылырга тиеш.

## § 3. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ БЮДЖЕТЫ ҺӘМ СМЕТАСЫ

Авыл көтепханәсе авыл советы бюджетында тора һәм аның үзенең сметасы була. Авыл көтепханәсе расходларының төп статьялары түбәндәгеләр:

1) хезмәт хакы, 2) китаплар сатып алу, 3) газета һәм журналлар яздыру, 4) бинага ремонт ясау һәм аны җиһазлау, 5) административ-хуҗалык расходлары (ягу, җылыту, яктырту, канцелярия расходлары һ. б.).

Район көтепханәсе культура-агарту эшләренең район бүлеге бюджетында тора һәм аның да шулай ук үзенең сметасы була, бу сметага авыл көтепханәсенең сметасы белән чагыштырганда түбәндәге статьялар өстәлә:

а) массовый чаралар үткәрү расходлары;

б) командировка расходлары;

в) методик эш расходлары.

Бюджеттан бирелә торган сумалардан тыш, район һәм авыл көтепханәләре договор тәртибендә күчмә көтепханәләр белән файдалана торган җирле оешмалардан һәм учреждениеләрдән өстәмә акча ала алалар. Бюджеттан тыш килә торган бу акчалар күчмә фондны киңәйтүгә һәм күчмә көтепханәләрдән файдаланучы укучыларга массовый эш белән хезмәт күрсәтүгә тотыла. Көтепханәне комплектлауга бирелгән акчаның кимендә 30% ы балалар әдәбияты алу өчен тотылырга тиеш.

Хезмәт хакы расходларын билгеләгәндә соцстрах буенча начисление (хезмәт хакының гомуми суммасыннан 4,3%) игътибарга алынырга тиеш.

Расходларның һәр статьясы буенча алдан ук расчет ясалып куелырга тиеш, бу расчет шушы статьяның расход суммасын нигезләү өчен хезмәт итә дә.

Мәсәлән, көтепханә фондын тулыландыру расходларын алып карыйк. Бу расходларның расчетын түбәндәге форма буенча эшлибез:

| Тәртип №№ | Расходлар исеме | Саны | Ургача бәясе | Суммасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Китаплар сатып алу | 1 000 | 4 сум | 4 000 сум | |
| 2 | Брошюралар сатып алу | 1 000 | 50 т. | 500 сум | |
| 3 | Китапларны төпләтү һәм ремонтлау | 250 | 2 сум | 500 сум | |
| 4 | Газеталар яздыру | 11 | — | 490 с. 60 т. | |
| 5 | Журналлар яздыру | 38 | — | 1 233 с. 20 т. | |
| 6 | Басма аннотация карточкаларын яздыру | тулы комплект | — | 450 с. | |
| | Барлыгы . . . | 2 299 | | 7 173 с. 80 т. | |

Смета төзү көтепханәнең эш планына, аның контроль күрсәткечләренә бик нык бәйләнгән. Планда сатып алынырга тиешле китаплар саны күрсәтелә, сметада — шушы билгеләнгән сандагы китапларны сатып алуга кирәкле акча күрсәтелә. Планда массовый эшләр күрсәтелә, сметада—билгеләнгән массовой эшләрне үткәрүгә тотылачак расходлар күрсәтелә.

Акчаны тотканда нәкъ расланган смета буенча эш итәргә кирәк. Сметада каралмаган расходларны тотарга ярамый. Бер статья буенча бирелгән акчаны икенче статья буенча билгеләнгән расходларга тотарга ярамый.

Культура-агарту эшләренең район бүлеге һәм район финанс бүлеге һәр кварталга касса планы төзиләр, ягъни расланган сметаның бу кварталда нинди өлешен тотарга кирәклеген билгелиләр. Көтепханә мөдире касса планын төзегәндә катнашырга һәм һәр квартал белән бәйләнгән расходларны, мәсәлән III кварталга — бинага ремонт ясау һәм ягулык хәзерләү расходларын, IV кварталга — вакытлы матбугат яздыру раходларын күздә тотарга тиеш һ. б.

Көтепханәдә эшне исәпкә ала барудан тыш, расходлар исәпкә алынып барырга тиеш. Һәр расход буенча көтепханәдә аклау документы (счет, расписка, накладной, квитанция һ. б.) калырга тиеш, һәрбер расход көтепханәнең касса кенәгәсенә языла барырга тиеш.

## § 4. МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ ЕЛЛЫК ОТЧЕТЫ

Әгәр дә көтепханәдә агымдагы эшләр регуляр рәвештә исәпкә алынып бара икән, ул чагында еллык отчетны төзү бер дә кыен түгел. Массовый көтепханәнең еллык отчеты РСФСР ның Үзәк статистика управлениесе тарафыннан 1943 елның 16 апрелендә расланган 19—53 номерлы форма буенча өч данәдә төзелә (3 нче кушымтаны кара). Отчетның ике данәсе культура-агарту эшләренең район бүлегенә тапшырыла, бер данәсе көтепханәнен үзендә кала.

Отчетта көтепханәнең тулы исеме языла һәм аның нинди типка керүе күрсәтелә (өлкә. район, шәһәр, авыл һ. б.— 2 нче пункт). Аннан соңгы пунктларда түбәндәге сорауларга җавап бирелә: көтепханә каршында уку залы һәм балалар бүлеге бармы? Көтепханә бинасының гомуми мәйданы нинди? Көтепханәнең штатын-

да, көтепханә мөдирен дә кертеп исәпләгәндә, ничә түләүле работник бар? Шушы беренче мәгълүматлардан соң укучылар саны турындагы, күчмә көтепханәләр эше турындагы, фондтан чыккан китаплар турындагы, көтепханәләр арасындагы абонемент буенча китаплар алу һәм бирү турындагы мәгълүматлар китерелә. Булган китаплар, аларның ел буена кереме һәм бүлекләргә бүленеше күрсәтелгән 11 нче пункт бик әһәмиятле. Отчетның соңгы пункты көтепханәнең ел әйләнәсендә кергән һәм тотылган акчасы мәсьәләсенә багышланган.

Отчет бланкысын тутыргач, көтепханәче көтепханәнен отчет чорындагы эшен язуга күчә.

Отчетның шушы язма өлешендә көтепханәче укучылар белән эшләүнең эчтәлеген, массовый чараларның тематикасын, белешмә-библиография эшенең юнәлешен сөйләп бирә, укучыларның сорауларына һәм аларның көтепханә тарафыннан канәгатьләндерелүенә характеристика бирә, көтепханәнең планы ни дәрәҗәдә үтәлүен күрсәтә.

Отчетта көтепханә эшенең төп кыенлыкларын һәм кимчелекләрен, аның казанышларын һәм уңышларын ачып бирергә, шулай ук көтепханәнен эшенә һәм билгеләнгән планның үтәлүенә комачаулый торган сәбәпләргә анализ ясарга кирәк.

## КӨТЕПХАНӘ ЭШЕ БУЕНЧА ӘДӘБИЯТТАН КЫСКАЧА ИСЕМЛЕК

1. **Көтепханәләр турында Ленин нәрсәләр язды һәм әйтте.** Н. К. Крупскаяның сүз башы мәкаләләре һәм искәрмәләре белән. 4 нче басмасы. М Көтепханә белеменең һәм тәкъдим библиографиясенең фәнни-тикшеренү институты. 1939. 80 бит.

2. **Крупская Н. К.** Көтепханә эше. Мәкаләләр җыентыгы. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940. 128 бит. Җыентык көтепханә эшенең бурычлары һәм оештырылуы турында, көтепханә кадрларын хәзерләү турында, укучыга хезмәт күрсәтү турында, балалар көтепханәсе һәм мәктәп көтепханәләре турында, балалар әдәбияты турында мәкаләләрне эченә ала. „Социалистик төзелешнең бик әһәмиятле участогы" (5—9 битләр), „Авыл көтепханәчесенең эше турында" (25—33 битләр). „Китап өстендә үзлегеннән ничек эшләргә" (80—94 битләр) дигән мәкаләләр аеруча әһәмиятле.

3. **Кленов А. В.** Көтепханә техникасы буенча кыскача кулланма. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1944. 108 бит. Көтепханә техникасына бәйләнешле барлык төп мәсьәләләр кыска гына формада яктыртылганнар. Бу ярдәмлек булмаганда шул ук авторның түбәндәге китабыннан файдаланырга мөмкин. **Кленов А. В.** Көтепханә техникасы. Көтепханә техникумнары өчен укыту ярдәмлеге. Тулыландырылган 3 нче басмасы. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1940. 248 бит.

4. **Массовый көтепханәләрдә көтепханә техникасы минимумы** (инструкцияләр һәм учет формалары). М. Дәүләт көтепханә-библиография институты. 1945

5. **Троповский Л. Н.** Кечкенә көтепханәләр өчен унарлы классификациянең кыскача таблицалары. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1944. 80 бит. Таблицалардан файдалачуны җиңеләйтү өчен аларга унарлы классификациянең иң әһәмиятле рубрикаларының алфавитлы күрсәткече кушымта итеп бирелгән (37—80 битләр).

6. **Хавкина Л. Б.** Кёттер методы буенча автор таблицалары (икеле цифрлы). 15 нче басмасы. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1945. Китапларны кеттерлау буенча күрсәтмәләрне эченә алган кереш мәкаләне өйрәнергә киңәш бирелә.

7. **Денисьев В. Н.** Библиографиядән гомуми курс. РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан көтепханә техникумнары өчен укыту ярдәмлеге сыйфатында расланган. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941. 152 бит. Түбәндәге бүлекләре белән танышырга киңәш бирелә:

I. Библиография предметы, әһәмияте һәм бурычлары. II. Библиографиянең типлары һәм төрләре. V. Китапларны өйрәнүнең төп мәсьәләләре. VI. Китаплар белән беренче башлап танышу методлары. VII. Китапларны аннотацияләү һәм VIII. Массовый көтепханәдә тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләре төзү.

8. **Денисьев В. Н.** Авыл көтепханәсенең китап фондын ничек комплектларга. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941. 48 бит („Авылдагы көтепханә эшчесенә ярдәмгә“). Брошюра көтепханәләрне комплектлауның хәзерге тематикасын чагылдырмый, ләкин аны комплектлауның гомуми методикасы белән һәм 1941 елга кадәр басылып чыккан төп библиографик материаллар белән танышу өчен файдаланырга мөмкин.

9. **Хейфец З. Б.** Китап сайлауда укучыга ярдәм. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941. 30 бит („Авылдагы көтепханә эшчесенә ярдәмгә“). Брошюра китаплар биргән вакытта укучы белән алып барыла торган беседаның методикасын өйрәнү өчен файдалы. Автор мисал итеп китергән китаплар беркадәр искерә төштеләр, өйрәнүче кешегә үзенә соңгы вакытларда чыккан әдәбияттан мисаллар сайларга кирәк булачак.

10. **Карклина Н.** Массовый көтепханәнең белешмә-библиография эше. М. Көтепханә белеменең һәм тәкъдим библиографиясенең фәнни-тикшеренү институты. 1939. 55 бит.

11. **Агитаторның газета белән эшләве. М.** Госполитиздат 1943. 15 бит. Агитатор өчен бик кыйммәтле истәлек, газета белән эшләүне оештырганда көтепханәче дә файдалана ала.

12 **Метелкин Н. һәм Зуева О.** Авыл көтепханәсенең массовый эше. М. Дәүләт көтепханә-библиография издательствосы. 1941. 24 бит („Авыл көтепханәчесенә ярдәмгә“). Брошюра ике кисәктән тора: 1. Массовый эшнең бурычлары, оештырылуы, формалары һәм методлары. 2. Актив белән эшләүне оештыру. Беренче кисәге массовый эшнең тематикасы ягыннан беркадәр искерә төште, ләкин массовый чараларны хәзерләү һәм үткәрү методикасы белән танышу өчен файдаланырга мөмкин.

# МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘДӘН ФАЙДАЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

**1. Массовый көтепханәдән барлык гражданнар түләүсез файдалана алалар**

2. Өйгә китаплар алу өчен һәм уку залына даими рәвештә йөрү өчен шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә көтепханәгә язылганда шушы урында даими торуы турында билгесе булган паспорт күрсәтү таләп ителә.

Авыл жирләрендә һәм кечкенә торак пунктларда өйгә китаплар алу өчен паспорт урынына кешене таныклый торган бүтән документ күрсәтелергә мөмкин.

> Искәрмә: 16 яшькә житмәгән балалар ата-аналарының яки үзләрен тәрбияли торган башка кешеләрнең поручительствосын китерәләр. Ул шәһәрләрдә йорт идарәләре тарафыннан, ә авыл җирләрендә авыл советы тарафыннан расланырга тиеш.

3. Бу урында вакытлыча яши торган гражданнар, шулай ук шәһәрдән читтә яки шәһәрнең башка районында торучы гражданнар өйгә китаплар алу өчен 30 сум күләмендә залог кертәләр.

Көтепханәдән киткәндә залог укучыга кайтарып бирелә. Залог укучыларны көтепханә китапларын саклап тоту һәм аларны вакытында кайтарып тапшыру җаваплылыгыннан азат итми.

4. Кызыл Армиянең офицерлар составы китапларны өйгә алганда 30 сум күләмендә акчалата залог калдырып алалар, рядовойлар һәм сержантлар составы часть командованиесенең поручительствосы белән алалар.

> Искәрмә: Рядовойлар, сержантлар һәм офицерлар составын көтепханәгә укучы итеп язуны формалаштырганда укучы формулярына частьның исемен һәм торган урынын язарга рөхсәт ителми. Частьның почта адресын гына күрсәтергә кирәк.

5. Вузлар һәм техникумнарның тулай торакларда тора торган студентлары өйгә китапларны 20 сум күләмендә залог калдырып яки уку бүлегенең һәм уку йорты көтепханәсенең поручительствосы белән алалар. Мондый хәлләрдә уку йортларының укыту бүлекләре һәм көтепханәләре материаль яктан тулы җаваплылыкны үзләре өстенә алалар.

Искәрмә: г) ФЗӨ мәктәпләре, һөнәр һәм тимер юл училищелары укучылары көтепханәләрдән вузлар һәм техникумнарның тулай торакларда тора торган студентлары белән бертөсле шартларда файдаланалар;

б) производствода эшләүче һәм 16 яшькә житмәгән яшүсмерләр көтепханәгә завод таныклыгын һәм завод идарәсеннән яки завкомнан алган поручительствоны китереп язылалар.

6. Уку залына килгәч укучылар әдәбиятны укучы билеты буенча яки шәхесне таныклый торган документ калдырып алалар.

7. Тору урынын алыштырган абонент (укучы) ун көн срок эчендә көтепханәгә үзенең яңа адресын белдерергә һәм яңа пропискалы паспортын күрсәтергә тиеш.

8. **Укучы өйгә күп дигәндә 3 китап ала ала:** берсе матур әдәбияттан һәм 2 се фәнни әдәбияттан. Брошюралар бу исәпкә керми. Срогы күп дигәндә 10 көн.

Әгәр дә бу китапларны башка укучылардан сораучылар булмаса, көтепханә китаплардан файдалану срогын озайта ала.

Искәрмә: Аерым хәлләрдә көтепханәчегә китаплардан файдалану срогын кимету хокукы бирелә.

9. **Сирәк китаплар, белешмә әсәрләр, бер генә данәдә булган китаплар өйгә бирелмиләр:** алардан уку залында гына файдаланырга мөмкин. Уку залы булмаган көтепханәләрдә бу китапларны шул китап урынына китап сатып алырлык күләмдә залог калдырып бирергә була.

10. Укучыга бирелгән китаплар укучы формулярына язылалар; укучы һәр китапны алганлыкка кул куя. Китапларны укучыдан кабул итеп алганда көтепханәче аларны алганлыкка кул куя. Укучы китапларны алганлыкка һәм көтепханәче аларны кире кабул итеп алганлыкка кул куйган укучы формуляры бу китапларны көтепханәдән алу һәм аларны укучыдан кире кайтарып алу фактын таныклый торган юридик документ булып хезмәт итә

11. Китаплар укучы тарафыннан билгеләнгән срокта кайтарылмаган хәлләрдә аңа повестка жибәрелә. Әгәр дә шуннан соң укучы көтепханәгә килмәсә, аңа китаплар жыючы жибәрелә, ә повестка һәм жыючыны жибәрү буенча тотылган расход 3 сум күләмендә укучыдан алына. Китапларны кабул итеп алу турында укучыга көтепханә печате сугылган квитанция бирелә.

12. Укучы китапларны искә алырлык сәбәпсез озак тоткан өчен көтепханә укучыдан кичектерелгән һәр китап өчен көненә 50 шәр тиеннән пеня ала. Кичектерүгә 10 көн үткәннән соң пеня ике тапкыр артык алына.

13. **Укучы көтепханә китапларын жыйнак һәм сак тотарга тиеш, китапларга бернинди дә билгеләр ясамаска, сызгаламаска, аларны бозылудан һәм урланудан сакларга һәм вакытында көтепханәгә кайтарып тапшырырга тиеш.**

Искәрмә: Китаплар алганда укучыга аларны яхшылап карап тикшереп алырга һәм нинди дә булса берәр житешсезлек күренсә бу турыда көтепханәчегә әйтеп алырга киңәш бирелә. Көтепханәче бу турыда китапка тиешле билгеләр ясый, башкача булганда китапта күренгән житешсезлекләр өчен укучы жаваплы була.

Укучы китапны кайтарып тапшырганда көтепханәче аны игътибар белән карап алырга тиеш.

14. Китапны югалтканда яки бозганда укучы көтепханәгә шундый ук китап кайтарып бирергә тиеш, яки көтепханә тарафыннан бер дәрәҗәдә кыйммәтле дип табылган икенче китап белән алыштырырга, яки шундый ук китап сатып алырлык акча түләргә тиеш.

15. Укучы китапларны кайтарудан яки аларның бәясен түләүдән баш тартса, көтепханә укучыдан югалткан яки бозган китабының бәяен нотариаль контораның башкару язуы буенча (РСФСР Совнаркомының 1931 ел 11 август карары нигезендә, С. У. № 56, 418 бит) яки суд тәртибендә түләтә.

Көтепханәдән китап урлауда, көтепханә китапларын бозуда гаепле булган укучылар җинаять кодексының 79 һәм 162 статьялары буенча җавапка тартылалар һәм шул ук вакытта аларга көтепханәгә китергән материаль зыянны түләтү чарасы күрелә.

Искәрмә: Балигъ булмаган укучы тарафыннан көтепханәгә китерелгән материаль зыян өчен ата-аналар яки бала кем семьясында булса шул кеше җавап бирә.

16. Көтепханә:

а) кирәкле китапларны сайлауда укучыга китаплар биргәндә телдән консультацияләр бирү, аңа көтепханә каталогларын, тәкъдим ителә торган әдәбият исемлекләрен һәм бүтән төрле библиографик материалларны бирү юлы белән, шулай ук китап күргәзмәләре оештыру юлы белән ярдәм итәргә тиеш;

б) алынган яңа әдәбият турында укучыга белдерергә тиеш;

в) укучыларның таләпләре буенча индивидуаль уку планнары төзергә тиеш;

г) белешмә эшен оештырырга тиеш;

д) укучы сораган китаплар көтепханәнең үзендә булмаганда, аларны көтепханәләр арасындагы абонемент буенча бүтән көтепханәләрдән алу чарасын күрергә тиеш.

17. Укучыларга хезмәт күрсәтүне яхшырту һәм укучылар активын эшкә тарту өчен көтепханә мөдире (директоры) укучыларның конференцияләрен һәм киңәшмәләрен чакырырга, аларда көтепханәнең эшен тикшерергә, әдәби кичәләр, китапларны тикшерүләр оештырырга тиеш һ. б.

18 **Көтепханә администрациясе һәм аның сотрудниклары бу кагыйдәләрнең үтәлүе өчен җавап бирәләр һәм аларны бозуларга каршы тиешле чара күрергә тиешләр:** китапларны саклау турында укучылар белән абонементта беседалар үткәрергә, китапларны озак тоткан укучыларга белдерүләрне вакытында җибәрергә тиешләр һ б. Шулай булмаганда көтепхзнәгә укучылар китергән материаль зыян өчен көтепханә работниклары җавап бирәләр.

19. Кагыйдәләр көтепханәдә күречерлек урынга эленгән булырга тиеш Язылганда укучылар аның белән таныштырылырга тиешләр, бу турыда алар формулярга кул куялар. Эшчеләре һәм хезмәткәрләре шушы көтепханәдән файдалана торган предприятие һәм учреждениеләрнең администрациясе дә кагыйдәләр белән таныштырылырга тиешләр.

20. Көтепханәдән файдалану кагыйдәләрен бозучы укучыларга китаплар бирү туктатыла, бу турыда укучы эшли торган урынның администрациясенә һәм җәмәгать оешмаларына хәбәр ителә.

*КУШЫМТА 3*

*Форма ОБ-1*

РСФСР ның Статистика Управлениесе тарафыннан расланды, № 19—53, 16/VI—1943 ел.

# МАССОВЫЙ КӨТЕПХАНӘНЕҢ 194... ел өчен ОТЧЕТЫ

Культура-агарту учрежденчеләре Комитеты органнары яки колхоз исәбенә тотыла торган һәрбер стационар көтепханә еллык отчет яза.

Отчет 1 нче январьга булган хәл буенча 3 данәдә язылып, аларның икесе 10 нчы январьдан да соңга калмыйча район башкарма комитетының культура-агарту эшләре бүлегенә тапшырыла һәм бер данәсе көтепханәнең үзендә кала.

Көтепханәнең адресы (АССР, край, өлкә, район, шәһәр, авыл күрсәтелә) ..............................................................................

..............................................................................................................

1. Көтепханәнең тулы исеме ..............................................

..............................................................................................................

2. Көтепханә нинди типка керә: край, өлкә, республика, округ, район, шәһәр, авыл (мөстәкыйль авыл бюджетында тора торганы), балалар көтепханәсе яки колхоз көтепханәсе (колхоз клубына яки культура йортына керми торганы). ..............................

3. Көтепханә каршында уку залы бармы—бар, юк (астына сызыла).

4. Көтепханә каршында балалар бүлеге бармы—бар, юк (астына сызыла).

5 Көтепханә бинасының гомуми мәйданы ........................ кв. м.

6. Түләүле көтепханә эшчеләре, барлыгы (көтепханә мөдирен дә кертеп исәпләгәндә) ........................ кеше.

| | |
|---|---|
| Ел әйләнәсендә (январь башыннан алып декабрь азагына кадәр) аерым абонемент буенча китап, журнал һәм брошюралар алган укучылар саны | |
| Соңгы 3 ай (октябрь—декабрь) эчендә күпме укучы китап, журнал һәм брошюралар алган | |
| Шушылардан 16 яше тулмаган балалар | |
| Ел әйләнәсендә уку залы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән укучылар саны | |

| | | |
|---|---|---|
| 194.... елның 1 нче январена күчмә көтепханәләрнең гомуми саны | | |
| Барлыгы китап бирелгән | Күчмә көтепханәләр өчен | |
| | Китап илтүчеләргә | |
| Ел әйләнәсендә күчмә көтепханәләрдән китаплар алган барлык укучылар | | |
| Ел әйләнәсендә күчмә көтепханәләрдән бирелгән китаплар саны | | |

9. Ел әйләнәсендә көтепханәнең төп фондыннан күпме китап юкка чыкты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . данә.

Шул исәптән тузу сәбәпле . . . . . . . . . . . . . . . „

Укучылар кайтармау сәбәпле . . . . . . . . . . . . . . „

10. Көтепханәләр арасындагы абонемент буенча ел әйләнәсендә:

башка көтепханәләрдән . . . . . . . . . данә китап алынды,

башка көтепханәләргә . . . данә китап бирелде.

11. Көтепханәдә булган, алынган һәм бирелгән китаплар, журналлар һәм брошюралар саны бүлекләр буенча санаганда:

| Бүлекләр | Отчет елы азагына, күчмә көтепханәләрдәге һәм укучылардагы китаплар белән бергә санаганда исәптә тора торган данәләр | Шулардан отчет елы эчендә көтепханәгә алынды | Аерым абонемент буенча укучыларга бирелгән китаплар саны | Уку залында ел әйләнәсендә бирелгән китаплар саны |
|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 |
| Иҗтимагый-политик.... | | | | |
| шул исәптән: Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин китаплары.... | | | | |
| Табигать фәне буенча | | | | |
| Техника буенча . . . | | | | |
| Авыл хуҗалыгы буенча . . . . . . . . . | | | | |
| Матур әдәбият . . . . | | | | |
| Балалар әдәбияты . . | | | | |
| Башкалар . . . . . . | | | | |
| Барлыгы китаплар, журналлар, брошюралар. | | | | |

12. Отчет елы эчендә керем-чыгым (сумнар белән)

| Еллык смета буенча барлыгы билгеләнгән (расланган) | Ел әйләнәсендә керде | | Ел әйләнәсендә тотылды | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән бюджет чыганакларыннан (респ. һәм җирле бюджетлардан) | Барлыгы | Шул исәптән | |
| | | | | Эш хакына (соцстрах начислениесеннән башка һ. б.) | Китаплар, журналлар һәм газеталар сатып алуга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Тутыру (язу) датасы............194.......ел.

**Көтепханә мөдире** ............................

## ЭЧТӘЛЕК

Бит

Кереш сүз. Массовый көтепханәнең бурычлары һәм көтепханәдә эшләүченең роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

I бүлек. **Район һәм авыл көтепханәләренең эшен оештыру**

§ 1. Районда көтепханәләр челтәре . . . . . . . . . . . . 9
§ 2. Көтепханә эшенә җитәкчелек . . . . . . . . . . . . 11
§ 3. Массовый көтепханәнең төзелеше һәм аның китапларыннан файдалану тәртибе . . . . . . . . . . . . 14
§ 4. Массовый көтепханәдә укучылар активы . . . . . . 18

II бүлек. **Көтепханә фондының составы, аны өйрәнү һәм комплектлау**

§ 1. Көтепханә фондының төп өлешләре . . . . . . . . . . 21
§ 2. Фәнни китапларның типлары . . . . . . . . . . . . 21
§ 3. Массовый көтепханәләрне комплектлау принциплары. 23
§ 4. Көтепханә эшчесе китапларны ничек өйрәнә . . . . . 26
§ 5. Китапларны өйрәнү һәм көтепханәне комплектлау өчен библиографиядән ничек файдаланырга . . . . . . . . . 30
§ 6. Көтепханәнең китап фондын ничек өйрәнергә . . . . 34
§ 7. Көтепханә өчен китапларны кайдан һәм ничек алырга. 43
§ 8. Көтепханәләр арасындагы абонемент . . . . . . . . . 45

III бүлек. **Массовый көтепханәләрдәге китапларны классификацияләү һәм каттеризацияләү**

§ 1. Массовый көтепханәләрдәге китапларны классификацияләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
§ 2. Китапларны каттеризацияләү . . . . . . . . . . . . . 52

IV бүлек. **Көтепханәнең китап байлыгына учет**

§ 1. Көтепханәгә алынган әдәбиятны кабул итү . . . . . . 55
§ 2. Көтепханәгә алынган китап, брошюра һәм журналларның аерым учеты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
§ 3. Көтепханәдән чыга торган әдәбиятка аерым учет . . . 60
§ 4. Көтепханә фонды хәрәкәтенә гомуми тулай учет . . . 62
§ 5. Көтепханә фондын тикшерү . . . . . . . . . . . . . 64
§ 6. Көтепханә фондын тапшыру һәм кабул итеп алу . . . 69

V бүлек. **Көтепханәдәге китапларны каталогка салу**

§ 1. Көтепханәдә каталоглар ник кирәк, аларның төрләре һәм формалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
§ 2. Китапларны тасвир итүнең төп кагыйдәләре . . . . . 73
§ 3. Системалы каталогка карточкаларның куелышы һәм аның формалаштырылуы . . . . . . . . . . . . . . . . 76
§ 4. Алфавитлы каталогта карточкаларның куелышы һәм аның формалаштырылуы . . . . . . . . . . . . . . . . 78
§ 5. Тәкъдим итү өчен тематик карточкалар . . . . . . . . 80

VI бүлек. **Көтепханәдә китапларны рәсмиләштерү, тезеп кую һәм саклау**

§ 1. Көтепханәдә китапларны рәсмиләштерү . . . . . . . . 83
§ 2. Китапларны тезеп кую . . . . . . . . . . . . . . . . 85
§ 3. Китапларны, журнал һәм газеталарны саклау . . . . . 87

VII бүлек. **Абонементта һәм уку залында эшләү**

§ 1. Укучылар белән эшләү, аның бурычлары һәм эчтәлеге. 90
§ 2. Көтепханә эшчесенең китаплар бирүгә хәзерләнүе . . 92
§ 3. Көтепханәгә яңа укучылар язу . . . . . . . . . . . . 93
§ 4. Укучыларга китаплар сайлау һәм тәкъдим итү . . . . 96
§ 5. Укучыдан китапларны кабул итеп алу. Китапларны кайтарып алганда көтепханә эшчесенең укучы белән беседасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
§ 6. Абонементта эшләү техникасы . . . . . . . . . . . . . 101
§ 7. Бирелгән китап, брошюра һәм журналларны исәпкә алу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
§ 8. Абонементны формалаштыру һәм җиһазлау . . . . . . 105
§ 9. Укучыларга уку залында хезмәт күрсәтү . . . . . . . 105

VIII бүлек. **Массовый көтепханәнең белешмә-библиография эше**

§ 1. Массовый көтепханәнең белешмә-библиография эшенең бурычлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
§ 2. Массовый көтепханәнең белешмә-библиография эшен оештыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
§ 3. Белешмә, библиография һәм бүтән ярдәмче материалларны сайлау һәм файдалану . . . . . . . . . . . . 114
§ 4. Көтепханәнең белешмә эшенең формалары һәм методлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

IX бүлек. **Көтепханәнең массовый эше**

§ 1. Көтепханәнең массовый эш бурычлары . . . . . . . . 129
§ 2. Газета витриналары . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
§ 3. Китап күргәзмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
§ 4. Көтепханә плакаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
§ 5. Кычкырып укулар-беседалар . . . . . . . . . . . . . 140
§ 6. Әдәби кичәләр һәм укучылар конференцияләре . . . . 146
§ 7. Көтепханәнең үзен пропагандалау һәм яңа укучылар тарту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

X бүлек. **Көтепханәнең күчмә эше һәм китапларны укучыларга илтеп бирү**

§ 1. Көтепханәнең күчмә эшен оештыру . . . . . . . . . . . 153
§ 2. Көтепханәнең күчмә эш техникасы һәм аны учетка алу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

XI бүлек. **Массовый көтепханәнең эш планы, сметасы һәм отчеты**

§ 1. Эш планын төзегәндә нәрсәдән чыгып эш итәргә . . . 161
§ 2. Массовый көтепханәнең эш планы . . . . . . . . . . . 163
§ 3. Массовый көтепханәнең бюджеты һәм сметасы . . . . 168
§ 4. Массовый көтепханәнең еллык отчеты . . . . . . . . . 170
*Кушымталар.*
Көтепханә эше буенча әдәбияттан кыскача исемлек 172
Массовый көтепханәдән файдалану кагыйдәләре . . . 174
Массовый көтепханәнең отчет формасы . . . . . . . 177

В. Н. Денисьев

КРАТКОЕ РУКОВОДСТВО
ПО БИБЛИОТЕЧНОМУ ДЕЛУ

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе Хәмзә Кәримов

Җаваплы редакторы Г. Набиев

Техник редакторы И. Зәйнуллин

Корректорлары И. Галиуллина һәм И. Рахматуллин

Басарга кул куелды 26/XII-47 ел. ПФ 13376. Тираж 3 165. Басма табак 11½.
Заказ №469. Бәясе 5 сум.

Издательстволар һәм полиграфия Управлениесе каршындагы Камил Якуб исемендәге китап фабрикасында басылды. Казан, Бауман ур. 19, 1948 ел.

ОТК 8

[35-00]

Бәясе 5 сум

ОТК. 1.